Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 7 (1423) 22 февраль 2023 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga



8

Дистә-йөз меңнәр белән саналган татар шахтерларын барлау, аларның тарихын һәм бүгенгесен өйрәнү юлында зур адым ясалды.

9

Татар генералы Хәбиб Ганиевне хезмәттәшләре Бөек Ватан сугышында солдатларда иң авыр вакытта да өмет уята белгән хәрби җитәкче буларак искә ала.

12

Тормышын хәрби кораблар белән бәйләгән милләттәшебез Тимур Яруллин картиналарында аларны мөмкин кадәр төгәллек белән сурәтләргә тырыша.

Ватаныңны саклау – изге бурыч, Хәвеф килсә әгәр илләргә...

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов карары белән җырчы Габделфәт Сафин, татар мәдәниятен саклауга һәм музыкаль сәнгатьне үстерүгә аерым өлеш керткән өчен, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены медале белән бүләкләнде.
- Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан төшерелгән «Ибн Фадлан» документаль-нәфис фильмын 2 марттан башлап Казан, Түбән Кама, Уфа, Чаллы шәһәрләрендә карап булачак.
- Мөслим районы үзәгендә урнашкан Балалар сәнгать мәктәбендә Татарстан Рәссамнар берлеге оештырган этно пленэр-симпозиум бара.
- Муса Җәлил исемендәге премиягә быел «Шаян ТВ» телеканалы, шагыйрь Рифат Сәлах, җырчы Илүсә Хуҗина, Камал театры актерлары Фәннүр Мөхәммәтҗанов һәм Ләйсән Гатауллина лаек булды.
- 5-9 сентябрьдә узачак XIX Казан халыкара мөселман киносы фестивале кысаларында Гарәп киносы көннәре оештырылачак.
- Татарстан Язучылар берлеге ярдәме белән «Тормыш иминлеге фәнни үзәге» яшь язучылар һәм шагыйрьләр өчен «Яшел сигналга сәяхәт» конкурсы үткәрә.
- Һади Атласи исемендәге хәйрия фонды Бөгелмәдә хәттат Нәҗип Нәккаш күргәзмәсен оештырды.
- Татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимовның «Алмачуар» әсәре буенча Татарстан һәм Казахстан хезмәттәшлегендә иҗат ителгән «Тарлан» фильмы V Әл-Айн халыкара кинофестивалендә (Әбу-Даби) җюриның махсус бүләгенә ия булды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Фарис ХАРИСОВ, Татарстанның элекке мәгариф һәм фән министры:

«Хәзер заманнар үзгәрде. Буын үзгәрә башлады, яңа яшьләр килә. Аларга тарихны аңлатучы җитми. Яшьләр татар мәгарифенең үсү этапларын белми, кайберләре бөтенләй җиңел карый. Татар гимназиясендә күп фәннәр татар телендә укытылмый икән, балада милли үзаңны формалаштырып буламы? Була, ләкин аңлату эше катлауланаа бара».

СЫНАМЫШЛАР

27 февральдә аяз булса – көннәр суыта ● Агачларны бәс сарса – суыта ● Кыш салкын килсә, җиләк-җимеш уңа ● Кыш карсыз булса, җәй иген уңмый ● Мартта еш томан төшсә, җәй яңгырлы килә ● Март коры булса – иген уңа, яңгырлы булса – уңмый.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 54 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 02 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **10 сәгать 08 минут.** Алдагы тугыз көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **41 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **3 мартта 10 сәгать 49 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

22 февраль – рәссам Равил Халит улы Шәрәфетдиновның тууына 75 ел (1948–1995).

25 февраль – нашир-мөхәррир, җырчы Камил Мотыйгулла улы Мотыйгыйн (Төхфәтуллин) тууына 140 ел (1883–1941).

26 февраль – шагыйрә Гөлзадә Әүхәди кызы Бәйрәмовага 60 яшь (1963).

1 март – шагыйрь, публицист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рәфикъ Юныс улы Юнысовның тууына 80 ел (1943–2021);

– Казан хореография училищесы ачылуга 30 ел (1993).

2 март – балалар язучысы Дәрҗия Сәйфулла кызы Аппаковаsucc тууына 125 ел (1898–1948).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Февраль-мартның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 2 март.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(20-27 февраль)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

###ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген шәгъбән аеның 2 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Марсель БАКИРОВ,
филология фәннәре докторы, КФУ профессоры, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе

Яңа сигезтомлык ник кирәк?

2014-2021 елларда Татарстан Фәннәр академиясе һәм Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты грифлары белән күптән көтелгән 8 томлык «Татар әдәбияты тарихы» чыгарылды. Шулардан беренче томны төзешүдә турыдан-туры катнашкан һәм аның фәнни редакторы булган кеше мин фәкыйрегез иде. Шул ук томда минем тюркологиядә беренче буларак һун-гуннарның поэтик иҗатын, риторика-матур сөйләү сәнгатен һәм дә һун бабаларыбыз һәм борынгы төркиләр кулланган язу төрләрен тәфсилләп, махсус рәвештә өйрәнүгә багышланган «Пратөрки бабаларыбыз иҗаты» исемле күләмле тикшеренүем басылды һәм «Идегәй – эпос-дастан жанрының классик үрнәге» дигән мәкаләм дә урын алды. Ә шул ук 2014 елда басылган икенче томда исә «Чура батыр эпос-дастаны» дип исемләнгән хезмәтем урнаштырылды.

Заманында югары уку йортлары өчен дәреслек итеп, күренекле тюрколог Н.Баскаковның «Введение в изучение тюркских языков» дигән китабы чыгарылган иде. Мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән бу хезмәттә төрки телләрнең формалашуы һәм иң борынгы үрнәкләре һун теленә бәйләп карала. Шулай булгач, аңлашыла инде: минем төрки сүз сәнгатенең башын һуннар белән бәйләвем һәм чәчелеп яткан төрле аз билгеле чыганакларны бөртекләп өйрәнеп, кытай һәм латин телләрендә килеп җиткән уннан артык һун тел-аваз иҗаты жанрлары (мифологик хикәят, ырым, мәкаль, әйтем, ода-алкыш, гимн, келәү, каргыш, ант, тарихи һәм лирик җыр, шигъри-музыкаль юрамыш, күрәзә, җеназа сыктавы, эпос-дастаннарның инде формалашкан булуын раслаучы сюжетлы рәсем) үрнәкләрен аерып чыгаруым, һичшиксез, законлы һәм соралып торган изге гамәл иде. Ә инде әлеге текстларның башка телләрдә килеп җитүе генә аларның эчтәлегенә һәм, гомумән, пратөрки фольклорда беренче башлап формалашкан жанрларга булганлыгына шик тудыра алмый. Чөнки теләсә кайсы телдәге информациянең тәрҗемәдә бирелә алуы шиксез.

Ләкин менә бер ел үтмәс борын ук (!), «Татар әдәбияты тарихы»ның яңа редакциядә кабаттан чыгарыла башлавы һәм, инде чыгып өлгергән ике томнын күренгәнчә, Марсель Бакировның һич көтмәгәндә редколлегия составыннан һәм фәнни редакторлыктан чыгарылуы, әле генә саналган фәнни ачышларымның да ул томнардан алып ташлануы гына аек акылга сыймый. Бу бит башка төрки халыклар арасында иң борынгы иҗади мирасыбызны торгызу һәм өйрәнүдә, Мансур Хәсәнов, Нурмөхәммәт Хисамов, Әнвәр Шәрипов, Марсель Галиев һ.б. рецензентлар бик дөрес билгеләгәнчә, татарның пионер (башлаучы һәм нигез салучы) булуын танып, ихлас күңелдән горурланасы урында, авторны эзәрлекләүдән, үчләшеп (бәлки көнләшеп тә), аның исемен әдәбият һәм фән тарихыннан сызып ташларга ашкынудан башка гамәл түгел. Һәм күәтләп әйтәм: «Идегәй» дастанына яңача карашымны һәм табышларымны белдереп (җөмләдән, беренчеләрдән булып, Туктамыш хан башыннан, киселгәч, ни өчен сөт, ә Идегәй башыннан, киресенчә, кан агуның серен аңлатып) язылган, шулай ук әдәби тәнкыйтьтә югары бәя алган хезмәтемнең элек миннән фольклор курсын тыңлаган шәкертемнең компилятив характердагы мәкаләсе белән алмаштырылуы да шуны ук раслап тора.

Әгәр дә яңартылган басмада минем материаллар, бракка чыгарылып кире кагылган икән, бәлки аларда җитди ялгышлар яки зарарлы фикерләр булгандыр? Киресенчә, рецензентлар тарафыннан уңай бәяләнгән безнең материаллардан аермалы буларак, алар урынына тәкъдим ителгән мәкаләләрдә җитди хаталарга юл куелган. Менә шуны раслый торган бер гыйбрәтле мисал. Икенче томда басылган «Чура батыр» дастанына багышланган мәкаләдә (авторы Лилия Мөхәммәтҗанова) әлеге каһарманның прототибы, үзенең һәм әтисе Нәрыкның исеме туры килүгә карап кына, Казан ханлыгының бәге Чура Нарыков булган, дип күрсәтелгән. Асылда әлеге тип – Мәскәү кенәзлеге гаскәре белән Казанны яуларга килергә чакырып, явыз Иван Грозныйга ике тапкыр хат-грамоталар җибәргән һәм Сафа-Гәрәй ханны Мәскәү тарафдары (марионеткасы) Шаһгали белән алмаштыруда катнашкан сатлык җан. Хыянәте, үз дәүләтен юк итү сәясәте алып барганы өчен, соңыннан ул, яраннары белән Мәскәүгә качып барган чагында тотылып, җәзалап үтерелгән. Сүз уңаеннан өстик: Ф.Урманчеев исеме белән бәйле бу тамырдан ялгыш караш, ягъни әлеге сатлык җанны Чура батырның прототибы итеп карау хәтта «Татар энциклопедиясе»нә дә үтеп кергән.

Казах эпосын махсус өйрәнгән белгечләрнең (Ә.Диваев, А.С.Орлов һ.б.) мәгълүматларына караганда, Чура Нәрык исеме белән бәйле дастан исә беренче башлап Казахстанның Кече Җүз биләмәләрендә күченеп йөргән нугайлар һәм казахлар арасында иҗат ителгән һәм анда җирле казахларның, Алмалык төбәгендә урнашкан Казан исемле каланы яклап, калмыкларга (ойротларга) каршы көрәше тасвирланган.

Соңыннан инде казахлар җирендәге Казанның Урта Идел буендагы Казан белән бер үк исем йөртүеннән чыгып, «Шура батыр» (тагын бер варианты «Нәрык») дип исемләнгән казах дастаны, мөгаен, нугайлар ашадыр, татарларга үтеп кергән һәм әсәрнең баскычлы калмыкларга каршы көрәш сюжеты руслар белән Казан ханлыгы арасында булган сугышка яраклаштырылган. Бу инде, димәк, эпос-дастанның татар версиясендә тасвирланган Нәрык улы Чура дип аталган каһарманның Казан бәге сатлык җан Чура Нарыков белән – исемнәренең формаль охшашлыгыннан башка – бернинди дә уртаклыгы юк дигән сүз.

Чураның ханлык мәркәзе Казанны саклаган реаль шәхес булганлыгын инкяр итә торган ышанычлы тарихи документ та бар. Кол Шәрифнең «Зафарнамәи вәлияти Казан» («Казан мәмләкәтенең җиңү бәяны») дигән әдәби тарихи-публицистик характердагы әсәрендә (академик Индус Таһиров бу әсәрне, Төркиядә табылуыннан чыгып, дин башлыгының төрек солтаны Сөләйманга ярдәм сорап язган хаты итеп карый), гәрчә 1550 елда Казанны саклауда катнашкан күренекле реаль батырларның исемнәре хәтта берәм-берәм аталып күрсәтелсә дә, алар арасында Чура исеме юк.

Югарыда сөйләнгәннәрдән соралып торган төп нәтиҗә шул: дастандагы Чура батыр образы конкрет шәхеснe гәүдәләндерүче каһарман түгел, ә җыелма образ булырга тиеш. Асылда аның прототибы – Казанны саклап көрәшкән һәм сугыш мәйданында корбан булган дистәләр һәм йөзләрчә батырлар. «Чура» сүзенең батыр, каһарман сугышчы дигән мәгънәгә туры килүе үзе үк берләштерерү һәм гомумиләштерү сыйфатына ия булганны күрсәтеп тора.

Халыкта: «Кешенең кем булуын беләсең килсә, кулына власть биреп кара», – дигән акыллы гыйбарә бар. 8 томлык «Татар әдәбияты тарихы» әле күптән түгел генә нәшер ителүенә карамастан, янә ничәмә миллион сумнарга төшереп, аның яңа басмасын чыгарырга алынуы, миңа калса, ошбу җитәкчебезнең, үз рәсми статусыннан файдаланып һәм башбаштаклык күрсәтеп, безнең налог-салымнар исәбенә җыелган хөкүмәт акчасын үз белдеге белән соралмаган урынга сарыф итүенә кайтып кала түгелме?!

(Дәвамы 4 нче биттә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Тәшвишле дата

Бүген РФ гаскәрләренең Украинада махсус хәрби операция (МХО) үткәрә башлавына нәкъ бер ел булды. Россия Президенты В.Путин аның максатларын Донбасста кешеләрне Киев режимының 8 елга сузылган җәфалавыннан һәм «геноцид»тан азат итү буларак билгеләде, бу илдә «демилитаризация» вә «денацификация» үткәрү кирәклеге турында да белдерде. Ул шулай ук Мәскәү планнарына Украинаны оккупацияләү бурычы кермәве, аның беркемгә һәм бернәрсә дә көчләп тагарга җыенмавы хакында да әйтте. Бу язмада ул чакта алга куелган максатларның ни дәрәҗәдә үтәлүе турында сүз куертып тормабыз (аны һәркем ирешелгән нәтиҗәләр белән чагыштырып та белә ала). Бүген исә игътибар үзәгендә күбрәк ил-көндә бу дата белән бәйләп үткәрелгән кайбер чаралар вә урын алган ишарәле вакыйгалар булыр.

Сүзне, әлбәттә, МХО үткәрелә торган төбәкләрдән башлап җибәрергә туры килә. РФ Саклану министрлыгының рәсми вәкиле И.Конашенков 5 февральдә Россия гаскәрләренең Донецк һәм Красный Лиман, шулай ук Южно-Донецк һәм Запорожье юнәлешләрендә актив һөҗүмгә күчүләре, нәтиҗәдә, бу юнәлешләрдә гаскәрләрнең отышлырак позицияләр биләве турында белдергән иде. Ә соңгы көннәрдә берничә торак пункт (Красная Гора, Гряниковка, Клещеевка, Подгорное авыллары) алынуы турында да хәбәрләр (ә кайберләре турында хәтта кат-кат хәбәрләр дә) булды. Күптән түгел 4 хәрби округта командующийларның алыштырылуы да МХО зонасындагы хәлләрнең торышы белән бәйле булырга мөмкин. Ә 24 февраль уңаеннан үткәрелгән чаралар рәтенә, мөгаен, РФ Президенты В.Путинның Федераль Җыенга быелгы еллык юлламасын, шулай ук Федерация Советы утырышының 1 марттан 22 февральгә күчерелүен һәм кайбер башка чараларны да кертергә буладыр. «Лужники»да узачак митинг-концерт исә бу датага багышлап әзерләнгән махсус чара да булып тора. Җөмләдән, узган атнада РФ хөкүмәтенең яшьләрне алга таба да патриотик рухта тәрбияләү проектларына 38 миллиард сум бүлеп бирүе мәгълүм булды.

Россия президентының Федераль Җыенга еллык юлламасы быел «Гостиный двор»да бәян ителде (узган елда исә юллама юлланмыйча да калган иде). Башка еллардан аермалы буларак, быел бу чарага МХОда катнашучыларны да дәшкәннәр. Ә чит ил журналистлары нигәдер чакырылмаган. Шунысын да искәртеп үтик, юлламаны әзерләү вакыты быел МХО зонасында вәзгыятьнең кискенләшкән чагына гына түгел, ә аңа бәйле халыкара хәлләрнең катлауланган чорына да туры килде. Сәясәтчеләр игътибарын мәгълүмат чараларында Мәскәүнең Киевне террорчылыкта гаепләве, шулай ук МХО статусын үзгәртергә ниятләве турындагы фаразлар да җәлеп итте. Әлбәттә, сәяси һәм хокукый яктан, статус – мөһим нәрсә.

Юлламаның үзенә килгәндә, сәясәттәге кискен хәлләр аның эчтәлегендә дә чагылыш тапкан: икътисади һәм социаль проблемалар, эчке вә тышкы сәясәттәге төп юнәлешләр белән бергә, анда зур урын агымдагы сәяси вәзгыять һәм Украинада үткәрелә торган МХОга да бүленгән. Юлламада шулай ук, Кремльнең бүгенге сәясәтеннән чыгып, МХО барышына һәм халыкара хәлләргә сәяси бәя бирелгән, кыен хәлләрдән чыгу һәм илдәге проблемаларны уңышлы хәл итүнең тактик адымнары билгеләнгән, стратегик бурычлар да тәгаенләнгән. Әчынбарлыкка алар ни дәрәҗәдә җавап та бирә – монысын инде якын киләчәк һәм тормыш үзе күрсәтер.

Хәлбуки, тәшвишле датага багышланган күп кенә чаралар халыкара һәм дөньякүләм дәрәҗәләрдә дә үтте. Алары рәтенә инде узган атнада Алманиядә эшләгән Иминлек буенча Мюнхен конференциясен, АКШ президенты Джо Байденның 20-22 февраль көннәрендә Польшага сәфәрен һәм анда НАТОның сул фланг илләре – «Бухарест тугызлыгы» лидерлары белән очрашуын һ.б. чараларны китерергә була. Ә АКШ лидерының, башта Киевкә килеп, анда Украина президенты белән очрашуы һәм 500 миллион долларлык өстәмә хәрби ярдәм турында да игълан итүе инде күпләр өчен бөтенләй дә көтелмәгән вакыйга булды. Өстәвенә, МХО башлануның берьеллыгы уңаеннан ул әле Россия халкына да мөрәҗәгать итәргә җыена икән. Игътибарны исә БМО Генераль Ассамблеясенең (ГА) 22 февральдә Украина буенча эшен яңартачак 11 нче гадәттән тыш махсус сессиясе дә җәлеп итә. Ул Украинада тотрыклы, гадел һәм гомумколачлы тынычлык урнаштыруны максат иткән һәм нигезенә узган ел G20 саммитында Украина президенты В.Зеленский тәкъдим иткән «тынычлык планы» салынган яңа резолюция проектын кабул итәргә җыена икән. Кайбер мәгълүматларга караганда, ГА сессиясендә аның буенча тавыш бирү 23 февральгә билгеләнгән. Насыйп итсә, бу һәм кайбер башка чаралар хакындагы сүзебезне инде киләсе язмаларда дәвам итәрбез.

Фоат УРАЗАЙ.

Сарманда - «Илһам чишмәсе»

Былтыр декабрь аеның соңгы көннәрендә «Илһам чишмәсе» III төбәкара җыр бәйгесенең башлануы турында хәбәр ителгән иде. Ул Бөтендөнья татар конгрессы, Сарман районы Башкарма комитеты, «Меги» оешмасы (җитәкчесе – бәйгенең оештыручысы һәм меценаты Илдар Гамиров), «Ак калфак» татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы белән берлектә оештырылды. Мәшһүр җырчы Илһам Шакировның иҗатын таныту, аның исемен мәңгеләштерү, яшь буынны шушы рухта тәрбияләү һәм аларның халкыбыз традицияләрен күреп-белеп үсүен максат иткән бәйгенең сайлап алу туры Бөтендөнья татар конгрессы бинасында үтте.

Конгрессның Башкарма комитеты рәисе Данис Шакиров ул чакта «Ялгыз вокал» номинациясендә уза торган конкурска катнашучылардан 150 дән артык гариза кабул ителүен хәбәр итте. Дәрәҗәле жюри бәйгедә катнашучылар иҗатын 6-9 яшь, 10-12, 13-16, 17-21 яшькә кадәр төркемнәргә һәм категорияләргә бүлеп бәяләгән. Төп игътибар катнашучының башкару осталыгы (вокаль алым, эмоциональлек, артистлык, башкару үзенчәлеге), музыкаль бизәлеш, костюмнар сайлау үзенчәлегенә бирелгән.

Шушы көннәрдә Татарстанның Сарман районы җирлегендә «Илһам чишмәсе» III төбәкара җыр бәйгесенең икенче этабы үтте. «Сәнгать бәйрәме эшмәкәр Миләүшә һәм Илдар Гамировларның матди ярдәме белән Сарманның үзәк мәйданына куелган Илһам Шакиров һәйкәленә чәчәкләр куюдан башланды», – дип хәбәр итте Бөтендөнья «Ак калфак» татар хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы җитәкчесе, жюри әгъзасы Кадрия Идрисова.

Сайлап алу туры Илһам Шакиров исемендәге сәнгать мәктәбендә узды. Катнашучыларның башкару осталыгын Татарстанның халык артисты Зөһрә Шәрифуллина, виртуоз баянчы, Татарстанның атказанган артисты Азат Хәлимов, җырчылар, ТНВ каналында «Җырлыйк әле» телевизион тапшыруын алып баручы Алинә һәм Азат Кәримовлар, эшмәкәр Илдар Гамиров, «Ак калфак» оешмасы рәисе Кадрия Идрисова, «Ак калфак» оешмасы советы һәм оештыру комитеты әгъзасы Миләүшә Гамирова, «Илһам чишмәсе» бәйгесенең оештыру комитеты әгъзасы Алмаз Нургалиев (режиссеры һәм сценарий авторы) бәяләде. Сайлап алу турында һәм гала-концертта Казан консерваториясе профессоры Әбүзәр Фәйзуллин, драматург Мансур Гыйләҗев, мәшһүр җырчыбызны караган Илһам Хаҗиев, Илһам Шакировның бертуган абыйсы Флер ага Кыямов катнашу да бәйгене бизәп җибәрде. Ә иң күңеллесе – Ф.Кыямовның кызы Миләүшә башкаруындагы җыр икенче урынга лаек булды.

Сайлап алу турында Актанаш районы балалары аеруча яхшы әзерлекле булулары белән аерылып торган. Актанаш хакимият башлыгы Ленар Зариповка Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васыйл Шәйхразыевның һәм медиакомпаниянең рәхмәт хаты тапшырылды.

С. КЫЯМОВА.

Мәрҗани мәчетендә яд мәҗлесе

Халкыбыз талантлы, галим шәхесләргә бай. Февраль ае гына да безгә – татар халкына шактый мәшһүр затларыбызны бүләк иткән.

Әйтик, 14 февральдә мәгърифәтче, тарихчы, этнограф әдип Каюм Насыйри, 17 февральдә дин галиме, мөдәррис-педагог, җәмәгать эшлеклесе, җәдидчелек хәрәкәте идеологы Галимҗан Баруди дөньяга килгән. Ә инде 15 февраль милләтебезгә татар халкының сөекле уллары – патриот шагыйрь, Советлар Союзы Каһарманы Муса Җәлил һәм татар моңын дөньяга танытуга, милләтебезне берләштерүгә гомерен багышлаган легендар җырчыбыз Илһам Шакировны бүләк иткән. 19 февраль – татар поэзиясенең күренекле вәкиле, дошман пулясыннан һәлак булган Фатих Кәрим арабыздан киткән көн.

Казанның Ш.Мәрҗани мәчетендә татар халкының шушы олуг шәхесләренең (палач балтасыннан гомерләре киселгән 10 җәлилченене дә кертеп) һәркайсының исемнәрен әйтеп, алар рухына багышлап Коръән уку мәҗлесе узды. Аны Мәрҗани мәчетенең имам-хатыйбы, Казан шәһәренең Аксакаллар шурасы рәисе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов ачып җибәрде. Ул халкыбызның «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» дигән әйтемен хәтергә төшереп, милләтнең горурлыгы булган шәхесләребезне һәрвакыт дога кылып искә алу кирәклеген әйтеп үтте. Имам-хатыйб шул ук вакытта абыстайларга оныклар белән туган телдә генә аралашу кирәклегенә дә басым ясады. «Мәшһүр, бөек затларыбыз халкыбыз өчен көрәшкән, утка кергән, иҗтиһат иткән, тормышларын милләтебезгә багышлаган. Әмма соңгы елларда балаларыбыз нигездә телебезне онытып бара. Яһүдләр

татарлардан дүрт тапкыр кимрәк, аларның Мәскәүдә 12 милли мәктәбе бар. Ә безнең Мәскәүдә бер мәктәп бар, анда да белем туган телебездә бирелми. Мәрҗани, Баруди, Җәлил, Каюм Насыйри, Фатих Кәрим һ.б. эстафетасын лаеклы дәвам итәргә тиешбез», – диде ул.

Мәрҗани мәчете хәзрәтләре Коръәннән сүрәләр һәм аятьләр укыдылар, аннары Әнсар хәзрәт Мифтахов динебез, милләтебез өчен хезмәт куйган кардәшләребезнең исемнәрен атап дога кылды.

Искә алу мәҗлесенә гыйлемле остаз-абыстайларыбыз җыелган иде. Ир-атлар булганда, хатын-кызларга сүрәләр укып утыру ярамавын искәртеп, хәзрәтләр киткәч, абыстайларыбыз Изге китабыбыздан аять-сүрәләр яңгыратты. Аннары Татарстан Милли музей хезмәткәре Флюра Дәминова – Ф.Кәрим, шагыйрә Йолдыз Шәрәпова – А.Алиш, абыстай Рәдилә Сабитова Г.Барудиның тормышы, иҗаты, халкыбыз өчен кылган гамәлләре белән таныштырды.

Сөембикә КАШАПОВА.

Автор фотосы.

1 нче биттә – Бөек Ватан сугышында җиңүнең 77 еллыгы уңаеннан Казан гарнизоны һәм махсус хәрби подразделение гаскәрләренең тантаналы йөрешеннән бер күренеш. Фото: rais.tatarstan.ru

«Җәлил укулары» офыкларын киңәйтә

Казанның «Сәйдәш» мәдәният үзәгендә V Халыкара «Җәлил укулары» әдәби бәйгесенә йомгак ясап, җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы үтте.

Быел Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Мәдәният, Мәгариф һәм фән министрлыклары белән берлектә оештырылган әлеге бәйгегә Россиянең 38 төбәгеннән һәм чит илләрдән (Азәрбайҗан, Беларусь Республикасы, Болгария, Кыргызстан, Казахстан, Үзбәкстан) 40 меңнән артык гариза кабул ителгән. Хәтта көтелмәгән Сербия, Япония кебек илләрдән дә катнашучылар булган. Әлбәттә, конкурсантлар арасында күпчелеге татарлар булса да, башка милләт вәкилләре дә хәтсез. География, катнашучылар ягыннан да бу биш ел дәвамында казанышка ирешкән беренче уңышлы конкурс. Бәйгенең II этабыннан финалга 836 катнашучы тәгаенләнгән. Аннары декабрь ае ахырында жюри карары нигезендә барлыгы 115 җиңүче билгеләнгән.

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров «Сәйдәш» мәдәният үзәгенә килүчеләрне, ягъни җиңүчеләрне Милли шура рәисе Васил Шәйхразыев исеменнән сәламләде. Ул 2019 елда 4000 катнашучыдан башланып киткән бәйгенең биш ел эчендә халыкчан булып китүен искәртте. Быел иң яшь катнашучы Чиләбе өлкәсеннән булган, аңа – 3 яшь, иң өлкәненә – 89 яшь, ул Нижневартовскидан. «Саннар әдәби бәйгенең тулы хәрәкәткә әверелүе турында сөйли. Муса Җәлил – халкыбызның сөекле улы, батырлык һәм каһарманлык символы», – диде Д.Шакиров.

Башкарма комитет җитәкчесе шулай ук Бөтендөнья татар конгрессының Россия төбәкләрендә дә җирле хакимият белән берлектә Муса Җәлилнең исемен мәңгеләштерүдә бик күп эшләр башкарылуын искә алды. Төрле шәһәрләрдә патриот-шагыйрь исемендәге мәктәпләр, урамнар бар, бюстлары куелган. Быел исә Казахстанның Җидепулат, Сәмәй шәһәрләрендә Муса Җәлил исемен татар бакчасына биреп, каршыдагы мәйданда бюст кую ниятләнә. Якутиядә дә Муса Җәлил бюсты ачылачак. Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчелеге бу эшләрнең дәвамлы булачагына ышандыра.

«Муса Җәлил Җир шарының барлык кыйтгаларында яшәгән халкыбызны уятты», – ди Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, режиссер, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, конкурсның жюри рәисе Рамил Төхфәтуллин. Ул шулай ук чыгыш ясаучыларның ихласлыгына, эчтәлеккә мөнәсәбәтенә, әзерлегенә игътибар иткән. «Бәйгедә катнашучыга бәя биргәндә аның әсәрне аңлау дәрәҗәсе, сөйләүченең хисләре, самимилеге кебек сыйфатлары исәпкә алынды. Чын мәгънәсендәге талант ярылып ята һәм күренә», – диде ул.

Әйе, әдәби бәйгенең дөнья күләмендә узуы милләтебезгә горурлык өсти. Халкыбыза, татар сүзен дөньяга яңгыратыр өчен Аллаһтан бүләк итеп бирелгән шагыйрьнең шигырьләре бүген 23 телдә яңгырап, жюри игътибарына тәкъдим ителгән. Арада катнашучыларның Муса Җәлилгә, аның батырлыгына багышланган шигырьләре дә булган.

Бәйгене йомгаклау кичәсе фронттагы сугышчыларга хатлар тапшыруны чагылдырган сәхнә күренеше белән ачылып китте. Күз алдына яу кырындагы Муса Җәлилнең дә кызы Чулпаннан, хатыны Әминәдән хәбәр алуы күз алдына килеп басты. Бүген исә Чулпан ханым кичәнең кадерле кунагы иде. Конкурста катнашучылар шагыйрьнең сәхнә экранында күрсәтелгән кечкенә Чулпан белән бергә төшкән фотолары фонында Муса Җәлилнең кызына атап язган шигырьләрен яңгыратты. Гомумән, сәхнәгә чыгучыларның, хәтта кечкенә кызчык-малайларның да Җәлил шигырьләренең һәр сүзен аңлап, күңеле аша уздырып сөйләвенә игътибар итми мөмкин түгел иде.

Конкурста җиңүчеләрне тәбрикләргә сәхнәгә күтәрелгән «Китап» радиосы баш мөхәррире, жюри әгъзасы Алмаз Миргаязов Муса Җәлилнең рухын шушы рәвешле куандыруга сөенеч кичерүен белдерде. «Залны тутырып Муса Җәлилгә, әдәбиятка, сәнгатькә гашыйк кешеләр утыра. Шигъриятнең, мәдәниятнең модасы төшеп барганда, балалар кулына гаджетлар кереп утырганда, мондый күренешнең булуы, һәм аның елдан-ел көчәя баруы – зур шатлык», – диде ул.

Татарстанның атказанган артисты, жюри әгъзасы Инсаф Абдулла үз буыны кебек, бүгенге яшьләребезнең дә җәлилчеләр үрнәгендә тәрбияләнеп үсүен телгә алды. «Каһарманлык, ватанпәрвәрлек хисләрен балачактан сеңдермәсәк, соңыннан байрак күтәреп йөрер кенә, бернигә дә ирешә алмыйбыз», – диде ул.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

Яңа сигезтомлык ник кирәк?

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Әлеге дуамал адымына рәсми һәм законлы төсмер бирергә тырышып, махсус конференция оештыруы һәм дә койрык болгаучылар, аумакайларның хуплавы ярдәмендә ике мең еллык әдәбият-сүз сәнгате мирасыбызга «ревизия» ясарга алынуы – асылда, каш төзәтәм дип күз чыгару белән бер. Чөнки кире каккысыз фактлар раслаганча, сүз җитәкче ханымның ирешелгән «уникаль» фәнни ачышларны урынсыз кире кагуы, хәтта тарихи һәм идеяви фальсификациягә юл куюы турында бара. Әгәр инде әдәбиятыбыз тарихында ниндидер урынлы төзәтүләр һәм өстәүләр соралган булса, зур чыгымнарга бармыйча, редколлегия әгъзалары һәм авторлар белән алдан сөйләшеп, андый үзгәрешләрне беренче басмада ук хәл итеп булыр иде ләбаса! Һич югында, өстәмә материаллар кертеп, кушымта том чыгару белән дә чикләнеп булыр иде.

Өстәп әйтергә кирәк, 2007 елда Д.Заһидуллина редакторлыгында (икенче фәнни редактор Т.Галиуллин) «Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге» басылып чыккан иде. Белгечләр арасында әлеге сүзлекнең шактый дәрәҗәдә рус хезмәтләре йогынтысында төзелгәнлеге турында сүз булды. Моны раслау өчен, әйтик, революциягә кадәрге иҗат методлары турында әлеге сүзлектә басылган мәкаләләрдә (авторы Д.Заһидуллина) татар дөньясына хас булган һәм мәгърифәтчелек реализмы белән үрелгән җәдитчелек хәрәкәтенең махсус «җәдит» исеме белән телгә алынмавын, янә килеп, традиция буенча әдәби сүзлекләргә кертелә торган дастан, җыр, мөнәҗәт, сыктау, әйтеш, такмаза, келәү, чичән, җырау кебек атамаларның, шулай ук гарәп-фарсылардан кергән тәхәллүс, робагый, хәмсә, тәзкирә, рисалә, васыятьнамә, кыйсса, мәснәви, мәкам, хикмәт, нәзыйрә кебек соралып торган терминнарның сүзлектә кертелми калуына игътибар итү дә җитә. Сүзлектә кулланылган чыганаклар арасында, әлбәттә инде, минем «Татар фольклоры» дигән китабыма һәм шигырь төзелешен өйрәнүгә багышланган хезмәтләремә урын табылмаган (хәлбуки, мин Д.Заһидуллинаны халык иҗатына һәм шигырь мөнәсәбәтле терминнар белән сүзлектә катнаша алуым турында алдан ук искәрткән булсам да).

Әллә кайчаннан бирле әзерләнеп килгән 25 томлык халык иҗаты тупланмасының нибары бер томы гына чыккан вакытта, «атай малы катай» рәвешендә эш итеп, Академия бюджетының шактый зур өлешен, үз белдегенчә, кабат моннан алда гына миллионнарча чыгымнар тотылган бер үк өлкәгә бүлеп җибәрүе – аеруча хәтәр югалтуларга китерә торган яман шөгыльләр. Бу инде, димәк, әдәп-әхлак һәм хокук нормаларын санга сукмау, күрәләтә бозу юлына баскан тотрыксыз җитәкчелекнең кырын эшләре йомып калдырылырга тиеш түгел, ә җәмәгатьчелеккә фаш ителеп, автократик башбаштаклыгына чик куелырга тиеш дигән сүз.

РЕДАКЦИЯДӘН: Без Башкортстанга дистәләрчә тапкыр сәяхәт кылганда, Уфа каласының китап кибетләрендәге киштәләрдә «Башкорт әдәбияты тарихы»ның – 16 том, «Башкорт теленең академик сүзлеге» – 10, «Башкорт халык иҗаты»ның – 18 том булып тезелеп торуын күреп, хәйран калдык. Әле кичә генә 16 томлы «Башкортстан авылларының тарихы», 47 томлы «Башкорт ырулары тарихы» сатыла иде, инде юкка чыккан. Ә бездә «Татарстан авыллары тарихы» дигән сыңар китап та юк. Мөхтәрәм авторыбызга кушылып, Фәннәр академиясе яки фәнни институтлар югарыда саналган күптомлыкларга тиң хезмәтләрне тудыру һәм халык кулына китереп җиткерү өчен ни эшли соң? – дип сорарга мәҗбүрбез.

● Җирнең якынча 70 проценты су белән капланган, тик әлеге суның нибары бер проценты гына эчәргә яраклы.

● Диңгез буйлап йөк ташу шулкадәр арзан ки, шотландиялеләргә тоткан балыкларын 16 мең чакрымдагы Кытайга җибәреп, аннан филе хәлендә кире кайтарту файдалырак булып чыга.

● Җирдә агачлар саны безнең галактикадагы йолдызларга караганда күбрәк. NACA фаразлавынча, Киек Каз Юлы галактикасында якынча 100-400 миллиард йолдыз бар, планетабызда агачлар саны исә 3 триллионнан артык.

● 1 фунт (454 грамм) шоколад җитештерү өчен кимендә 400 какао орлыгы кирәк. Дөньяда иң кыйммәтле шоколад Chocopologie by Knipschildt бренды белән чыгарыла, аның 1 фунты 2500 доллар тора.

СЫЙФАТСЫЗ ҖАНИСӘП

Соңгы җанисәп нәтиҗәләре буенча Россиядә татарлар саны 600 меңгә кимегән. Әмма тарихчы, этнолог Дамир ИСХАКОВ җанисәп саннарына ышанмаска чакыра. Аның фикеренчә, Татарстанга федераль хакимият алдында бу мәсьәләне аерым күтәрергә кирәк.

2022 елның азагында игълан ителгән Росстат саннарыннан күренгәнчә, хәзер Россиядә 4,71 млн татар яши дип санала. Татарлар саны Татарстанда гына арткан – 78 мең кешегә. Шул ук вакытта Башкортстанда татарлар 34,7 меңгә кимегән, ә менә башкортлар 96,5 меңгә арткан. Идел-Урал төбәкләрендә татарлар саны бермә-бер кимегән: Оренбург өлкәсендә 35 меңгә, Сембердә – 40 меңгә якын, Самарада – 30 мең, Свердловск өлкәсендә – 50 мең, Мәскәүдә 65 мең чамасы татар юкка чыккан.

Россия халык санын алу нәтиҗәләреннән татар телендә сөйләшүчеләрнең 1 миллионга кимүен, татарның картаеп баручы милләт булуын да күрергә була.

Җанисәптә 147,2 миллион кешедән 130,6 миллионы гына милләтен күрсәткән. 16,6 миллионы бу сорауга җавап бирмәгән.

– Әле 2010 елгы җанисәп алдыннан сез 2025 елга татар халкының саны ярты миллионга кимиячәк дип фаразлаган идегез. Бу халык санын алуда ук татарлар 600 меңгә азайды. Ике җанисәптә 840 мең татар юкка чыккан. Бу сезнең өчен көтелмәгән саннар булдымы?

– Билгеле, татарларның саны бик нык үсми, чөнки бала табучылар аз. Әмма без бүгенге демографик хәлдә дә үзебезнең саннарны саклап кала алабыз. Ләкин татарның саны кимүендә башка сәбәпләр дә бар.

Беренче чиратта, соңгы халык санын алуның үзенчәлекләрен исәптә тотарга кирәк. Ул ковид шартларында башланды. Бу вакытта беркем дә беркемне өенә кертми һәм кертергә теләми иде. Икенчедән, статистика белән эшләүчеләрнең эше бик начар оештырылды. Нәтиҗәдә җанисәп алу фаҗигале төстә тәмамланды. Иң дәрәҗәле демографлар да бу статистик нәтиҗәне бернәрсәгә дә ярамый дип таныды. Моны үзем дә күзәттем. Казан эчендә фатирларга кереп йөрү булмады. Танышларның берсенә дә кермәделәр. Димәк, Татарстанда да нәтиҗә шундый ук.

2010 елгы җанисәп алдыннан мин Тишков (В.Тишков – Россиянең Этнология һәм антропология институты директоры) белән сөйләшкән идем. Халык санын алучылар зур шәһәрләрдә фатирларның өчтән беренә керә алмый дигән иде ул. Аларның санын полиция чыганакларыннан алалар. Анда барыбыз да исәптә. Әмма полиция чыганакларында канун нигезендә милләт һәм туган телне күрсәтергә ярамый. Бу татар санын киметүгә этәргеч булды.

Тагын бер сәбәп: татарлар хакимият органнары вәкилләрен яратмый. Безнең халык җанисәпкә дә шулай карады. Моннан тыш, Башкортстандагы вәзгыять өстәлде. Татарстан Башкортстан эчендә юньләп эшли алмады. Хакимият тә безнең итәктән тартып торды. Әйе, пропаганда белән шөгыльләндек, мин 37 видеоязма әзерләдем, аны 270 мең кеше карады. Ә менә Башкортстан эченә кереп, милли оешмаларны аякка бастырып эшли алмадык. Бу Татар конгрессының эше сүлпән булуы белән бәйле. Тик чын, физик татар юкка чыкмады. Алар бар, фәкать саналмады.

– 2002 һәм 2010 елда да полициядән мәгълүмат алу булган. Ул вакыттан соң нәрсә үзгәрде?

– Ул чакта җанисәп сыйфатлырак узды. Элекке халык санын алуда мәгълүматның 4-5 проценты гына полиция чыганакларыннан алынган булган, хәзер ул өч тапкырга артты. Шул сәбәпле халык санын алуда милләтсез кешеләр ишәйде. Моннан тыш, татарлар эре шәһәрләрдә яши. Мин әйткән иң күп кимчелекләр зур шәһәрләрдә таралган.

– Хәрәмләшүләр булган дип санныйсызмы?

– Монысы тора-бара ачыкланыр әле. Милләтләрнең җенес, яшь, төрле төбәкләргә барып урнашуын өр-яңадан тикшерергә кирәк. Бу саннарны бик нык шомартырлар, чөнки җанисәп «алучылар» югары даирәдә җавап тота.

– Әстерхан һәм себер татарлары, керәшеннәр, мишәрләр татар исәбендә саналганмы?

– Керәшеннәр татар эчендә саналган. Себер татарларын аерым да язалар. Әстерхан татарларын аерым санауның мәгънәсе калмады, алар юкка чыкты. Чөнки Әстерхан татарларының бер өлеше нугайлар эченә керде, шуңа күрә Әстерхан өлкәсендә татарлар саны 20 меңгә кимеде. Нугайларга моннан файда булмаячак, алар аз санлы милләт.

– Болгар дип язылучылар саны нык кимегән. 2010 елда үзен болгар дип 4 мең кеше санаса, хәзер 694 кә калган.

– Бу «Болгар әл-Җәдит» клубының эгъзалары инде. Бәлки, аларга мөфти Тәлгать Таҗетдин дә кушылгандыр. Соңгы вакытта ул үзен болгар дип атый. Тик алар саны үсми. Соңгы фәнни җыеннарда да болгарчылар күренми. Болгарчылык мәктәбе ахырына кадәр җимерелеп төште, бәлки шул да йогынты ясагандыр. Нормаль кеше үзен болгар дип атый алмый.

– Татарстанда татарлар саны 78604 кешегә артса да, гомум халык исәбенә караганда, аларның өлеше кими – 53,15 проценттан 52,22 процентка төшкән. Урыслар 73435 кешегә арткан – 39 процент. Республикада миграция көчле. Татарстанга күчеп килүчеләрнең күпчелеге башка халык дигән сүзме?

– Татарстанга татар булмаган милләт вәкилләре килә. Татарларның бер процентка кимүе шуның нәтиҗәсе. Хакимият бу хакта уйламый, гигант төзелешләр алып бара. Үзебездә эшче көчләр бетте, авыл халкы кимеде. Читтән кеше китереп, икътисадны үстерәбез дип, моның тискәре яклары булуын уйламыйлар. Икътисадны үстерсәң дә, ул акчалар Мәскәүгә китә. Моның төп йогынтысы татарның саны кимүенә китерә. Әмма тагын бер кат кисәтәм, татарның бер өлеше исәпкә алынмады, Татарстанда да җанисәп юньле-рәтле узмады.

– Бу Татарстанда татарлар санын киметү сәясәте түгелме?

– Бу – Мәскәүнең күптәнге хыялы. Шул юл белән мигрантлар агымын көйләү дә бардыр. Элегрәк Урта Азиядән кайтучы татарларны Татарстанга кертмәскә тырышалар, аларга квоталарны башка төбәкләрдән бирәләр иде.

– 2010 елда сез Башкортстанда башкорт итеп язылган татарларның 40% чамасы кире татарлыкка кайтты дип әйткән идегез. Бу җанисәптә башкортлар 96 меңгә артты, татарлар 35 меңгә кимеде. Нәтиҗәдә без күпме татарны югалттык?

– Җанисәп нәтиҗәләрендә 241 мең татар телле башкорт бар. Минемчә, югалган татарлар да шул чамадыр. Башкортстанда 2002-2010 еллар арасында 200 мең татар башкорт дип язылган килеш калды. Безнең башкорт «дуслар» тагын өстәгәннәрдер.

Башкортстан татарларының Татарстанга күчү процессы да бар. Моннан тыш, башкортларның бездән бер өстенлеге – алар арасында авылда яшәүчеләр күбрәк. Авылда бала күбрәк туа. Фальсификация дә юк түгел. Моны бөтен кеше сөйли, алдан сигналлар да булды.

– Чиләбе өлкәсендә башкортлар татарларның сан ягыннан узып киткән. Татарлар өлкәдә 180 меңнән 120 меңгә калган, ягъни 60 меңгә кимегән. Башкортларда кимү азрак – 34 мең. Хәзер Чиләбе өлкәсендә 128 мең башкорт яши дип санала. Моны ничек аңлатырга?

– Ике сәбәбе бар. Беренчедән, җанисәп сыйфатсыз узды. Эре шәһәрләрдә күп кеше халык санын алучыларны кертмәде. Икенчедән, Чиләбе кебек шәһәрдә ассимиляция дә бара. Башкортлар күбрәк авылларда яши, алар күбрәк бала таба. Аннары, татарлар көчле вакытта, катнаш гаиләдә үскән балалар татар булып языла иде. Хәзер татарлар бераз сүрелгәч, ата-аналар балаларын урыс дип яздырадыр, бәлки.

– Гомумән, Идел-Уралда татарлар саны нык кимегән...

– Бу демографик хәл түгел. Ун ел эчендә мондый югалту була алмый. Әгәр ун елдан соң Россиядә демократик җәмгыять оешса, без татарларның чын санын күрербез.

– Соңгы елларда милли җәмәгатьчелек Казан Идел-Урал төбәкләре белән начар эшли, дип тәнкыйтьләп килде. Татар конгрессы татарлар аз яшәгән Якутия, Бурятиягә бару, чит илгә кунакка йөрү белән мавыкты. Татарлар күпләп яшәгән төбәкләр читтә калды. Идел-Уралда яшәгән татарларның саны кимүенә бу да тәэсир иттеме?

– Бу Башкортстанга гына кагыла. Татарстан башка төбәкләр һәм милли оешмалар белән эшли. Мин барлык мишәр зоналарында булдым. Оренбург якларында йөрдек. Эш нормаль бара. Шуңа күрә бу сәбәп була алмый. Менә Башкортстанда без эшли алмыйбыз да, эшли белмибез дә.

– Россиядә татарларның 600 меңгә, башкортларның нибары 12 меңгә кимүенә нинди дә аңлатма бирергә мөмкинме?

– Хәзер Татарстан җитәкчеләре без барлык татар милләте өчен җавап бирәбез дип сөйләргә ярата. Чын сәясәттә шуны тормышка ашырырга да тырыша. Әмма бүген татар җәмәгатьчелеге бу җитәкчеләр алдына «Мәскәү безнең 600 мең татарны кая куйды?» – дип сорау куя. Татарстан сәясәтчеләре федераль хакимияттән әлеге нәтиҗәләр өчен җавап бирүне таләп итәргә тиеш. Әмма алар бу мәсьәләне күтәрмәс, чөнки куркалар. Ә бирергә тиешләр. Аларга барыбер бу сорауны бирергә туры киләчәк.

– Җанисәпнең әлеге нәтиҗәләрен Татарстанга басым буларак кабул итәргә мөмкинме? Президент атамасын үзгәртүдә ыгы-зыгы тудыру да Мәскәүгә ошамагандыр.

– Мәскәүнең басымы көчле, аларның хыялы – милли республикаларны юкка чыгару. Моңа шөбһәләнергә ярамый. Республикаларны әкрен-әкрен генә юкка чыгару бара. Чынлыкта Мәскәүгә бер халык та ошамый. Бәлки, аларга чын урыслар да ошамыйдыр әле.

– Татар телен белүчеләр 1 миллионга кимегән. Бүген татар телен 3,26 млн кеше белә, 2,91 кеше көндәлек тормышта куллана. Татарстанда яшәүчеләрнең 1,5 миллионы гына татар телен белә. Моңа нинди бәя бирәсез?

– Мин бу саннар да дөресләккә туры килмидер. Социологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, татарның якынча 70 проценты туган телне теге яки бу дәрәҗәдә куллана. Җанисәптәге пропорция полиция саннарын куллану нәтиҗәсендә килеп чыккан.

– Бу җанисәп татарның картаеп баручы милләт булуын тагын бер кат күрсәтте. Медиана яшенә карасак, татар белән урыс бер дәрәҗәдә – 41,6 һәм 41,7. Башкортларда бу күрсәткеч яхшырак – 40. Чеченнәр яшь милләт – 27,2. Бүген татарда хезмәт яшен узганнар милләтнең 26,6 процентын тәшкил итсә, балалар һәм яшүсмерләр 16,8 процент кына. Бер ун елдан татарлар табигый төстә ун процентка кимү куркынычы алдында торамы?

– Бу саннар дөрес, әлеге процесс бара. Бала тудыру булмаса, кимибез. Бүген ике бала белән генә милләтне үстереп булмый. Бу – трагик демография. Башка процесслар да бар. Хәзер ислам дине кире кайта. Мөселман гаиләләрендә баланы күбрәк табарга тырышалар. Анысы уңай күренеш. Шуның нигезендә генә фаразлар ясарга мөмкин. Бүген татарларның 80 проценты үзен мөселман дип саный. Мәчетләргә йөрүчеләр – 5-6 процент. Казанда да мөселман гаиләләре күп.

Халык санын алуда бер уңай күренеш тә бар: Татарстанда татарлар белем дәрәҗәсендә урыслар белән тигезләшкән һәм хәтта аларны узып та киткән. Урысларда бу күрсәткеч 15 процент булса, татарларда 20 процентка җиткән. Димәк, социаль яктан без алга киткәнбез. Без бик тиз үсәбез, ләкин туган телне югалта барабыз. Әлеге мәсьәләнең уңай һәм тискәре ягы шушы.

– Сез ун елдан Россиядә демократик җәмгыять оешса, татарларның чын санын күрәчәкбез дисез. Бүгенге вәзгыятьтә татар гаиләләре чит илгә китәргә мәҗбүр. Россиядә хәзерге хәл калса, ни көтелә?

– Россиядә демократия булса, татар янә 5 млннан артып китәчәк. Булмаса, без «ике йөз елдан соң инкыйраз»га барачакбыз булып чыга. Йөз елын үттек инде.

АЗНАКАЙДАГЫ ӘГЕРҖЕ

Әгерҗе – Азнакайдан Әлмәткә баручы юлның сул ягында урнашкан уртача зурлыктагы авыл. Якындагы урман, Мәнәүс елгасы авылга ямь өсти. Шәһәргә алты чакрымлык төзек юл илтә.

Архив чыганагыннан күренгәнчә, 1732 елда монда Казан өязенең Әгерҗе авылыннан ясаклы татарлар (30 ир-ат) күчеп килә. Болар Мәүлекәй Илмәтов (уллары Әмир, Хәлил, Искис – 1762 елгы документта исемен Фәезгә төзәтәләр), Ибрай Акманов (улы Абдул), Мусай Акманов (уллары Абрек – 1762 елгы документта Габбәс, Хәсән), Акманай Акманов, Бохар[мәт] (улы Бакый) һәм Кадермәт Тимәшовлар, Сөләйман Ишмәтов (улы Бакир), Киләй Ярмәчкин, Кәмәй Илмәков, Даут Ибраев, Гадел һәм Ишкенә Тимәшовлар, Мүкәй Сөләйманов, Аймәт Уразбахтин (улы Гомәр), Әхмәр Дусмәтов, Хөсәен Акманов, Мансур Кутуев, Абдулла Дусмәтов, Илкә[й] Бохармәтов, Кулай Әминков, Ишбулды Урманов була (РБАДА, 350 фонд, 2 тасв., 1154 сакл. бер.).

Төп халкы чыгышы белән Әгерҗедән булганлыктан, яңа барлыкка килгән авыл да шул исем белән атала. Шул чордагы чыганакларда «яңа нигезләнгән Әгерҗе» (документта «новопоселенная Агрыз») дип күрсәтелә.

Әмма яңа Әгерҗедә (Җөри юлы, Туйкә Абдулов йөзлегенә (сотнясына) керә) теркәлгән Әмир (41), Мәхмүт (35), Биктаһир (23) Мәүлекәевләр, Мансур Кутуев (59), Бакый Бохаров (39), Кадермәт Тимәшов (59), Абдул Ибраев (40) һ.б. ясаклы татарлар 1749 елда кире үз авылларына, Арча юлындагы Иске Әгерҗегә кайта. Ул авылда барлыгы 80 ир-ат һәм 69 хатын-кыз исәпләнә (Шунда ук, 1188 сакл. бер.).

1748 елгы халык санын алу документында яңа Әгерҗедә (чыганакта «новопоселенная Агрыз») 69 ир-ат ясаклы татар теркәлгән. Алар барысы Казан өязе Әгерҗе авылыннан күчеп килгән һәм Илбакый Исмәгыйлов йөзлегендә (сотнясында) тора (Шунда ук, 1142 сакл. бер.).

3 нче ревизия (1762 ел) вакытында Әгерҗедә 74 ир-ат ясаклы татар исәпкә алына. Шуларның берсе – Сөләйман Ишмәтов. Ул авылга нигез салучылар исемлегендә күрсәтелгән иде, озын гомер кичереп 1760 елда 85 яшьтә вафат була. Документта уллары Мөхәммәт (1762 елда 46 яшь), Бәкер (42), Биккол (20) турында да мәгълүматлар бирелә. Мәсәлән, Мөхәммәт йөзбашы («сотник») дәрәҗәсенә ирешкән. Тоба, Барҗы Омга һәм тагын ике авылдан 1758 елда берничә гаилә килеп утырган. Җөри юлының Иске Әгерҗе авылыннан да күченүчеләр була (Шунда ук, 3795 сакл. бер.).

Моңарчы бу җирләр Юрмый волосте биләмәчеләре (вотчинниклары) кулында була. Шуңа күрә үзара килешү төзелә: хуҗалар күченүчеләрдән берьюлы 40 сум оброк, ә соңгылары исә җиргә тулы хокук ала.

Емельян Пугачев җитәкчелегендәге Крестьяннар сугышы (1773-1775 еллар) башлангач, төбәктәге күпчелек авыллар, шул исәптән Әгерҗе, баш күтәрүчеләргә кушыла. Монда старшина Габдулла Ягъфәровның роле зур була. Чөнки фетнәгә чаклы авыл халкы аның кул астында булган. Старшина беренче көннән пугачевчылар сафына баса, карательләргә каршы сугышларда катнаша, әсирлеккә төшә һәм 1774 елның җәендә асып үтерелә.

Гасыр ахырында (1795 ел) Әгерҗе уртача зурлыктагы авыллардан санала. Анда 34 хуҗалык булып, 103 ир-ат һәм 87 хатын-кыз яши. Ярмөхәммәт Габбәсов гаиләсе Уфа казна палатасы указы нигезендә 1795 елда Оренбург янындагы Каргалы (Сәет) бистәсенә сәүдәгәр булып күченә. Биктимеровлар (2 гаилә) Түбән Сукаеш авылына күчеп утыра. Шуңа күрә Әгерҗедә 1782 ел (128 ир-ат һәм 109 хатын-кыз) белән чагыштырганда, халык саны кимрәк була (БР МА, И-138 ф, 2 сакл. бер.).

Бер гаилә (Таһир Бимәтов варислары) аерым теркәлгән. Болар берара Бөгелмә мещаннары саналып, Уфа казна палатасы указы нигезендә 1795 елда ясаклы татар сословиесенә күчә.

XIX гасырның беренче яртысында авылның үсешендә зур үзгәрешләр күзәтелми. 1816 елда 35 хуҗалык, 110 ир-ат һәм 112 хатын-кыз исәпләнә.

Авыл биләмәләрендә 2 су тегермәне була. Тегермән Елгада урнашканын – Зөбәер Әхмәров, Мәнәүстәгесен Урманайдан Абдул исемле кеше тота.

1834 елда Әгерҗедә беренче тапкыр типтәр сословиесендәге татар – Габдрахман Мәхмүтов (35 яшь) гаиләсе (3 ир-ат һәм 5 хатын-кыз) теркәлә. Бу нәсел монда 1775 елдан бирле яшәсә дә, моңарчы Бөгелмә өязенең Әлмәт авылында исәпләнгән (БР МА, И-138 фонд, 2 тасв., 578 сакл. бер.).

1859 елда Әгерҗедә типтәр сословиесендәге татарлар 11 ир-ат һәм 16 хатын-кыз (4 хуҗалык) була. Исемлектә беренче кеше булып указлы мулла Габдрахман Мәхмүтов (60 яшь; ике хатыны) күрсәтелә, аннары яңа килеп утыручылар – Ибәтулла Габдерәхимов (44 яшь; Кәкре Елгадан), Габделгани Сәйфуллин (39 яшь; Бөгелмә өязе Әлмәтмулла авылыннан), бертуганнар Әхмәтгали (22 яшь) һәм Сәфәргали (19 яшь) Корбангалиевләр (Чакмагыш авылы; 20 нче кантон). Алар документның титул битендә «башкорт», эчке битендә «типтәрдән башкорт» («башкиры из тептярей») дип язылган (Шунда ук, 757 сакл. бер.).

Типтәр сословиесендәге татарларның 1855 елдан «башкорт» дип язылa башлавы Самара губернасы белешмә әдәбиятында да чагыла. Аның мәгълүматы буенча, 1859 елда Әгерҗедә 218 ир-ат һәм 207 хатын-кыз (65 хуҗалык) казна крестьяннары һәм«башкорт»лар санала (Список населенных мест Российской империи. Т. 36. Самарская губерния. – С.-П, 1864). Монда казна (дәүләт) крестьяннары дип элеккеге ясаклы татарлар аталган.

Шулай итеп, типтәр сословиесендәге татарлар саны бик аз була. Ревизия чыганакларын белмәгәнгә, кайбер авторлар сословиеләре күрсәтеп үткәндә беренче итеп азсанлы «типтәр»ләрне яза.

Авылда элеккечә бер мәчет эшли. 1862 елдан имам-хатыйп һәм мөгаллим вазыйфасын Габдрахман Габдерәхимов башкара (БР МА,И-295 фонд, 3 тасв., 5662 сакл. бер.).



● Авылның 1732 елда нигезләнүен раслаучы документ фрагменты.

1884 ел ахыры – 1885 ел башында Әгерҗе Азнакай волостенда (аңа тагын Азнакай, Әсәй, Балтач, Туйкә, Сәпәй, Холмовка керә) уртача зурлыктагы авыллардан санала. 132 хуҗалыкта 341 ир-ат һәм 337 хатын-кыз яши. 2 лавка, 19 хуҗалыкта 70 баш умарта тотыла.

Авыл җәмгыяте ул чорда 1496,5 дисәтинә уңайлы һәм 93,9 дисәтинә уңайлы булмаган җир биләгән. Аның 814,3 дисәтинәсен сөрүлекләр алып торган. Монда җан башына тигән җир күләме волостьның башка (мәсәлән, Азнакай, Сәпәй) авылларына караганда шактый түбән була. 16 яшьтән 60 яшькә чаклы һәр ир-атка бүлгән очракта ул 9,3 дисәтинә туры килә.

Әмма хуҗалыклар буенча җирнең күләме, ягъни иманалар саны шактый аерыла. Авылда 126 хуҗалыкның иманасы була. Шуларның 60 ында ул – берәр, 45 ендә – икешәр, 14 ендә – өчәр, 7 сендә дүртәр яисә аннан артыграк. Мондагы бер имана чагыштырмача түбән – 6,9 дисәтинә, шуңа күрә шактый хуҗалыклар аз җирләләр төркеменә керә. 6 гаиләнең (хуҗалыкның) иманасы бөтенләй булмый. Аларның бер өлеше (12 ир-ат һәм 13 хатын-кыз) читтә яшәгән.

Җир сыйфатлы һәм вакытында эшкәртелсен өчен, беренче чиратта, эш кораллары кирәк. 102 хуҗалыкта алар җитәрлек, калганнарында – өлешчә (3) яисә бөтенләй булмый (17). Соңгылары кирәкле коралларны авылдашларыннан хак түләп яисә башка шартка килешеп алып торган.

Игенчелектән тыш, терлекчелек тә зур урын тота. Эш аты (239), мөгезле эре терлек (186), сарык (456) һәм кәҗә (236) асраучылар күп була.

Бу очракта да зур аерма күзәтелә. Эш атларын гына алыйк. 88 хуҗалык – берәр, 25 хуҗалык – икешәр-өчәр, 2 хуҗалык – дүртәр, 4 хуҗалык дүрттән дә күбрәк ат тотса, 6 хуҗалыкта алар бөтенләй булмый.

Шул ук вакытта 5 хуҗалыкның эш аты гына түгел, сыеры да булмый. Өстәвенә, бер гаилә йортсыз (соңгы 10 елда янгыннардан 29 хуҗалык зыян күрә). Андыйлар бик зур авырлык белән тормыш итә.

Башка авыллардагы кебек, монда да игенчелек эшләренә ялланучылар (36 кеше) һәм һөнәрчеләр (4) була.

1889 елда Әгерҗедә 137 хуҗалыкта 880 кеше яши. Элеккечә бер мәчет була. Ул Уразай, Балтач, Әгерҗе, Туйкә, Холмовка һәм Шкапское авыллары белән Азнакай волостена керә. Соңгы икесе – XIX гасырның икенче яртысында барлыкка килгән рус авыллары. Беренчесендә – дворянка А.Т.Герасимова, икенчесендә дворяннар П.Н.Ильин һәм А.А.Соловьев утарлары урнашкан.

Гасыр ахырына Әгерҗе беркадәр зурая. 1897 елда 156 хуҗалыкта 443 ир-ат, 451 хатын-кыз исәпләнә. Элеккечә мәчет һәм 2 су тегермәне була. Аларның беренчесе Тегермән Елгада урнашкан, ул мещан Бобров карамагында, икенчесе – Мәнәүс елгасында, Галиуллинныкы.

Авыл тормышын тулырак итеп күз алдына китерү өчен, аның кешеләре турында сөйләп үтү әһәмиятле. Бу җәһәттән хуҗалыклар санын алу документлары игътибарга лаек.

Әгерҗедә бик күптәннән мәчет эшләп килүе хакында әйтелде. 1900 елда монда Хикмәтулла Нигъмәтуллин (аңа 39 яшь) муллалык итә. Ул хатыны (26) һәм кызы белән яши. Мулланың хуҗалыгы зур түгел. Анда икешәр эш аты, сыер, бозау һәм 5 сарык була. Авыл җәмгыяте бүләк иткән 8,5 дисәтинә җирдә ул арыш (4,22 дисәтинә) һәм солы (4,56) игә. Моннан тыш, читтән дә арендага җир участогы (5 дисәтинәдән артык) ала. Анысы күбрәк печәнлек буларак файдаланыла. Хикмәтулла хәзрәтнең хезмәтчеләре юк, кирәк булганда вакытлыча эшчеләр яллый.

(Дәвамы киләсе санда).

Таһир КӘРИМОВ,
тарих фәннәре кандидаты.



Фәнис ЯРУЛЛИН

Әллә нигә кояш баешына Ешрак карыйм хәзер кызыгып...

(Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллинның тууына 85 ел)

КИЕК КАЗ ЮЛЛАРЫННАН

Киек казларга ияреп,
Эшне ташлап кулымнан,
Чыгып китәсе килә бер
Киек Казлар Юлыннан.

Зөһрә кызның чиләгеннән
Эчәр идем су алып.
Фәрештәләр мәҗлесендә
Йөрер идем сыйланып.

Китәр идем ерак-ерак,
Кызлар йолдызлыгына.
Гашыйк булыр идем шунда
Иң чибәр бер кызына.

Чүмеч йолдызын тотырып,
Шатлыклар эчәр идем.
Бик ошаса, мәңгелеккә
Мин күккә күчәр идем.

ЙОКЫСЫЗ СӘГАТЬЛӘР

Йә, нихәл, карак төн,
Килдеңме кунарга?
Әллә соң килдеңме
Йокымны урларга?

Соңгардың шул инде,
Бичара, карак төн.
Мин инде йокымны
Күптәннән югалттым.

Бәлки, ул киткәндер
Сугышка, фронтка –
Әтигә ияреп
Кергәндер ул утка.

Туң җирдә яткандыр,
Суларга баткандыр.
Ә кайтыр юлларын
Карурман япкандыр.

Кем белә: бәлки, ул
Югалган язларда?
Ә бәлки, беренче
Шигырьне язганда?!

Үзем дә белмимен
Ул кайда калгандыр.
Бәлки, ул мәхәббәт
Утында янгандыр.

Ә бәлки, ачлыкның
Тозлы күз яшендә
Кинәт юк булгандыр,
Әверелеп яшенгә.

Югалттым мин аны
Бик иртә – гомергә.
Саулыгым белән ул
Калдымы чит җирдә?!

Җилбәзәк бирәр кыз
Алдымы шаярып? –
Онытып йөриме
Бирергә кайтарып.

Йокысыз калырга
Булды шул сәбәпләр.
Санасаң – бер гомер
Йокысыз сәгатьләр,
Тынгысыз сәгатьләр.

ФАСИЛ ӘХМӘТКӘ

Менә син дә китеп бардың, Фасил,
Киткән «Аккошлар»ың артыннан.
Ул аккошлар синең пакь җаныңны
Саклап барыр җилдән-салкыннан.

Якын иттек без гел бер-беребезне,
Аралашмасак та бик артык.
Җаннарыбыз безнең кардәш иде,
Шул кардәшлек торды гел тартып.

Зарланышып ала идек кайчак
Озак-озак итеп телефоннан.
Трубкаңны куеп роялеңә,
Бер көй уйный идең син соңнан.

Әйтә идең: шәп чыккан бит, малай,
Музыкада бу бит – яңалык.
Чукынып китсен, хәер, яңалыгы,
Ничек анда синең тазалык?

Язасыңмы һаман? Язасыңдыр.
Үземә дә бу эш бик таныш.
Тик «тегендә» генә булыр, ахры,
Синең белән миңа тукталыш.

Без бөекләр... Юк, юк, каршы килмә,
Без бит моны яхшы беләбез.
Яраларны яшереп бәйли-бәйли,
Карурманнан җырлап киләбез.

Бездән чыкмый сыкрау авазлары,
Безнең тавыш һаман көр әле.
Мин уйнармын сиңа яңа бер көй,
Такси ал да миңа кил әле.

Хәер, килмә, үзем барам сиңа,
Эләктерәмен дә бер ярты.
«Генераллар» булып утырырбыз,
Соңга калсак – күктә Ай якты.

...Шулай диеп шалтырата идең,
Уенын-чынын кушып гел бергә.
Вакыт күп тә, гомер кыска икән,
Кунак-кунак булып йөрергә.

Ашыга-ашыга китеп бардың, Фасил,
Киткән «Аккошлар»ың эзеннән.
Аккошларның ап-ак каурыйлары
Кабрең өсләренә сибелгән.

ХӘТЕР АЛАННАРЫ

Хәтер аланымда күләгә юк,
Хәтер аланнарым якты әле.
Ул аланда пешкән җимешләрем
Һаман сусыл, һаман татлы әле.
Анда йөри яшь-яшь чибәр кызлар,
Челтерәтеп матур чиләкләрен.
Каптыралар минем үземә дә
Чиләкләргә җыйган җиләкләрен.
Ул аланда гөлләр шау чәчәктә,
Матурлыктан күзләр камашырлык.
Кызлар күзе кебек чишмәләрнең
Карашыннан башлар адашырлык.
Аланнарда тамган яшьләремнең
Ачылыгы күчкән баланнарга.
Яшьлегемнең яшеннәрдән алган
Катылыгы калган чаганнарда.
Сөйгән ярлар биргән кульяулыктай
Кадерле сез, хәтер аланнарым.
Ул аланда кульяулыгын болгап
Басып тора кавышалмаган ярым.
Хәтер аланымда күләгә юк,
Хәтер аланнарым якты әле.
Күңелемә күчкән хатирәләр
Тәүге үбеш кебек татлы әле.

МИН ЮКЛЫКНЫ, БӘЛКИ, БЕРКЕМ СИЗМӘС

Сабыр канатымның каурыйларын
Берәм-берәм җилләр йолкып бара.
Ул каурыйлар көзге яфрак булып
Үткән юлларыма коелып кала.

Килер бер көн: каурыйларым бетәр,
Канатларым калыр шәрәләнеп.
Очармын да тирән упкыннарга,
Җан бирермен шунда бәргәләнеп.

Якты кояш миңа ясин чыгар,
Җилләр күмәр җиргә җәсәдемне.
Кеше хәтере – рәшә, тиз таралыр,
Онытырлар җирдә яшәвемне.

Онтылулар ләкин һич куркытмый,
Һәрнәрсәнең була бер азагы.
Мин юклыкны, бәлки, беркем сизмәс,
Кимер бары җирнең бер газабы.

КОЯШ БАЕГАНДА

Әкрен генә кояш баеп килә,
Бар дөньяда серле кызыллык.
Шәрә башлы тауның өсләрендә
Ак болытлар ята кызынып.

Яфракларга шәфәкъ уты капкан,
Урман-кырлар яна шул утта.
Сайрар кошлар сайравыннан туктап,
Хәйран калып утыра тынлыкта.

Җил дә исми. Ул да, чалкан ятып,
Кояш баеганны күзәтә.
Әй бу кичләр, әй бу хозурлыклар
Күңелләрне әллә нишләтә.

Уйлар китә ерак-еракларга,
Сокланудан тыннар кысыла.
Урап калдырасы килә гомер җебен
Биек агачларның очына.

Әкрен генә кояш баеп килә,
Җирдә, күктә сихри кызыллык.
Әллә нигә кояш баешына
Ешрак карыйм хәзер кызыгып.

КАБЫРГА

Хатын-кызлар безнең кабыргадан
Яратылган – белми кем генә?
Белә торып, шушы кабырганың
Аптырыйбыз кәкрелегенә.

Турайтмакчы булып кабырганы
Тырышабыз гомер буена.
Күпме генә сукма – ул тураймый,
Йә уалып бетә, йә сына.

Тимердән дә түгел, камырдан да,
Кабырга бит була сөяктән.
Ходай аны юкка яратмаган
Умырып алып безнең күкрәктән.

«Мә! – дигән Ул. – Кәкре кабырганы
Үзеңә бирәм гомер итәргә.
Йә син аны кимереп читкә ыргыт,
Йә йолдыз ит, күтәр күкләргә».

Кабыргалар, кәкре кабыргалар,
Сез бит безгә тигән өлешләр.
Без эт булсак – сез бер сөяк кенә,
Без ир булсак – алтын-көмешләр.

БАРАМ

Барам-барам, сүнәм-янам,
Нидер бирәм, нидер алам.
Биргән саен байый барам,
Алган саен ярлыланам.

Чумам төнгә, чыгам көнгә,
Йөзәм вакыт дәрьясында.
Яна гомер таңнар булып
Күзләремнең карасында.

Мәхәббәтнең капкаларын
Хисләр җиле бәреп ача.
Сөю бәреп кергән җаннан
Караңгылык чыгып кача.

Айларымны, елларымны
Төен итеп төйнәп барам.
Җырланмаган җырларымны
Былбылларга сөйләп барам.

Менәм хыял үрләренә,
Ятам уйлар үзәнендә.
Күкләрнең барлык төсләре
Агылып керә күзләремә.

Пычранам да чистарынам,
Егылам да тагын торам.
Кайда башы, кайда ахыры –
Гомеркәйләр кара урман.

БАШКА ЯССЫЛЫК

Күчеп барам башка яссылыкка,
Монда бар да бераз моңсурак.
Офыкларның төсе тонгырак,
Һавалары бераз тынчурак.

Урманында дәртле кошлар сирәк,
Елгалары артык тын ага.
Болытларның үпкәләре шиңгән,
Көчкә-көчкә генә тын ала.

Дәшеп торган биек таулары юк,
Давыллар юк бәреп егарлык.
Эссе түгел монда, салкын түгел,
Кайнарлык юк тынны буарлык.

Юллары да бара туры гына,
Сикәлтәләр очрый бик сирәк.
Монда бар да, кырмыскалар кебек,
Ниндидер йөк бара өстерәп.

Хыял атларыбыз ташлап качкач,
Җимерелгәч өмет таулары,
Шушы яссылыкка чыгабыз без,
Биштәрләргә салып җаннарны.

Хыяллардан башка җаннар авыр,
Барган саен, баса иңнәрне.
Барасың син, арган юлчы кебек,
Аермыйча көнне-төннәрне.

ТАТАРЛАР – тау эше остасы

Бөтендөнья татар конгрессы бинасында «Пермь шәһәре һәм Пермь крае һәм Кемерово өлкәсе татар галимнәренең Уралда һәм Кузбасста тау казу һәм тау сәнәгате тарихын өйрәнүдәге роле һәм татар шахтерларының Россия төбәкләрендә яшәүчеләрнең социаль-икътисади тормышына керткән өлеше» дигән темага түгәрәк өстәл утырышы узды. Аның барышында «Шахтерлар – хезмәт гвардиясе», «Татар-шахтерлар. Тау эше осталары» китаплары, татар халкының Пермь шәһәре үсешенә керткән хезмәтенә багышлап үткәрелгән фәнни-гамәли конференция материаллары җыентыгы һәм Кемерово шәһәрләрендә басылып чыккан басмалар тәкъдим ителде.

●**Данир Закиров (сулда) Альберт Борһановка татар мәдәниятен үстерүгә керткән өлеше өчен Пермь шәһәре милли мәдәнияте мохтарияте медален тапшыра.**

●**Данис Шакиров (уңда) Әнвәр Әшировны Бөтендөнья татар конгрессының Мактау гармотасы белән бүләкли.**

Татар халкы гомер-гомергә тырышлыгы белән аерылып торган. Ата-бабаларыбыз тормышлары матди яктан авырайган чакта читкә китеп акча эшләүне гадәт иткән, алар тимер эшкәрткән, Донбасс, Кузбасс, Уралга барып күмер чапкан, җир байлыгын күтәргән, Себер киңлекләрен иңләгән. Еш кына чит җирләрдә төпләнеп тә калганнар. XIX йөз ахырында файдалы казылмалар табылу, металлургия предприятиеләрендә эшче куллар җитмәү күмер чыга торган, металл казылмалары табылган якларда татарлар нигезләгән авылбистәләр пәйда булуга, алардан шәһәрләр үсеп чыгуга китергән. Әйтик, Пермь губернасында да Кизел, Губаха, Гремячинск кебек шәһәрләр шушы сәбәпле барлыкка килә.

Татар шахтерлары турындагы китаплар авторы, техник фәннәр докторы, Россиянең атказанган шахтеры һәм инженеры, Пермь шәһәренең Татар милли-мәдәни мохтарияте җитәкчесе Данир Закировның тормышы да – моның ачык мисалы. Татарстанның Апас районы Дәвеш авылында яшәгән әтисе Галимҗан абзый Бөек Ватан сугышы башлануның икенче көнендә үк яшь хатынын, кечкенә өч баласын калдырып яу кырына киткәндә, Данирга нибары ике яшь, сеңлесенә дүрт ай була. Балаларга ачлык-ялангачлыкны күп татырга туры килә. Хәтта җиде яшьлек малай атлар да көтә. Данир әтисенең сугыш кырыннан кайтуын озак өметләнеп көтә. Сигезьеллык мәктәпне тәмамлап, һөнәр училищесында укыган үсмер машина-трактор станциясендә эшли башлый. Йортлары да инде нык тузган була. Гаиләдә бердәнбер ир-егет булган Данир аны, тәртипкә китереп сипли, черегән такта-бүрәнәләрен алыштыра, әмма шактый зур суммада бурычка керә. Аны ничек түләргә? 18 яшьлек егет алдына акча табу мәсьәләсе килеп баса. Данир 1958 елда ничек тә тормышны җайлыйсы килеп, акча табу нияте белән авылдашлары хезмәт куйган Урал якларына – Кизел шахталарына эшкә чыгып китә. Әлбәттә, 18 яшеннән туган йортыннан, әнисеннән аерылып чит якларга юл тоту җиңел булмагандыр. Кизел күмер бассейнында проходчик булып эшли башлаган егет үзенең алга таба техник фәннәр докторы дәрәҗәсенә ирешәчәген, Бөтенсоюз әйләнә-тирә мохитне саклау институтының (ВНИИОСуголь) директор урынбасары, шактый еллар дәвамында Көнбатыш Уралның энергетикасын җитәкләп барачагын, ягъни Көнбатыш Урал энергетиклары ассоциациясенең генераль директоры булачагын күз алдына да китермәгәндер.

Данир проходчик хезмәтенең барлык авырлыгын татый, шахтерларның ни дәрәҗәдә тырыш булуын, анда эшләүчеләрнең хезмәт урыннарына беркайчан да соңармыйча килүен, төгәллеген, бер-берсенә ярдәм итеп, бер гаилә булып эшләүләрен күреп гаҗәпләнә. Шахталарда эш куркыныч та була, ишелүләр, имгәнүләр кабатланып тора. Данир да берничә тапкыр җитди сынауларга тарый, әмма аны Раббыбыз саклап кала. Күмер катламын корыга бораулый торган булалар, шуңа да эш урыннарында һәрвакыт бернәрсә дә күренмәслек тузан күтәрелә. Ул үпкәләргә утыра. Нәтиҗәдә шахтерлар силикоз дигән профессиональ авырудан интегә. Моннан тыш җир астында, ябык аралыкта эшләү, тавыш, вибрациянең йогынтысы, һәрдаим җимерелү, шартлау дәһшәтен тою кешегә психологик яктан тәэсир итә. Шушы шартларда эшләү милләттәшләребезнең күпләп кырылуына да китергәндер. Данир Закиров силикоздан котылу юлын җиңел атлетика белән шөгыльләнүдә таба, ул йөгереп кайтуны гадәткә кертә. Смена буе бораулап, 15 әр вагонетка төяп озаткан егет, арыса да, спорт ярышларында катнаша, шахтадан чыгуга кичке эшче яшьләр мәктәбенә йөгерә. Уку егеткә җиңел бирелә, әмма эштән соң дәресләрдә утыру авыр, ул еш кына йоклап китә. Данир мәктәпне ташлап та карый, икенче елны, барлык ихтыяри көчен җыеп, яңадан парта арасына утыра. Шул ук вакытта шахтада эшләү яшь егет өчен үзе бер мәктәп була. Җитәкчелек кичке эшче яшьләр мәктәбен тәмамлаган Данирны Пермь политехника институтына укырга юллый. Шуннан соң Д.Закировның шахтада хезмәт баскычы буйлап күтәрелеше башланып китә. Мастер, баш энергетик, баш механик, «Кизелуголь»ның матди-техник тәэмин ителеше һәм транспорт производствосы берләшмәсе директоры... Татар егете читтән торып Пермь политехника институтында аспирантураны да тәмамлап өлгерә, кандидатлык, докторлык диссертацияләрен яклый.

Аз сүзле, кырысрак холыклы, төгәллек ярата торган Д.Закиров тырышлыгы, белемгә омтылышы, тынгысызлыгы аша барысына да ирешә, шул ук вакытта кайда гына хезмәт куйса да, үзенең милләтен онытмый, аларның сугышта һәм тыныч тормыштагы батырлыклары турында өйрәнеп хезмәтләр яза. Бөтендөнья татар конгрессының Төбәк тарихын өйрәнүчеләр белән эшләү комитеты җитәкчесе Альберт Борһанов та милләтебезнең Д.Закиров аркылы Пермь краеның данлыклы татарлары белән танышуын ассызыклады. Ике ел элек кенә Д.Закиров Бөек Ватан сугышында милләттәшләребез кылган батырлыкларын өйрәнеп, татарлардан 378 Советлар Союзы Герое исәпләнүен тәгаенләп, «Пермские татары в боях за Родину» дигән китабын дөньяга чыгарган иде.

Д.Закиров үзе дә 1930 елларны «XX гасырда халыкларның бөек күчеш чоры» дип белдерде. Шушы елларда «коммунизм төзелеше»нә Татарстаннан гына 300 мең кеше читкә эшкә чыгып киткән. Аларның күбесе шахталарда хезмәт куйган. Халкыбыз тау-руда һәм күмер сәнәгатен үстерүдә гаять зур өлеш керткән, шахта хезмәтенең барлык михнәтләрен күреп, илне күмер белән тәэмин итүдә, тормышны алга җибәрүдә әһәмиятле көч булган. Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров күмер хезмәтендә булучы татар шахтерларының хезмәте әлегәчә әдәбиятта да яктыртылмаган, тиешенчә бәяләнмәгән, галимнәр, тарихчылар тарафыннан да фәнни өйрәнелмәгән булуына басым ясады. Шахтерлар хезмәте турында китаплар, гомумән, юк диярлек иде. Гомеренең шактый өлешен күмер хезмәтенә багышлаган Д.Закиров исә Казанга шахталарда хезмәт куйган милләттәшләребез турында саллы китап алып килде. Хезмәттә якташларыбыз – исемнәре хезмәтләре белән данланган шахтерлар турында язылган. Алар арасында өч Советлар Союзы Герое, 17 Социалистик Хезмәт каһарманы, 18 данлыклы шахтер-җитәкчеләр, 11 Россиянең атказанган шахтеры, 2 Мактаулы шахтеры, 9 «Шахтер даны» билгесенең өч дәрәҗәсе кавалеры бар. Кизелдан Мансур Хәсәншин, Кузбасстан Хәмзә Мөхәммәдиев кебек геройлар, Дан орденының тулы кавалеры, Кизелле Әхәт Даутов турында киң мәгълүмат бирелә. Басманың ике бүлеге алтын табу хезмәтенә, «Березов мәгъдән учагы (рудник)»н булдыру тарихына багышланган. «Татар-шахтерлар. Тау эше осталары» хезмәтендә татарларның Колымада беренче алтынны табучылар булуы турындагы язма да игътибарны җәлеп итә. Казан губернасының Мирза авылыннан чыгып киткән крестьян Бари Шәфигуллин була ул.

Китапта шахтер династияләре турында да мәгълүмат бар, мисалга, өч татар династиясе турында язма тәкъдим ителә. Бу уңайдан Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының өлкән фәнни хезмәткәре Ләйсән Хәлилова Д.Закировның китаплары укучылар һәм галимнәр өчен дә тиңсез чыганак булуын белдерде. «Без Д.Закиров хезмәтләреннән алып, читтә яшәгән күп кенә шәхесләрне «Татар энциклопедиясе» басмаларына керттек», – диде ул.

А.Борһанов читтәге шәхесләребез батырлыгын мәңгеләштерү, галимә Тәэминә Биктимерова исә Урал шахта забойларында татар хатын-кызларының да эшләве турында махсус китап чыгару кирәклеген белдерде.

Утырышта татар морзалары вәкиле, Кемерово өлкәсе, Новокузнецк шәһәренең төбәкне өйрәнүчеләр җәмгыяте җитәкчесе, «Чулпан» мәчете имам-хатыйбы Әнвәр Әшировның китаблары «Кузбасс татарларының тарихи язмышы» китабы да тәкъдим ителде.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

ГЕНЕРАЛ Хәбиб Ганиев

Хәбиб ага Ганиевне соңгы мәртәбә 1965 елның апрель ахырларында Ереван шәһәрендә, табигатьнең шау чәчәккә күмелгән вакытында күргән идем. 1970 ел ахырларына кадәр даими рәвештә хатлар алышып, хәбәрләшеп тордык. Бервакыт ул яктан хәбәрләр килү туктатылды. Күңел юкка шикләнмәгән, генералның йөрәге икенче инфаркттан соң туктаган икән.

Ул әле һич тә карт түгел иде. Ереван аэропортында мине егетләрчә каршылады. Күзләремә ышанмый тордым: урта буйлы, төз сынлы, төскә-башка чибәр кеше иде ул... Гомере буе читтә яшәсә дә, саф татарча сөйләшә, хәтта урыс сүзләрен дә кыстырмый.

Сугыштан соң Совет Армиясе Генштабы Мәскәүгә хәрби башлыкларны җыя. Шунда һәммәсенә Сталинның әмере җиткерелә: сугыш вакытында җыйналган, тупланган бөтен документларны, көндәлекләрне һ.б. юк итәргә. Сәбәп-мотив көн кебек ачык: Сталин гаебе аркасында миллионнарча сугышчылар әсирлеккә төшә. Шуны яшерергә тели Верховный. «Тиешле» документларны тапшырмаганнарны иң каты җәза көтә! Шуларны ишеткәч, Хәбиб ага Ереванга хатынына телефон аша татарча әйтеп, фронтта тупланган материалларны үзе кайтып җиткәнче юк итәргә куша. Әмма кайчандыр авыл советы рәисе булган Гыйльминур апа шуны белә: андый кисәтүләр куркыныч нәрсә. Дөнья бер урында тормый – «тегe документлар»ның кирәк булу вакыты да җитәргә мөмкин бит. Ул шактый кәгазьләрне яшереп куя. Мин Ереванга Хәбиб ага турында эссе язарга дип баргач, Хәбиб ага бернәрсә дә сөйләмәс булды. Шул чакта Гыйльминур апа кайбер материалларны яшереп куйган җиреннән алып бирде.

Тарихтан шул билгеле: 1941 елның июль урталарына немецлар, фронтларны өзеп, СССРның көнбатыштагы күпчелек җирләрен басып ала, Мәскәүгә үрмәли. Фюрерга анда мәһабәт һәйкәл кую өчен, махсус рәвештә гранит ташыйлар. Ноябрь башында Кызыл Мәйданда Җиңү парады үткәрергә әзерләнәләр, һәм бу реаль булып тоела. Бары тик бер урында – Прут, Днестр елгалары буенда гына фашистлар уңышка ирешә алмый. Шул юнәлештә дошман бихисап авиация, танк армадалары, артиллерия туплый. Канлы сугыш көн-төн бара. Берлиннан туктаусыз күрсәтмәләр алына: «Кызыл фанатикларны суга батырып үтерергә, берсен дә кызганмаска!» Бомбалардан, снарядлардан җирләр тетри, һавадан листовкалар ява: «Бирелсәгез, гомерегезне саклaрбыз, яхшы ашатырбыз!» – диелә аларда. Әмма нинди генә югалтулар кичерелмәсен, совет сугышчылары чигенми. Чөнки алар белән бергә Хәбиб Ганиев кебек комиссарлар да була...

Сүз уңаеннан, бу 169 нчы дивизия турында сугыш вакытында ук китап чыккан. Гыйльминур апа аны укырга биргәч, 1941 ел сугышчыларының батырлыгы алдында баш идем... Сүзне тагын бер китап авторына – генерал-лейтенант Н.Попельгә бирик. Ул болай дип яза: «Таң атуга Калядин (3 армиянең политбүлек башлыгы) белән икәү туңып уяндык... Көтмәгәндә колакка баян тавышы ишетелеп китте. «Кем уйный?» – дип сораганымны сизми дә калдым. «Комиссар Ганиев. Ул һәр иртә шулай...» – диде Калядин.

Без шул якка юнәлдек. Ганиев янына үтәрлек түгел. Окоп солдатлар белән тулы, аларның йөзе дә тыныч. Суык та алмаган. «Ганиев – политработник буларак, хәзинә ул, – диде Калядин, – анда башка политработникларда булмаган өстәмә ике сыйфат бар: баянда уйный һәм татарча сөйләшә белә. Татар теле турында шуңа әйтәм, бездә башкорт, татар, азәрбайҗан, үзбәк сугышчылары белән иплән сөйләшерлек политработниклар җитешми».

Масайган дошман бу вакытта әле төнен рәхәтләнеп ял итә, ә иртәннән төнгә кадәр бертуктаусыз һөҗүм артыннан һөҗүмгә күтәрелә. Зур бәрелешләрнең берсе 3 июльдә була. Фашистлар дивизияне камап алу һәм юк итү теләге белән, тар гына урынга 40 танк, бихисап мотопехота туплый. Үзенә төп ударны алган полкта сугышчылар белән бергә комиссар Ганиев тә була. Дошманны чигендерү ул заман өчен искиткеч сирәк күренеш: Яков Колчак дигән сугышчыга Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Күпләрне Ленин ордены яки башка орден, медальләр белән бүләклиләр. Бу җиңү һич тә очраклы булмый. Бу хакта Я.Колчак болай ди: «Җиңүдә комиссар Ганиевнең роле искиткеч зур булды. Ул безне дошманнардан курыкмаска, аларны кыйнарга өйрәтте. Безнең белән бергә булуы да һәммәбезгә көч бирде».

Бер каты бәрелеш вакытында 169 нчы дивизиянең командиры генерал И.Т.Трунов һәлак була. Сугышчылар бер мәлгә югалып кала. Әмма комиссар Хәбиб Ганиев салкын канлылык күрсәтә һәм шундук командалыкны үз кулына ала, нәтиҗәдә дошман зур югалтуларга дучар ителә, чигенергә мәҗбүр була. Моның өчен Хәбиб аганы Кызыл Байрак ордены белән бүләклиләр. Бу хакта махсус әйтүебезнең сәбәбе шул: ул чакта, немец туктаусыз ил эченә үрмәләгәндә, сугышчыларны бүләкләү урынсыз дип карала...

Якташыбызның кыюлыгы, солдатлар хәленә керә белүе эзсез калмый. Аны башта 41 нче, аннан соң 65 нче армиягә политбүлек башлыгы итеп күчерәләр. Ул бирегә дә үзен тиз арада уңай яктан таныта.

Сүзне 65 нче армиянең командующие, ике мәртәбә Советлар Союзы Герое П.Батовка бирик: «Армиянең политбүлек башлыгы

●Сулдан уңга: полковник Г.Е. Гришко, полковник Хәбиб Ганиев, генерал-лейтенант Павел Иванович Батов һәм генерал-майор Николай Антонович Радецкий.

Х.Ганиев... романтиклар токымыннан иде. Шәхси батырлыгы чиксез иде аның» (П.Батов. Походларда һәм сугышларда. – М., 1963). Бу юлларны укып чыккач Хәбиб агага мондый сорау бирдем: «Армиягезнең командующие – ике мәртәбә Советлар Союзы Герое, ә нигә бу исем сезгә бер мәртәбә дә бирелмәде?» Генералның җавабы болай булды: «Мин Алтын Йолдыз өчен сугышмадым, Ватаным өчен кан түктем. Ул вакытта гомумән үпкәләшү, бүләк кайгысы булмады. Өстәвенә, минем табигатем дә шундый. Мин язмышымнан канәгать».

65 нче армиянең сугыш юллары турында күп китаплар язылган. Шуңа күрә аның аерым мизгелләренә тукталу урынлыдыр. Шуларның берсе – Днепр елгасын кичү. Бу мәгълүм факт: дошман елганың уң ярын бик нык ныгыткан. «Руслар мондый ныгытманы күпме генә көч түксә дә, ала алмас», – дип, Геббельс пропагандасы көн-төн «сайрады». Ныгытмаларга килгәндә, дошман дөрес әйтә. Әмма...

…1943 елның 15 октябре. Иртәнге 6 сәгать утыз минутта атаклы «катюша»лар ут ача, авиация дошман позицияләренә бомбалар яудыра. Меңнәрчә туплар, минометлар үз эшләренә керешә. Җир туры мәгънәсендә тетри. «Помпейның соңгы көне» картинасында да мондый ук мәхшәр сурәтләнмәгәндер... Беренче булып суга 18 корпусның 69 нчы дивизия солдатлары керә. Әйе, безнең яктан югалтулар зур була. Хәтта кеше гәүдәләреннән елга буылгандай тоела. Шулай да, алга куелган бурыч үтәлә: Днепрның уң як ярында беренче плацдармнар барлыкка килә. Андагы солдатларны суга куып төшерү өчен дошман бөтенесен эшли. Әмма теләгенә ирешә алмый. Дөньяда күрелмәгән бу батырлык өчен 65 нче армиянең 185 сугышчысына Советлар Союзы Герое исеме бирелә... Бу исем елганың теге ягына беренче булып чыгып исән калганнарга бирелә. Әмма анда һәлак булганнарның һәммәсе дә Герой исеменә лаек. Чөнки алар Ватан өчен үз гомерләрен биргәннәр...

«Днепр сугышлары» өчен Хәбиб Ганиев Ленин ордены белән бүләкләнә, генерал-майор дәрәҗәсенә күтәрелә.

Кызганыч, миңа Совет Армиясенең Үзәк архивында эшләргә туры килмәде. Шуңа күрә, 65 нче армия турында кирәк саналган материалларны таба алмадым... Өстәвенә, Хәбиб ага да артык тыйнак булып чыкты. Шулай да мин бер документтан өзек китерим. Бу «2 нче Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан татар халкына хат». Анда мондый юллар бар:

«Вөҗдан безне «үч ал» диеп,
Сугышка, яуга илтә,
Хәбиб Ганиев – генерал,
Җитәкләп алга илтә.
Кертә ул безне сугышка,
Җитәр өчен максатка,
Ул – большевик, нык җитәкче,
Ул якын дус солдатка».

Бу – мәңгелек законы: еллар үтә дә үтә – мизгелгә дә туктау юк. Әмма әлеге хатта язылганнар, олы тарих мирасы буларак, бик озак сакланыр дигән өмет бар. Бит әлеге хат ут давылы эчендә язылган. Анда кайнар хисләр дә, күз яшьләре, киләчәккә өмет тә бар... Югарыда әйтелгән иде инде – Хәбиб ага сугышның беренче минутларыннан алып соңгы көненә кадәр фронтта була. Әмма үкенечлесе шул, бу артык тыйнак кеше көндәлекләр дә язып бармаган. Мөгаен, вакыты булмагандыр, күңелен «киләчәктә язармын әле» дип тынычландыргандыр. Шул сәбәпле генералның үз кулы белән язылганнарга тап булырга туры килмәде... Аның хакында Советлар Союзы Герое генерал-лейтенант А.Г.Джанджгава үзенең «Немеренные версты: записи комдива» китабында (М., 1979) болай бәян итә: «1945 елның 26 гыйнвары. Көн бик салкын. Мин командалык иткән дивизиягә генерал Ганиев килде. Гадәти киемдә, чана өстендә ничек туңмагандыр. Әмма ул үзен егетләрчә тотты. Дивизия алдына куелган бурычны аңлатты: без Висла ярларына чыгарга тиеш икән. Шундук полкларга, батальоннарга китте, солдатлар белән сөйләште. Дивизия һөҗүмгә күчкәч тә, бездә ике көн булды, кыенлыкларны бергә кичерде. Чыннан да, безнең дивизия Висла елгасы ярына барып чыкты һәм шунда ныгып урнаша башлады. Дошман искиткеч зур каршылыклар күрсәтте, әмма җиңү безнең якта иде инде. Монда политбүлек башлыгы Хәбиб Ганиевнең роле бик зур булды».

Сугыштан соң Х.Ганиев Кавказ арты хәрби округы советына әгъза итеп билгеләнә. Бу зур дәрәҗә дә, зур җаваплылык та иде. Якташыбыз аны тулысынча аклады. Соңгы сулышына кадәр Ватанга хезмәт итте. Кабере, хәзергечә әйтсәк, чит җирләрдә – Ереван шәһәре зиратында. Безгә бу изге урынны онытмаска, сөекле якташыбыз каберенә чәчәкләр куярга кирәк...

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ,
педагогика фәннәре докторы.
«Гасырлар авазы»
журналыннан.

СӘЕРЛЕ

Василий ШУКШИН

(Ахыры. Башы 6 нчы санда.)

– Шушымы?! – дип шатланып кычкырды ул бераздан, табылдыгын аңа сузып.

Шунда тегенең хәтта пеләше кызарып чыкты.

– Нигә аны кулың белән тотарга иде? – дип акырды ул шышылдаулы тавыш белән.

– Ә нәрсә белән тотарга иде соң?! – дип гаҗәпләнде Сәерле.

– Мин аны кайда кайнатыйм хәзер? Йә, кайда?

Монысын Сәерле дә белми иде.

– Минем белән барыйк соң?.. – диде ул аптырап. – Монда минем абый яши, шунда кайнатырбыз... Сез мин анда микроблар иярткән дип куркасызмы? Юк алар миндә!..

Күршесе Сәерлегә гаҗәпсенеп карап алды да кычкыруыннан туктап калды.

Аэропортта Сәерле хатынына телеграмма язды:

«Җиргә төштек. Күкрәгемә алдым сирень ботагын, мине, Грушам, оныта күрмә тагын. Васятка».

Телеграфистка, җитди, кырыс хатын-кыз, аны укып чыккач:

– Башкача языгыз! – дип кире бирде. – Сез буй җиткән кеше, балалар бакчасында түгел бит.

– Ә нигә? – дип сорады Сәерле. – Хатларымда мин аңа гел шулай язам. Ул минем хатыным бит. Сез, мөгаен, әллә нәрсә уйлагансыздыр...

– Хатларда теләсә нәрсә яза аласыз, ә телеграмма – элемтәнең башка төре ул. Монда – ачык текст бит.

Сәерле яңадан язды:

«Җиргә төштек. Барысы да тәртиптә. Васятка».

Телеграфистка «җиргә төштек» белән «Васятка» дигән сүзләрне үзе төзәтте дә, телеграмма «Килеп җиттек. Василий» булып калды.

– «Җиргә төштек...» имеш! Сез нәрсә, космонавтмы әллә? – диде телеграфистка.

– Ярар ла соң... Сезнеңчә булсын алайса, – дип килеште Сәерле.

...Абыйсы Дмитрийның өч баласы барын ул белә иде... Ә менә тагын киленнәре дә булырга тиешлеге исенә дә килмәгән! Әнә шул киленнәре аның бөтен ялын бозды да куйды! Ул нигәдер аны күрүгә үк ошатмады.

Кичен алар абыйсы белән эчтеләр дә Сәерле калтыравык тавышы белән җырлап җибәрде: «Тополь-лә-әр... Тополь-лә-әр...»

Софья Ивановна, ягъни киленнәре, икенче бүлмәдән башын тыгып, усал гына:

– Ә акырмыйча булмыймы? Сез вокзалда түгел бит? – диде дә ишеген каты итеп ябып куйды.

Абыйсы Дмитрий уңайсызланып калды, әлбәттә.

– Анда ни... балалар йоклый. Ә болай яхшы ул, – дип акланып куйды.

Тагын эчтеләр. Сүз арасында яшьлекләрен, әниләрен, әтиләрен искә төшерә башладылар...

– Ә хәтерлисеңме?.. – дип шатлык белән сорады абыйсы Дмитрий. – Хәер, син аны ничек хәтерлисең ди! Имчәк баласы гына идең. Безне бергә калдыралар да мин сине үбеп туймый идем. Бер мәртәбә хәтта күгәренеп килдең! Әләкте миңа моның өчен. Бүтән бергә калдырмый башладылар. Әти-әни чак кына читкә борылса да, мин – тагын синең янда, тагын үбәм. Шайтан белгән, нинди гадәт булгандыр ул! Үземнең маңкам теземә житкән, ә инде ... ни ... шул үбүләрем...

– Ә хәтерлисеңме?! – дип Сәерле дә исенә төшерә. – Ничек син мине...

– Туктатасызмы сез акыруыгызны? – дип сорады бераздан Софья Ивановна бик усал нервыланып. – Кемгә кирәк сезнең маңка белән үбешү турындагы бу сүзләрегез? Сөйләшкән булалар тагын!..

– Әйдә урамга, – диде шулчак Сәерле.

Урамга чыгып, болдырда утырдылар.

– Ә хәтерлисеңме?.. – дип дәвам итте Сәерле.

Ләкин шул мизгелдә абыйсына нәрсәдер булды: ул елап җибәрде һәм йодрыгы белән тезенә суккаларга тотынды.

– Менә ул минем тормыш! Күрдеңме? Күпме явызлык бу кешедә!..

Сәерле абыйсын тынычландырырга кереште:

– Ташла, борчылма. Кирәкми. Бернинди дә явыз түгел, ә психлар алар! Минеке дә шундый ук.

– Нишләп ошатмады?! Ул сине ошатмады бит... Ә ни өчен?

Сәерле шунда аңлап алды, әйе, ошатмады аны киленнәре. Ә, чыннан да, ни өчен?

– Ә менә ни өчен: син бернинди дә җаваплы урын кешесе, ягъни җитәкче түгел. Беләм мин аны, юләрне. Саташып беткән ул шундый җаваплылар белән! Ә үзе кем соң?! Идарәдә буфетчы, тигез җирдә түмгәк. Әнә шунда күрә дә, башлый аннары... Ул мине дә куралмый, җаваплы урындагы кеше булмаганга, авылдан чыкканга күрә.

– Нинди идарәдә соң ул?

– Монда... Тау эшләре буенча... Хәзер әйтә дә алмыйм. Ә нишләп миңа кияүгә чыгарга иде ул чагында? Нәрсә, ул минем кем икәнемне белмәгәнмени?

Шунда Сәерленең дә бәгыре өзгәләнеп куйды.

– Гомумән алганда, эш нәрсәдә соң? – дип абыйсыннан түгел, ә кемнәндер башкадан сорады ул, кычкырып. – Әгәр белергә телисез икән, барлык күренекле кешеләр дә авылдан чыккан диярлек. Кемнең сурәте кара рамкага алынган, баксаң, ул авылдан чыккан кеше! Газеталар укырга кирәк!.. Кайсы гына зур фигура булмасын, аңлыйсызмы, – авылныкы, бик иртә эшли башлаганнар.

– Ә мин аңа, авылда кешеләр яхшырак бит, алар һавалы түгел, дип күпме тукыйм!

– Ә Степан Воробьевны хәтерлисеңме? Белә идең син аны...

– Белә идем, белмәскә!..

– Ничек кенә әле андагы авыллылык!.. Менә сиңа мә: Советлар Союзы Герое! Тугыз танкны юк иткән. Таранга барган. Хәзер әнисенә үлгәнче алтмыш сум пенсия түләп торачаклар. Күптән түгел генә белделәр, хәбәрсез югалган, дип йөргәннәр иде моңарчы...

– Ә Максимов Илья!? Без бит бергә киткән идек. Менә сиңа – Дан орденының тулы кавалеры! Ләкин Степан турында әйтә күрмә аңа... Кирәкми...

– Ярар. Ә теге кем дә бар тагын!..

Тәэсирләнгән туганнар озак шаулаштылар әле. Сәерле хәтта болдыр тирәли йөри-йөри, куллары белән селтәнә-селтәнә сөйләнеп алды:

– Авыл, имеш!.. Аның һавасы гына да ни тора бит! Иртән тәрәзәне ачып җибәрәсең – беләсеңме, шундук бөтен жиреңне ничек юып ала! Хет эчеп җибәр – шул чаклы салкынча һәм хуш исле, төрле үлән исләре килеп тора, чәчәкләр исе...

Шулай утыра торгач, икесе дә ялыкты.

– Түбәнне яңадан яптыңмы соң? – дип сорады абыйсы әкрен генә.

– Яптым, – диде Сәерле һәм тирән сулап куйды. – Веранда эшләдем – карап туйгысыз! Чыгасың да кичен шул верандага... менә әни белән әти дә исән булып, балалар белән син кайтып төшсәң икән, утырып идек барыбыз да бергә кура җиләге белән чәй эчеп, дип хыяллана башлыйсың. Быел бик күп булды ул. Син, Дмитрий, ачуланышма инде аның белән, юкса тагын да күбрәк яратмый башлар. Ә мин ничек тә ягымлырак булырга тырышырмын, шунда ул да йомшый төшәр.

– Ә бит ул үзе дә авылдан! – дип ничектер күңелсез генә гаҗәпләнеп куйды Дмитрий. – Ә менә... Балаларны да аптыратып бетерде, юләр: берсен пианинода уйнатып интектерде, икенчесен фигуралы шууга яздырган. Йөрәккә кан сава, ә әйтергә ярамый, шундук тиргәш-талаш китә.

– Ммм!.. – дип нигәдер тагын ярсып куйды Сәерле. – Берничек тә аңлый алмыйм мин бу газеталарны: менә, имеш, кибеттә шундый бер дорфа хатын-кыз эшли. Их сез!.. Ә ул бит өенә кайткач та шундый ук. Менә кайда ул кайгы! Аңлый алмыйм мин! – Ул да йодрыгы белән тезенә сугып алды. – Аңламыйм: нилектән усалга әйләнә икән алар?!

Иртән Сәерле йокыдан уянганда, өйдә беркем дә юк иде: абыйсы да, хатыны да эшкә киткәннәр, олырак балалар ишегалдында уйный, кечкенәсен яслегә илткәннәр.

Сәерле урын-җирен җыештырды да юынып алды һәм киленнәре күңеленә хуш килердәй нәрсә булса да эшләргә кирәклеге турында уйлана башлады. Шунда күзенә бала арбасы чалынды. «Әһә, – дип уйлады ул, – бизәп куйыйм әле мин шуны». Ул өйләрендә мичләрен шундый итеп бизәде, бөтенесе гаҗәпләнеп калды. Эзли торгач, балаларның буяуларын да тапты, кылкаләмнәрен алып, эшкә дә тотынды. Бер сәгатьтән арбаны танып та булмый иде инде. Ул аның өстенә торналар ясап куйды – алар төркеме почмак сыман булып оча, аста – төрле чәчәкләр, яшел үләннәр, ике яшь әтәч, чебешләр... Ул арба тирәли әйләнеп карап чыкты – күз алгысыз! Балалар арбасы түгел, ә уенчык!

Киленнәренең ничек итеп күңелле гаҗәпләнүен күз алдына китереп, елмаеп куйды.

– Ә син, авыл, дисең. Юләр! – Ул киленнәре белән араны җайларга тели иде. – Бала кәрҗиндә яткан шикелле булыр монда.

Сәерле көн буе шәһәр буенча йөрде, кибет витриналарын күзләде. Абыйсының малаена катер сатып алды, болай яхшы гына уенчык катер – ак төстә, лампочкалары да бар. «Мин моны да бизәп куям әле», – дип уйлап алды ул.

Абыйларына кичен сәгать алтылар тирәсендә кайтып керде. Болдырга гына менгән иде, абыйсы Дмитрийның хатыны белән орышуын ишетте. Хәер, хатыны гына орыша, ә абыйсы бары тик:

– Нәрсә инде!.. Ярарсана... Соня... Ярар инде... – дип кенә кабатлап тора.

– Бу тинтәкнең иртәгә үк эзе дә булмасын монда! – дип кычкырды Софья Ивановна. – Иртәгә үк кайтып китсен!

– Ярарсана инде!.. Соня...

– Ярар түгел! Бер дә ярар түгел! Чемоданын тотып атканны көтеп ятмасын!

Сәерле болдырдан төшеп китәргә ашыкты... Ә аннан соң нәрсә эшләргә икәнен үзе дә белмәде. Аңа тагын авыр иде. Үзен кемдер куралмаган чакта Сәерлегә гел шулай бик авыр һәм куркыныч була. Шундый тойгы биләп ала: янәсе, менә хәзер барысы да бетте, шулай булгач, бу дөньяда нигә яшәргә? Һәм андый вакытларда аның үзен яратмаучы яисә аннан көлүче кешеләрдән кая булса да еракка-еракка китәсе килә башлый.

– Нишләп мин менә шундый икән соң?! – дип ачынып пышылдады ул сарайда утырганда. – Сизенергә кирәк иде миңа: аңламый бит ул, аңламый ул халык ижатын.

Ул сарайда караңгыга тикле утырды. Йөрәге һаман сызлана иде. Аннары абыйсы Дмитрий килеп керде. Тик аны монда күреп бер дә гаҗәпләнмәде: әйтерсең, энесе Василийның инде күптән сарайда утыруын белә иде.

– Менә... – диде ул. – Теге... тагын тавыш куптарды. Арбаны... алай кирәк түгел иде инде.

– Мин аңа ошар дип уйлаган идем. Китәм мин, абый.

Абыйсы Дмитрий көрсенеп куйды... Һәм берни дә әйтмәде.

...Сәерле өенә жылы яңгыр яуган көнне кайтып төште. Автобустан чыккач, аягындагы яңа ботинкаларын салды да жылы, юеш җирдән йөгереп китте. Бер кулында – чемодан, икенчесендә – ботинкалары. Сикергәли-сикергәли, йөгерә-йөгерә кычкырып җырлап җибәрде:«Тополь-лә-әр... Тополь-лә-әр...»

Күк йөзе, инде бер читеннән чистарып, зәңгәрләнгән һәм кояш та кайдадыр якында гына сыман иде. Яңгыр да сирәкләнде, аның эре тамчылары күлләвекләргә шапылдап төшә дә аларда куыклар барлыкка килә һәм шартлый.

Бер җирдә Сәерленең аягы таеп китте дә ул чак кына егылмыйча калды.

...Аны Василий Егорыч Князев дип йөртәләр иде. Аңа тумышыннан утыз тугыз яшь. Ул авылда киномеханик булып эшли. Шымчылар белән этләрне ярата. Балачакта шпион булырга хыялланган иде.

Русчадан **Әхәт САФИУЛЛИН** тәрҗемәсе.

Бөек җырчы дустым

(Ахыры. Башы 5, 6 нчы саннарда).

1970-1980 елларда Илһам Казахстан шәһәрләрендә үзе оештырган «Идел» инструменталь оркестры белән гастрольдә була, аның шанлы концертлары зур залларда аншлаг белән шаулап, гөрләп уза. Казах дуслар да җавапсыз калмады. Шул ук 1962 нче елның декабрендә Казанда казах әдәбияты һәм сәнгате атнасы узды. Г.Камал театры бинасында (хәзер Тинчурин театры) казах язучылары, шагыйрьләре чыгышларын тыңладым, спектакль, концерт карадым. Яшь шагыйрь, кып-кызыл күлмәк кигән Олҗас Сөләйманов үзенең рус телендә иҗат иткән шигырьләрен укып, алкышларга күмелде. Сүз башым кунак турында иде бит, дәвам итәм.

Беренче секретарь Ф.Табеев автомобиль җибәреп, Илһамны һәм баянчы Зиннур Гыйбадуллинны Идел елгасы буендагы Обком дачасына китертә. Илһамның моңлы җырлары кунакка бик ошый, һәр җырга ул кул чабып утыра, рәхмәт әйтә. «Җан тартмаса, кан тартыр», – ди татар мәкале. Горурланырлык бит – дәүләтнең олуг эшлеклесе кырык эшен читкә куеп, Илһамның җырларын тагын бер кат тыңлау өчен, Казанга махсус килгән! Сәнгатькярләрне кунак белән бер минутка да үзләрен генә калдырмыйлар. Шулай да Кунаев аларга сорау бирә: «Тормышларыгыз ничек, егетләр?» Егетләр сер бирми: «Әйбәт яшибез, Динмөхәммәт Әхмәдович!» Концерт тәмамланып, кунак башка бүлмәгә чыккач, Илһамнар янына Табеев керә. «Егетләр, шәп концерт бирдегез, кунакка бик ошады. Кирәк нәрсәгез бармы?» Илһам шундук гозерен әйтеп сала: «Баянчының фатиры юк»... Бер атна эчендә Зиннур Гыйбадуллин, Гөлшат апа һәм кызы Асия Зәйнашевалар Шмидт урамындагы ике бүлмәле фатирга күчте. Илһам бу очракта үзенә бернәрсә дә сорамаган, ә дусларын әйбәт фатирлы иткән...

Ярдәмчел, игелекле зат иде Илһам дустым. Аның хәерхаһлы гамәлләрен санап бетерерлек түгел. Бигрәк тә яшь сәнгатькярләргә, музыкантларга, җырчыларга аның ярдәме күп булды. Менә аларның берничәсе: композитор Рәшит Кәлимуллин, җырчылар Ринат Ибраһимов, Салават Фәтхетдинов, якташы Зөһрә Сәхәбиева-Бигичева, Зөһрә Шәрифуллина, Венера Ганиева, Хәмдүнә Тимергалиева, Гөлзада Сафиуллина һ.б. һ.б.

Илһам – галим, чын эрудит иде. Ул күп китаплар укыды, галимнәр, сәнгатькярләр, язучылар белән аралашты. Татарстан, аның сәнгать тарихын өйрәнде; милләтебезнең күренекле шәхесләре белән кызыксынды. Дингә, сәясәткә үз фикере булды. Матбугатта сәнгатьнең актуаль мәсьәләләренә кагылышлы тәнкыйть мәкаләләре дөнья күрде, радио, телевидениеда чыгышлары тамашачыларны битараф калдырмады. Ул телевидениеда махсус тапшыру да алып барды, бик күп әңгәмәләрдә катнашты, соңгысы 2019 елның 15 гыйнварында булды.

Мин аптырый идем – Татарстанда олпат язучылар, журналистлар, композиторлар, башка сәнгатькярләр күп, ә бөек җырчыбыз Илһам Шакиров турында кулга алып укырлык бер китап, альбом чыгармыйлар. Вакытлы матбугатта аның тиңдәшсез иҗаты турында шактый күп мәкаләләр, фоторәсемнәр дөнья күрде анысы. Илһам үзе дә, оста публицист буларак, татар сәнгате, музыкасы, җыры проблемалары турында, аларны үстерү, камилләштерү юлларын күрсәтеп, тирән эчтәлекле мәкаләләр язды.

Инде халык мәхәббәтенә ирешкәч, Илһам турында, ниһаять, 1973 елда Казанда «Җырчы» исемле беренче кечкенә генә китап нәшер ителде. Ни гаҗәп, авторы галим-археолог, тарихчы Равил Фәхретдинов (1937-2014) иде. Ул Илһамның җыр сәнгатенә, гүзәл тавышына, тирән моңына, башкару осталыгына югары бәя бирде. Җәмәгатьчелек, күренекле затлар да китапны җылы кабул итте. Алар арасында шагыйрә Гөлшат Зәйнашева да бар иде. Соңрак бөек җырчыбызның юбилей елларында югары сыйфатлы, истәлекле китаплар, фоторәсемле альбомнар пәйда булды. Мәшһүр затлар Илһам турында якты кайнар хатирәләр белән уртаклашты, аның иҗатына югары бәяне белдерде. Бу саваплы эшне Татарстанның күренекле шагыйрьләре Разил Вәлиев, Гәрәй Рәхим һәм рәссам Фәйзерахман Камал сыйфатлы, тирән эчтәлекле итеп башкарды. Дустымны сагынып, «мин аларны еш кулыма алам, аларның изге сәхифәләрен актарам» (Г.Тукай, Китап, 1909 ел).

Күренекле шагыйрә, Г.Тукай премиясе лауреаты Гөлшат апа Зәйнашева – нәселебезнең «йөзек кашы», намуслы, нәтиҗәле хезмәте, оригиналь популяр иҗаты белән киң җәмәгатьчелеккә танылса да, гомеренең күп елларын тузган торакта, бер бүлмәле коммуналь фатирларда үткәрде. Колхоз базары тирәсендә Ямская урамындагы шундый фатирына Илһам белән без әледән-әле барып йөрдек. Биредә алар дүрт җан яшәде: Гөлшат апа, ире Зиннур Гыйбадуллин (композитор, баянчы), аның ерак туганы Рәзинә, Гөлшат апаның кызы, мәктәп укучысы Асия, өстәвенә бишенче өйдәш булып, Минзәләдән Казанга эшкә килгәч, бераз мин дә торып алдым. Илһам килгәч, өч сәнгатькярнең боткасы пешә, алар өр-яңа җыр иҗат итә. Зиннур баянда, Илһам рояльдә музыка тудыра, үзе җырлап та ала. Мине гаҗәпләндергәне шул – бирегә күренекле иҗат әһелләре: композиторлар, язучылар, җырчылар килеп йөри. Бүлмә тар булса да, хуҗаларның күңеле киң, кунакларны тәмле чәй белән каршы ала. Ә әңгәмәләр һәрчак иҗат мәсьәләләре турында була. Кунакларның мин күргәннәре: композиторлар Сара Садыйкова, Александр Ключарев, Бату Мөлеков; шагыйрьләр Мостафа Ногман, Роберт Әхмәтҗанов; язучы, элек шушы фатирда ике баласы белән яшәгән Әминә Бикчәнтәева, булачак язучы, минем Минзәләдәге дустым Фәнзаман Баттал, астроном Ким Шакиров һ.б. булды.

Җәйнең матур бер көнендә без Илһам белән Гөлшат апаның Идел буендагы дачасында ял иттек, елгада рәхәтләнеп коендык. Гөлшат апа тәмле аш, чәй белән сыйлады, өстәл янында әңгәмә өзелмәде.

Илһам Г.Зәйнашева сүзләренә иҗат ителгән җырларны мәңге онытылмаслык итеп башкарды. Шулардан берничәсе: «Туган җирем – Татарстан», «Иң кадерле сүз» (А.Ключарев музыкасы); «Китмә, сандугач», «Үзең аңла» (Р,Яхин); «Менәргә иде Урал тауларына», «Тукайны сагыну», «Тибрәнә җыр күңелемдә» (М.Мозаффаров). Татарстан гимны дәрәҗәсендәге бу җырлар туган илгә мәхәббәт тәрбияли, безгә рух бирә.

Ярты гасыр дәвам иткән хезмәт дәверендә Илһам СССРны аркылыга-буйга йөреп чыкты, концертлары күп урында аншлаг белән узды. Матбугатта чагылган, Илһам булган шәһәрләрне санадым – 32 чыкты (үзебезнең республика исәпкә алынмаган). Өстәвенә чит илләр – Төркия, Финляндия шәһәрләре. Бөек җырчыбыз каһарман зат иде, кайбер концертларда ул 20-30 җыр башкарды. Илһамга 1970 еллар азагында: «СССРның халык артисты исемен аласыгыз килсә, русча җырлагыз!» – дип әйткәннәр. Моңа каршы Илһам: «Башта Зыкина татарча җырлый башласын», – дип җавап биргән!..

Җыр сөюче тамашачылары белән хушлашу концертында (2010 ел) 75 яшендәге Илһам соклангыч итеп, моңлы җырлар башкарды, зур зал көчле алкышларга күмелде.

Илһам белән 2011 елда Г.Тукай музеенда, бөек шагыйрьнең тууына 125 ел тулуга багышланган кичәдә очраштык. Мин залда утыра идем, зур чәчәк букеты тотып, Илһам килеп керде, кочаклап алды. Без сөйләшеп торганда, музей директоры Рәмис Аймәт Илһамның кулындагы чәчәк букетына үрелде, берәр вазага куймакчы булгандыр. Илһам: «Сиңа түгел ул, Тукайга», – дип бирмәде. Илһам белән кочаклашып фотога да төштек.

Бөек җырчыбыз, 85 яше туларга бер ай кала, каты авырудан соң, 2019 елның 16 гыйнварында бакыйлыкка күчте. Бу көндә Моң ятим калды, халкыбыз зур шәхесебезне югалтты.

Илһамның моңлы җырлары минем магнитофон тасмаларында саклана, аны бик сагынам, әледән-әле җырларын тыңлыйм. Интернетта аның турындагы фильмнарны, видеороликларны кабат-кабат карыйм, җуелмас хатирәләрне яңартам. Шәхсән мин шуңа канәгать – бөек җырчыбыз, минем дустым Илһам Шакиров исемен мәңгеләштерү максатында хөкүмәтебезнең зур күләмле программасы тормышка ашырыла, бу саваплы гамәлдә җәмәгатьчелек, аның якташлары, авылдашлары актив катнаша. Казандагы музеена мин дә берничә кадерле, җуелмас экспонат бүләк иттем.

Марс ГАИТОВ.

Мәдәни җомга
22 февраль
№7, 2023

Кылкаләмле

Тимур Яруллин Санкт-Петербургта яшәп иҗат итә. Ул – танылган рәссам-маринист. Аның эшләрендә нинди генә кораблләр сурәтләнмәгән! Күбесе – тарихи кораблләр һәм алар прототипларының техник параметрларына да тулысынча туры китерелгән. Тәҗрибәле «диңгез бүресе»нең иҗаты сокланырлык!

Рәссам Алтайдагы Бийск каласында туган. Әтисе Назиф Нуретдин улы – татар, Томскида туса да, аның нәселе Татарстанга, Болгар якларына барып тоташа. Әнисе – рус милләтеннән, Августа Петр кызы – Новосибирск өлкәсенең Речник авылыннан. Бу гаилә ике ир бала үстергән.

Тимур Назиф улы – III ранг капитаны дәрәҗәсенә ирешкән хәрби. Ул кайчандыр үзе укыткан институтта рәссам булып эшли.

Тормышта ирешелгән максатлар күп очракта балачактагы хыялларга да барып тоташа... Безнең әңгәмә дә кыю, зыялы милләттәшебезгә сабый чагын янә искә төшерде...

– Тимур әфәнде, сез 1961 елда дөньяга килгәнсез. Балачакта: «Үскәч, космонавт булачакмын!» дигәнсездер инде?

– Нәкъ шулай, андый теләк тә булды... IX сыйныфта укыганда ук, парашют белән сикерергә йөрдем, ДОСААФ оештырган курста ике ел җитди шөгыльләндем. Укырга теләсәм, Волчанское авиация училищесына алачаклар иде. Ләкин урта мәктәпне тәмамлауга ук, башка һөнәр сайладым. Беркем дә бернинди дә киңәш бирмәде. Үзем шундый карар кабул иттем.

– Сез балачакта сәнгать мәктәбендә укыдыгызмы?

– Юк. 6 яшемдә без Томск каласында күчендек. I сыйныфта балалар сынлы сәнгать түгәрәгендә өч ай гына шөгыльләндем. Рәсем ясауга төшенә генә башлаган идем, тиз арада кыш җитте, ул чакта кар күп иде, чанада, чаңгыда шуасы, кар тәгәрәтеп уйныйсы килә башлады. Малайларның бик сирәге генә кызлар белән рәсем ясап кына утыра аладыр, түгәрәккә башка бармадым, әмма андагы укытучыбызны әле дә хәтерлим, ул миңа игътибарлы булырга өйрәнергә киңәш итте. Мәктәптә стена газеталары ясауда да катнаштым әле.

Дәү әтием Нуретдин Галәветдин улы 1944 елда Ленинград тирәсендәге яуда батырларча һәлак булган. Әбием Фирүзә Гобәйдулла кызы – җор телле, укымышлы мишәр ханымы иде. Ул гомере буе татарча, русча, гарәпчә китаплар укыды. Аныңниндидер бер гайре табигый сәләте булган. Чөнки безнең гаиләдә сөйләүләренчә, мин бик кечкенә чакта ук татар әбием: «Моряк туды!» – дигән. Аннары энем тугач, анысын инде үзем дә хәтерлим, әбием: «Менә философ туды!» – дигән иде. Энем Максим, чыннан да, күп гыйлем җыйды, армиядән кайткач та укыды.

Күңел кечкенәдән суга тартылды, дип әйтмәс идем. Ләкин балачакта бер хәл булды: II сыйныфта укыганда, әнием тиз арада суган алып кайт әле дип, кибеткә җибәрде, үзе кечкенә энемне карап калды. Үзем белән яшьтәш Оля Мерзлякова һәм Паша Покасов та янәшәмдә иде. Суган алгач, аларга Себер хакында бәян кылдым. Аннары: «Суган бар, зәңгәлә чире безне куркытмас! Әйдәгез, Себергә барабыз!» – дидем. Дусларым анда бару юлын белми иде, үземчә «өйрәттем»: «Мин беләм! – дидем. – Томь буенча Обька кадәр йөзеп барачакбыз, ә аңа чыккач, Салехард янәшәсеннән генә узачакбыз да, Кара (Карское) диңгезенә җитәчәкбез, ә аннан инде... Арктика да күренеп торачак! Киттек!» Дусларым: «Җайлы икән», – диеште. Һәм без көймәләр станциясенә таба чаптык, тимер чылбыр белән генә бәйләп куелган бер көймәне таптык. Көймәне этеп җибәрдек тә, өчәүләп шуңа кереп утырдык һәм йөзеп тә киттек. Ярдан 100 м киткән идек. Елга безне бик тиз арада үзенә таба тартты, ә көймә төбе тишек булып чыкты. Кот очты. Ә яр буйлап бер ир-ат йөгерә, үзе нидер кычкыра. Без теплоход янәшәсендә идек, матрослар озын саплы тимер ыргак белән көймәбезне эләктереп алды. Ярга чыгардылар, «Батырлык» өчен Оляга да, Пашага да, әлбәттә, миңа да бераз эләкте, аннары алардан качтым. Өйгә кайткач, әни дә ачуланды, чөнки минем өр-яңа, бер дигән сандалиларым инде киярлек түгел иде, тик ниләр булганын әниемә әйтеп тормадым.

– Аннары?

– Аннары 1976 елда гаиләбез белән Севастопольгә ял итәргә бардык, Кара диңгезне күреп сокландым. Ул шулкадәр матур булып тоелды, өстәвенә, диңгез өстендә нинди генә кораблар юк иде... Флот бәйрәме узган көннәр булган икән. Шулчак башыма «үскәч, диңгезче булырга кирәк» дигән уй килде. Севастопольгә тагын әйләнеп кайтыр өчен дип, әти-әнием диңгезгә бакыр акча атты, ә мин атмадым. «Мин болай да биргә кайтачакмын, ә өстемдә хәрби кием булачак», – дидем. Шулай килеп чыкты да. Ленинградның Ленин исемендәге Югары хәрби-диңгез инженерлык училищесының пар көче һәм газ турбиналары җиһазлары факультетында укый башладым. 1981 елда училище практикасын нәкъ шушы калада үттем. Ә әти-әнием әлеге шәһәргә бары биш ел узгач кына, минем янга кунакка килде.

Укуны инженер-механик белгечлеген алып тәмамладым. Хәрби хезмәтем 1984 елда Севастопольдә, Кызыл Байраклы Кара диңгез флоты корабында, 30 нчы дивизиядә, 5 нче электромеханик хәрби частьта башланып китте. Кораблардагы хезмәтем 10 ел дәвам итте. Ул вакытта рәсем ясау турында уйланылмады әле, ял айларында гына ясадым, һәм, билгеле инде, Кара диңгезне!

– Хезмәтегезне кайда дәвам иттегез?

– Бераздан «Очаков»та хезмәт иттем, I машинистлар группасы командиры вазыйфаларын үтәдем... 1988 елда хәрби хезмәтемне, үз теләгем буенча, Потида дәвам иттем. Ләкин тыныч вакыт бетте, бер ел узуга анда сугыш башланды. Советлар Союзы таркалды. 1992 елда безне аннан чыгардылар... Янә Севастопольдәге хезмәтемә әйләнеп кайттым. 1994 елда Хәрби-диңгез инженерлык институтының электротехника факультетына курс башлыгы итеп билгеләндем, курсантларны укыта башладым. Яхшы гыйлемле профессионаллар әзерләдек, шәкертләрем мине бүген дә онытмый, бәйрәмнәр белән котлый, рәхмәт сүзләре яза. Укытучы булгач, буш вакыт та артты һәм бихисап китаплар укып чыктым. Хәрби хезмәтемне дә юксындым, билгеле, диңгезләрне дә... Ни гаҗәп, кешеләр диңгезгә күбрәк ярдан карап соклана, ә диңгездә озаграк йөрсәләр, алар ярга карый. Күңелне төрле хис били иде. Шуннан соң кечкенәрәк форматтагы картиналар иҗат итәргә алындым. Бүгенгеләре инде – зур күләмлеләр. Баштарак акварель, гуашь белән ясадым, хәзер инде акрил, темпера белән иҗат итәм.

– Иҗат темалары озак уйландырадыр? Диңгез стихиясе күңелләрне аулый...

– Әйе, әүвәл кораб портреты дигән исем генә куя идем, үзем хезмәт иткән кораблләрне сурәтләдем. Аталышлары, борттагы номерлары да язылып куелды. Аннары – башкаларын. Беренче күргәзмәмне 1997 елда үзем укыткан факультетта ачтым. Сурәтләр яхшы килеп чыккач, нигә аларны башкаларга да күрсәтмәскә! Ошаттылар. Мин – тыйнак кеше, уңай бәяләмәләргә шатландым. Бераздан Пушкин каласы хаки-

● «Татарстан» сак корабы.

● «Казанец» мина ташучы корабы.

● Көймәләргә каршы сугыш корабы (1134а проекты.)

● «Сообразительный» эсминецы.

● «Киров» крейсеры Кронштадт янында.

«диңгез бүресе»

мияте дә иҗатым белән кызыксынып, яңа күргәзмә ачарга булды. Аннары курсантларым белән Североморск каласына практикага киттек, анда да күргәзмәм узды, соңрак нәшер итү белән бәйле гозерләр белән дә мөрәҗәгать итә башладылар.

Тарихи темаларга да тотындым. Чөнки тарихи китаплар укырга яратам. Ошаткан рәссамнар бар инде ул... Тик шул да истә: хәрби хезмәтем башлангач та, лейтенант чакта ук, гел үз-үземә: «Истә калдыр! Истә калдыр! Шушы суларны! Шушы Күкне!» – дип боерык бирә идем. Шулай итеп, күңелдә, хәтеремдә төрле хис-кичерешләр туплана барды.

Әсәрләрем төрлечә языла, кайчак кайбер корабларның төгәл техник схема-сызымнарын да өйрәнеп утырам. Мәсәлән, Икенче бөтендөнья сугышында катнашкан «Ямато» линкоры схемасы 120 биттән торды, шуңа күрә аның белән бәйле хезмәтем дә шактый озак ясалды (Искәртим: «Ямато» XXI гасырда да кешелек тарихында төзелгән иң куәтле линкор булып санала). Башта аның күп детальләрдән торган схемасын дисктан кәгазьгә күчереп алдым, аннан соң гына иҗат иттем. Үзем хезмәт иткән кораблар төзелешен яхшы беләм, алары истә, билгеле. Калганнарының схемаларын интернетка чумып та эзлим, кораблар бик катлаулы төзелешле машиналар, аларны тиз арада сурәтлим димә! Тарихларын да өйрәнәм. Быелгы беренче картинам да тарихи темага багышлана. «1942 елның 30 мартында Кильдинский плесында «Гремящий» эсминецының немец су асты көймәсенә һөҗүме» дип атала.

– *Аеруча истә калган берәр күренеш хакында сөйли аласызмы*?

– 1985 елда, яшь лейтенант чагымда, безнең кораб Севастопольнең «Минная стенка» причалында тора иде. Беркөнне матрослар стартерны суга төшереп җибәрде, ныклы трос буенча төшеп, шуны судан эзли башладым, ә соңыннан аңлашылганча, ул җирдәге диңгез төбе 16 м тирәнлектәге ләм икән, берничек тә табып булмаячак... Йөзә-йөзә эзлим шулай, берзаман өскә карасам... мин үз корабыбыз астында. Мондый күренешне күрүче сирәктер ул. Минә шул да искә калган. «Үтә күренмәле су» дигән картинамны әлеге кичерешләрем буенча яздым.

Бер картинамда Хәрби-Диңгез көчләребезнең миноносецлар эскадрасын әйдәп баручы «Ташкент» корабы тарихын да сурәтләдем. Аның хакында китапны III-IV сыйныфта чакта ук укыган идем. Ул 1937 елда итальян белгечләре тарафыннан төзелгән, аннары илебезгә кайтарылган. Аның тарихын «Аллаһ Тәгалә фәрештәләре саклап барган» дигән гыйбарә белән бәйләп карарга мөмкин. «Ташкент» 1942 елны Севастопольдән 2100 дән артык кешене алып, Новороссийск шәһәренә юл алган. Ул тиз дә барган, хәрби кораллары да куәтле булган. Фашистларның йөзгә якын бомбардировщигы аны 4 сәгать дәвамында бомбага тоткан, бу орышта «Ташкент»ка төбәп 336 авиабомба ташланган, җитди зыян килгән, аңа башка корабларыбыз да булышлык күрсәткән һәм ул Новороссийск каласына кадәр барып җиткән. Кызганыч, соңрак аны барыбер саклап кала алмаганнар.

– Сезнең әсәрләрдә диңгезләр, су стихиясе камил сурәтләнә. Бу осталык каян килә?

– Сәнгать юнәлешендә беркайчан да укымадым. Бу – бары үз сәләтем, үз тырышлыгым нәтиҗәсе. Курсант чагымда елына ике тапкыр Рус музеена бара идем. И.Айвазовский картиналарын карап, аның киндерләренә «борынымны терәп» өйрәндем. Ясау техникасын җитди төшенгәнмен булып чыга, чөнки миңа: «Картиналарыңдагы сулар салкынлыгын тоябыз!» – диючеләр дә бар. Моңа бик куанам.

– Шәхси күргәзмәләрегез еш узамы? Иҗатыгызны күрсәткән альбомнар бармы?

– Мин – С.Джевецкий исемендәге Халыкара координация үзәге эксперты, шулай ук Пётр фән һәм сәнгать академиясе әгъзасы. Североморск, Санкт-Петербург, Севастополь, Мурманск, Полярный калаларында узган күргәзмәләрдә катнаштым.

2008 елда «Морское собрание Республики Татарстан» төбәк иҗтимагый оешмасы чакыруы буенча, 11 картинамнан гыйбарәт шәхси күргәзмәм Казандагы 78 нче урта мәктәптә ачылды, аннары ул Бөек Ватан сугышы мемориал-музеенда да булды. Әлеге киндерләрдә Татарстан белән бәйле кораб сурәтләре чагылдырылган иде, әйтик, «Комсомолец Татарии», «Казанец», «Татарстан»... Мине шушы оешманың шәрәфле әгъзасы итеп тә кабул иттеләр. 11 картинам Казан музейларында калды, ә аларның күчермәләре «Морское собрание РТ» җәмгыятендә дә бар.

«Морской сборник» журналына иллюстрацияләр дә ясадым, альбомнар һәм уку әсбапларын бизәдем. Рәсемнәрем «Океанский щит России», «Корабли советского Военно-Морского флота России 1922-1991гг», «Оружие и технологии России XXI века. Подводные силы России» энциклопедияләренә дә кертелде. К.Булахның «Полный вперёд!» һәм «Сказки старого крейсера» дигән китап тышлыкларын да иҗат иттем. Картиналарым буенча тематик альбомнар да нәшер ителгән, алар арасында «Северная верфь», «Балтийский завод», «Северное проектно-конструкторское бюро», «К 100-летию профессионального проектирования подводных лодок ЦКБМТ «Рубин» альбомнары да бар.

Баштарак картиналарымны дусларыма гына бүләк иттем, аннары хезмәтләрем белән дәүләт музейлары да кызыксына башлады. Әсәрләрем Россия су асты көчләре музеенда саклана. Кайберләре – АКШ, Шотландия, Голландия дәүләтләрендәге шәхси коллекцияләрдә. Күп кенә әсәрләрем – Төньяк һәм Тын океан флотлары корабларының кают-компанияләрен, Хәрби-диңгез политехника институты диварларын да бизәп тора. Бүгенге көндә «1942 елның 27 июнендә лидер «Ташкент»ның Севастополь чылбырын өзеп чыгуы» дип аталган картинам белән бәйле рәвештә Россиядәге иң борынгы музейларның берсе – Санкт-Петербургтагы Император Бөек Петр исемендәге Үзәк хәрби-диңгез музее белән килешү эшләре бара.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәскәүдәге яңа мәчет, җанисәп һәм мөфтият

Россия мөселманнары Дини җыены башлыгы, Мәскәү шәһәре мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Чуашия Республикасы мөфтие Әлбир хәзрәт Крганов белән әңгәмә.

– Әлбир хәзрәт, исламда милләт турында ни әйтелгән? Гомумән, дин ягыннан бу мәсьәләгә нинди караш?

– Милләтне саклау – мөһим мәсьәлә. «Исламда милләт дигән нәрсә бармыни?» – дип сорау бирүчеләр булгалый. Чынлыкта, исламда «милләт» төшенчәсе телгә алына. Әйтик, гарәп милләте турында әйтелә. Без хәдискә таянып эш итәбез. Кыямәт көнендә Аллаһ Тәгалә ирләрдән: «Никахтан соң, гаиләңне ничек тәрбияләдең, дөрес юл күрсәттеңме?» – дип сорар. Имамнарга да сорау бирелер: «Мәхәлләдә кешеләргә дөрес юл күрсәтә алдыңмы, ислам дининең нигезен җиткерә алдыңмы?» Ил җитәкчеләре дә җавап бирәчәк. Шуңа күрә, татар булып дөньяга килгәнсең икән, беренче чиратта, үз гаиләң өчен җаваплы булган кебек, үз милләтең, халкың өчен дә җаваплы буласың.

Дөньялар үзгәрде. Элек Россия төбәкләрендә милләттәшләребез күп булса, хәзер Россия эчендә миграция зур, Кавказ, Урта Азиядән мөселман кардәшләрбез күченеп килә. Мәчетләрдә элекке гореф-гадәтләр, мәҗлес тәртипләре үзгәрде. Вәгазьләр дә элек татар телендә булса, хәзер татарлар азчылык рәвешендә калганга күрә, рус телендә сөйләргә туры килә. Русча сөйләгәндә дә сорау туа. Күп кенә гыйбарәләр татар телендә йөз еллар буена кулланылган, аларны рус теленә туры тәрҗемә итеп булмый. Ислам терминнарын дөрес итеп аңлатыра кирәк. Мәсәлән, кайберәүләр билгеле бер терминга тәңгәл килә торган рус сүзен табып аңлата. Бу дөрес түгел. Ислам дөньясындагы зур галимнәр дә шул фикердә. Чөнки сүзнең мәгънәсе аңа туры килми, исламдагы мәгънәгә теләсә нинди кулланышта булган рус сүзе белән тәрҗемәсен бирә алмыйбыз.

– Мәскәүдә күпме татар бар дип уйлыйсыз?

– Мәскәүдә татарларның санын төгәл күпме икәнен белү кыен, чөнки шәһәр бик зур. Мәскәүдә 4 мәчет, аннан тыш намаз бүлмәләре бар. Яһүдләрнең мәхәлләсендә исемлек китабы бар, алар бөтен гаиләләр белән элемтәдә тора. Ничә кеше, белемнәре нинди, нинди юнәлештә хезмәт итәләр һ.б. язылган. Шул гаиләләрне бер-берсе белән таныштырып, күрештереп торалар. Мәскәүнең яңа территорияләрендә яһүдләрнең яңа 3 оешмасы бар, шул оешма арасында яшьләрне туплап, бизнес-клубта лекцияләр укыйлар, шул рәвешле эш алып баралар. Аларның мәхәллә халкы белән турыдан туры элемтәсе бар. Ә безнең мәчетләрдә бу нәрсә юк...

Хәзер Коръән укый белә торган кешеләр артты, мәчетнең кирәге дә калмады кебек. «Безнең бу абзый да укый белә»дип, шуны гына чакыралар. Ләкин эш мәҗлестә түгел. Элекке тәртип – халык белән мәчет арасындагы элемтә югалды. Бу Мәскәүдә бер проблемага әверелде. Шуңа күрә башкалада күпме татар яшәгәнен дә белә алмыйбыз.

– Җанисәптә катнаштыгызмы соң?

– Җанисәп вакытында өйгә килүче булмады, «Госуслуги» порталы аша язылдым. Әмма анда катлаулы сораулар бик күп, һәрберсенә җавап бирү авыр. Мөфти буларак кына түгел, Россия Федерациясенең Иҗтимагый Палата әгъзасы буларак, җанисәп алуга сорауларым күп. Җанисәпне кемнәр оештырган икән? Нәтиҗәләр, йомшак итеп әйткәндә, матур түгел. Татар гына түгел, башка милләтләрнең дә саннары бик күпләп кимеде. 16-17 миллион кеше үзен бер милләт вәкиле итеп тә күрсәтмәгән!

Җанисәп үтте, ул тагын 10 елдан соң оештырылачак... Безне санамаган вакытта да татар булып яши алдык, беркая да китмәдек. Иң мөһиме – милләттәшләребезнең үзләрен татар итеп хис итүе. Үзләрен мөселман дип санаулары да мөһим, мөселманлык татарлыкны саклый. Бу гыйбарәгә беркем дә каршы түгелдер. Татарлар 1 миллионга гына калган икән, дип әйтә калсалар да, татар халкының, абзыйларыбызның үзләрен татар итеп хис итеп, шуның белән горурланып яшәве кирәк.

«Без берничә миллионга күбрәк!» – дип әйтсәк тә, кадеребезне арттыра алмабыз. Сыйфат юнәлешендә эшләргә кирәк. Бу – милләтебез, тамырлардан югары белемле, алдынгы фикерле кешеләрне күбрәк булдыруны күз уңында тоту дигән сүз. Без 50 миллион булып та, шундый кешеләрне үстерә алмасак, 50 миллион булуыбыздан файда юк. Әгәр азрак булсак, ләкин милләтебез арасында шундый кешеләрне дөньяга тудыра алсак, ул вакытта берничә генә татар да бөтен дөньяга татар халкын танытып, татар барлыгын күрсәтеп торырга мөмкин. Бу эш безнең өстә тора.

– Яшьләрне татар җанлы итеп үстерү өчен нишләргә кирәк?

– Татарстанда яшьләр белән, аерым алганда, «Сәләт» программасы белән актив эшлиләр. Бу программада 20 меңнән артык егет һәм кыз катнашып, яшь талантларны дөньяга чыгаралар. Шундый гамәлләрне күбрәк эшләргә кирәк. Чуашиядә иске мәктәп мәйданында «Сәләт-Батыр» бинасы төзелде, анда 150-200 торак бар, килгән кешеләргә тору мөмкинлеге каралган. Шуның кебек проектларны күбрәк уйлыйсы иде.

«Татарстан – Яңа Гасыр» телеканалының эшләве дә әйбәт. Ял көне каналны ачкач, балалар татар концертлары карый. Бер сүз, ике сүз булса да, барыбер, күңелләренә керә. «Таяну ноктасы», «Ком сәгате» кебек кызык тапшырулар да бар. Мәгънәви яктан тирәнлек сизелә. Ләкин болар гына җитми, дәвам иттерергә кирәк.

Халыклар дуслыгы турында фильмнар күрсәтегез әле дип, Россиянең халык артисты Н.Михалков, «Мосфильм»ның генераль директоры К.Шахназаров белән дә сөйләшкән булды. Татар телевидениесендә кинолар бар, ләкин алар хәзерге заманга туры килми. Әйе, анда бик дөрес нигез салынган: бер-береңне хөрмәт итү, миһербанлы һәм шәфкатьле булу һ.б. сыйфатлар яктыртыла. Ләкин яшьләргә башка төрле юнәлеш кирәк.

Балалар өчен татар мультфильмнары кирәк. Фильм һәм мультфильм балаларның фикерләвен формалаштыра. Инициативаны тудырып тормасак, ул вакытта без иртәгә баручылар түгел, ияреп баручыларга әйләнәчәкбез.

– Мәскәүдә мәчет төзелеше көтелмиме?

– Мәскәүдә 4 мәчет комплексы эшли. Мөселманнарның җомга намазы вакытында мәчетләргә сыя алмау проблемасы бар. Безнең санатып караган булды: 4 мәчетне бергә кушсак, Мәскәүдә кимендә 30 меңнән артык кеше җомга саен мәчеткә керә алмый, урамда кала. Кешеләрне сыйдырып булмый. Гомумән, 4 мәчет эченә, күп дигәндә, 15-20 мең кеше сыя.

Зур бәйрәмнәрне әйтеп тә тормыйм. Гает намазына 300 әр мең кешене сыйдыра торган мәчет булыр дип әйтә алмыйм. Ләкин өметләнәбез. Соңгы тапкыр Мәскәүдә мәчет төзүгә җир бирелгәнгә 25 ел вакыт узып китте. Тынычлык проспектындагы Җәмигъ мәчетенең яңартып төзелүе 110 ел элек бирелгән җир территориясендә булды. Мәчет мәйданы берничә мең кешене сыйдырырлык булып зурайды. Ләкин Җәмигъ мәчетенә дә кеше сыеп бетми.

2012 елда Мәскәү мэры С.Собянин алдында без бу мәсьәләне күтәргән идек, Аллага шөкер, ул уңай хәл ителде. Яңа Мәскәү дигән территориядә 5 миллионнан артык кеше яши торган яңа шәһәрчек барлыкка киләчәк. Сосенки дигән авылда балык буасы белән Калуга шоссесы уртасында 6 гектар җирдә төрле диннәр комплексы төзеләчәк. Бу хакта Мәскәү шәһәре карары бар. Шушы 6 гектарда мөселман, христиан, буддист, яһүдләрнең комплексы булачак. Шуның 3 гектарга якын җире (2 гектар 75 сутый) Мәскәү һәм Үзәк төбәк мөфтиятенә тапшырылды. Минә инде 1 елдан артык аның җитәкчесе булып хезмәт итәм. Хәзер шушы территориядә мәчет проекты эшен алып барабыз. Комплекс татар һәм Урта Азия архитектурасын берләштереп төзеләчәк. Комплекста мәчет, мәдрәсә, резиденция, күп функцияле бүлмәләр, ислам дине музеен төзергә исәплибез. Музей татар имамнары чалмасы кыяфәтендә булыр, дип уйлыйбыз.

Быел төзү эшләрен башлап җибәрергә ниятлибез. Шул ук вакытта, яһүдләр, христианнар, буддистлар да шул эшләр белән мәшгуль, без үзара аңлашабыз, аралашабыз. Әлеге комплекс төзелеше өчен «Бәрәкәт» дигән иганә фонды булдырдык. Химаячеләр советында 30лап татар кешесе бар.

Мәскәү шәһәрендә 9 мәхәлләбез исәпләнә. Мөфтият янындагы бинаны сатып алып, ремонт ясадык. Ул мәдрәсә булачак, көзен Зәйнулла ишан Рәсүлев исемендәге мәдрәсәне ачып җибәрәчәкбез. Хәзер анда лицензия алу эшләре, җиһазландыру бара. 2 мең кв. метрлык – үз милкебез ул.

5 ел элек Мәскәү өлкәсендә мөхтәсибәт оештырган идек, өлкәдә барлыгы 24 мәхәллә бар. Хәзер аларны «Мәскәү өлкәсе Дини җыены» дип, исемен үзгәртәбез. Звенигород дигән шәһәрдә мәчетне төзекләндерергә, реконструкция ясарга уйлыйбыз. Якуб Вәлиуллин дигән булдыклы кеше 1994 елда ук шунда мәхәллә оештырган иде, анда ярты гектар җир бар. Тарихи яктан карасак та, XVI гасырда ике бертуган татар кешесенә рус патшасы Звенигородта җир биргән, алар йомышлы татарлар булып яшәгән.

Безнең мәхәлләдә 150 гә якын татар хатын-кызлары укып йөри. Имамнарыбыз, хәзрәтләр – барысы да татарлар. Җомгага да татар абзыйлары килеп тора.

– Луганскидагы мәчетләр дә төзәкләндереләчәк, дип ишеттек.

– Луганскида Җәмигъ мәчете марттa ук Россия мөселманнары Дини җыены карамагына керде. Анда 14 мәхәллә эшли, хәзерге вакытта Луганскидагы мәчетне төзекләндерү эшләре бара, аларга акча бүлеп бирелде. Аннан тыш, 10 га якын кечкенә мәчет бар. Аларга да реконструкция ясарга уйлыйбыз. Херсон өлкәсе, Запорожьедагы мөселманнар безнең белән элемтәгә чыга, анда 50-60 лап мәхәллә бар, бергә эшләү юлларын карыйлар. Луганскида имамнарның 90 проценты – татарлар. Аларның күбесе Пенза өлкәсеннән. Татар оешмалары да бар анда.

– Мәскәүдә татар телле мохит тудырыр өчен нәрсә тәкъдим итәр идегез?

– Яһүдләрдән дә өйрәнәсе нәрсәләр күп. Алар синагогага шимбә көнне килеп, Тәүрат укып, чәй эчә һәм шуның белән кайтып китми. Анда тормыш кайнап тора. Мәчетләрдә дә шулай эшләргә иде. Җомга намазына барып кайту белән генә эш бетми. Гыйбадәтханәләрне мөмкин кадәр тулы көчкә кулланырга кирәк. Ул Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) вакытында да шулай булган: дәресләр дә үткән, балалар да уйнаган, хатын-кызлар да килгән. Мәчетләрне шундый үзәккә әйләндереп, эш итәргә кирәк.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА

intertat.tatar.

● Галим Фоат Галимуллин Ш. Мостафинны искә алу кичәсендә чыгыш ясый.

Эзтабарның исеме югалмасын!

Бөек Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм иткәндә шагыйрь, прозаик, публицист, «Хәтер Яктысы» эзләнү экспедициясе җитәкчесе Шаһинур Мостафинның «Ядрәләрне эреткән йөрәкләр», «Алар-Җәлил-Кормаш йолдызлыгыннан», «Батырлык кайтавазы» китаплар триптихы өчен җөмһүриятебезнең иң зур Дәүләт бүләге булган Габдулла Тукай исемендәге премиягә тәкъдим ителүе игътибарга лаек изге гамәл булган иде. Әмма Шаһинур абыйдан да гаярь әдипләр булуы ачыкланды...

Әдәбият белеме галиме, КФУ профессоры Ф.Галимуллинның аның турында әйткән сүзләре истә калган: «Шаһинур безнең әдәбиятка һәм тарихка үзләреннән бинихая зур өлеш керткән Рафаэль Мостафин, Шамил Рәкыйпов кебек өлкән әдипләребез белән кулга-кул тотынып эшләде һәм бүген дә аларның алыштыргысыз дәвамчысы булуын раслады».

Хәзер әдипнең тормыш баскычларын хәтеребездә яңартыйк. Шаһинур Әхмәтсафа улы Мостафин 1948 елның 12 февралендә Татарстанның Мамадыш районындагы Арташ авылында туа. Әтисе – урманчы, Бөек Ватан сугышы инвалиды. Унбер балалы гаиләдә ул – иң өлкәне. Туган авылында башлангыч мәктәпне тәмамлагач, күршедәге Урта Кирмән сигезьеллык һәм Түбән Ушмы унберьеллык мәктәпләренә йөреп урта белем ала. Шул ук елларда, әти-әнисенә, эне-сеңелләренә матди ярдәм итү максатыннан, кичләрен авыл клубында киномеханик ярдәмчесе булып эшли. 1966 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Көндезге бүлектә ике ел белем алгач, ишле гаиләсенә булышу өчен, читтән торып уку бүлегенә күчә һәм университетны 1972 елда тәмамлый. 1968 елдан Шаһинур – Мамадыш районында чыга торган «Коммунистик хезмәт өчен» (хәзерге «Нократ») газетасының әдәби хезмәткәре. 1970 елда гаиләсе белән Кукмара бистәсенә күчеп килә һәм биредә «Хезмәт даны» газетасына хатлар бүлеге мөдире булып урнаша. Ш.Мостафинның 12 елдан артык гомере әлеге район газетасы белән бәйле. 1983 елдан ул гаиләсе белән Казанга күчеп, Халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре буенча республика фәнни-методик үзәгендә баш мөхәррир хезмәтен башкара. 1988–1992 елларда – СССР һәм РСФСР Язучылар берлекләре Әдәбият фондының Татарстан бүлеге директоры хезмәтендә. 1992–1999 елларда – «Казан утлары» журналы редакциясендә мөхәррир, бүлек мөдире. 1999 елның августыннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары; 2006 елның апреленнән – «Сүз» китап нәшриятының баш мөхәррире...

Ш.Мостафин әдәбият сөючеләргә шагыйрь, публицист, документаль проза өлкәсендә эшләүче каләм әһеле буларак таныш. Иң беренче шигырен ул, М.Җәлилгә багышлап, алтынчы сыйныфта укыганда иҗат итә. Республика матбугатында 1963 елдан күренә башлый. 1965–2003 еллар арасында иң яхшы шигырь, хикәя, очерк, публицистик язмаларга республика күләмендә оештырылган иҗади бәйгеләрдә ул 12 мәртәбә җиңүче исеменә лаек була. Аның күпсанлы очерклары, кыйссалары, публицистик язмалары республика матбугатында, элеккеге СССР һәм чит илләрдә нәшер ителә торган дистәләрчә газета-журналларда, «Иркен минем Туган илем», «Безнең Ангелиналар», «Ана бәхете», «Җирдәге йолдызлар», «Җиңү дәвам итә», «Көзге ачы җилләрдә», «Халык бәхете өчен көрәшчеләр», «Мамадыш – яңарышта», «Җырларыбыз», «Безнең сәхнә», «Җырлап ачыла күңел» һ.б. күмәк җыентыкларда урын ала.

Ш.Мостафин, эзтабар әдип буларак, яу кырында ятып калган каһарманнарны барлау, алар кылган батырлыкларны, якты исемнәрен киләчәк буыннар хәтеренә җиткерү юнәлешендә дә армый-талмый эшли. Остазлары Гази Кашшаф, Рафаэль Мостафин, Самат Шакир, Шамил Рәкыйпов юнәлеш биргән үтә авыр, әмма игелекле шөгыльне дәвам итә. Ш.Мостафин җитәкчелегендәге «Хәтер яктысы» экспедициясе әгъзалары, хәрби архивлардан соң Балтыйк буе һәм Кавказ республикаларында, Волгоград, Донецк, Кировоград, Орёл, Ленинград, Львов, Мәскәү, Псков өлкәләрендә, Карелиядә һәм Германиядә булып, Бөек Ватан сугышының моңарчы билгесез батырлары турында бай мәгълүмат туплап кайтты.

2000 елда, Бөек Җиңүнең 55 еллыгы уңаеннан, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән «Батырлар Китабы» – «Книга Героев»ның баш консультанты һәм мөхәррирләренең берсе дә булды Шаһинур. Җиңүнең 60 еллыгын исә ул «Хәтер яктысы» дигән документаль-публицистик язмалар китабы белән каршылады. Ш.Мостафинның журналистика, әдәбият һәм хәрби-тарихи публицистика өлкәсендәге эшчәнлеге Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге премиясе, Татарстан Язучылар берлеге һәм Мамадыш районы хакимиятенең Ш.Маннур исемендәге премиясе, Кол Гали исемендәге Халыкара премия белән билгеләп үтелде. Аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем дә бирелде. 2003 елда ул Татарстан журналистларының «Бәллүр каләм» бәйгесендә хәрби темага язган әсәрләре белән лауреат исеменә лаек булды...

Татар әдәбияты белгече, профессор Фоат ага Галимуллин бүген Шаһинур Мостафинга алмаш булырдай эзтабар язучылар булмавы өчен борчыла. Ш.Мостафин исемендәге әдәби бүләк булдырырга тәкъдим итеп:

– Бөек Ватан сугышы вакытында җиңүгә үз өлешләрен керткән кешеләрне өйрәнү күптәннән дәвам итә. Кабатламыйча булмый, Самат Шакир, Шамил Рәкыйпов, Рафаил Мостафиннардан соң бу ифрат кирәкле эшне Шаһинур Мостафин армый-талмый дәвам итте. Кызганыч, бүген без эзтабар язучының 75 еллыгын гына билгеләп үтәбез. Аның бу өлкәдәге эшчәнлеге Татарстан Республикасы Язучылар берлеге тарафыннан искә алыну бик кирәкле гамәл. Шушы өлкәне яңа югарылыкка күтәрү өчен Ш.Мостафин исемендәге бүләк гамәлгә куелса, кызыксыну артыр иде, – диде.

Мөхтәрәм галим фикеренә Язучылар берлеге колак салыр дип уйлыйк...

Рамазан КӘБИРОВ.

Атнаның сәяси мизгелләре

Мюнхен конференциясе ни майтарган?

Иминлек буенча Мюнхен конференциясе узган атнаның төп сәяси вакыйгаларыннан берсе булды. 17-19 февральдә үткән бу чарада 45 илдән дәүләт һәм хөкүмәт җитәкчеләре һәм 90 министр катнашкан. Россиядән делегатлар чакырылмаган. Ә төп мәсьәлә буларак, анда Украинада һәм Россия белән бәйле хәлләр күтәрелгән һәм, кайбер экспертлар әйтүенчә, көн тәртибе дә «автократиягә каршы демократия» дигән тезиска кайтып калган. Сәяси күзәтүчеләр бигрәк тә АКШ вице-президенты Камала Харрис, Бөекбритания премьер-министры Риши Сунакның кискен чыгышларын билгеләп үтә. К.Харрис, әйтик, Мәскәүне кешелеккә каршы җинаять кылуда да гаепләгән. Сунак исә Украинага хәрби ярдәмне ике тапкыр арттырырга чакырган. Ә НАТО генераль секретаре Йенс Столтенберг Финляндия һәм Швецияне альянска әгъза итеп алу процессы 11-12 июльдә Вильнюста узачак саммитка кадәр төгәлләнер, дигән ышанычын белдергән. Украина президенты В.Зеленский да үзенең видеоэлемтә аша ясаган чыгышында, Библия персонажларын кулланып, Украина һәм аның халкын Давид патша белән, ә Россияне Голиаф образы белән чагыштырган. Кытай вәкиле (илнең элеккеге тышкы эшләр министры) Ван И исә Европа илләрен Украинадагы кискен вәзгыятьне тыныч юл белән җайга салу турында уйланырга чакырган.

Атнаның игътибарга лаек кайбер сәяси вакыйгаларын бер җөмлә белән генә булса да билгеләп үтик: Россиянең 101 хәрби хезмәткәре Берләшкән Гарәп Әмирлекләре ярдәмендә Украина әсирлегеннән азат ителгән. БМО КШ утырышында Кытайның даими вәкиле Чжан Цзюнь Россия һәм Украинаны, атышны туктатып, тыныч сөйләшүләрне башларга чакырган. Россиядә гипертизлекле «Кинжал» ракеталарын җитештерүне арттырганнар. Молдова исә БДБ буенча килешүләрне денонсацияләү эшенә керешкән. Хәрби хезмәткәрләрне өстәмә социаль яклау турында Россия президенты имзалаган карар буенча, МХО барышында үзен күрсәткән «Росгвардия» сугышчыларына Кырымда һәм Мәскәү янында җир участокларын бушлай алу хокукы бирелгән. АКШ дәүләт секретаренең сәяси эшләр буенча урынбасары Виктория Нуланд Кырымда урнашкан хәрби объектларны Украина өчен законлы мишень дип санавы турында белдергән. Вашингтон Кытайның Россиягә сугыш кораллары җибәрү мөмкинлеге АКШ өчен бу илнең «кызыл сызык»ны узуын аңлатачагы турында белдергән.

Фоат УРАЗАЙ.

Мәдәни җомга
22 февраль
№7, 2023

Исхакыйның яңа тәхәллүсләре

Гаяз Исхакый 1919 елда туган иленнән чыгып киткәч, берничә тапкыр матбага ачарга омтылыш ясап карый. Бу мөмкинлек бары тик 1928 елда гына туа. Архангельскидагы сөрген елларын бергә кичкән фикердәше, бу чорда исә Польша хөкүмәтенең башлыгы, маршал Йозеф Пилсутский (1867-1935) әдипне Варшавага чакырып ала, аңа үз матбагасын оештыруда ярдәм итә. Г.Исхакый Варшавада торып, кызы Сәгадәт һәм кияве Таһир Чагатайлар да катнашып, Берлинда «Милли юл» (соңыннан «Яңа милли юл») чыгара башлый. Мәҗмуганың беренче саны 1928 елның декабрендә дөнья күрә. Әлегә абунәчеләре, хәбәрчеләре булмаганлыктан, Исхакый, баштарак чорларда мәҗмуга битен нигездә үз мәкаләләре белән тутыра. Мәкаләләр әдипнең үз исеме белән дә, тәхәллүсләр белән дә чыга.

Г.Исхакый әсәрләре 15 томда 1998-2014 елларда басылып чыкты. «Милли юл»дан алынган мәкаләләр басманың 10-13 томнарына урнаштырылган. Тик бу томнарда әдипнең «Гаяз Исхакый», «Гаяз» имзалары һәм туган илендә чагында ук билгеле булган «Чыңгыз» тәхәллүсе белән басылган мәкаләләре генә урын алган. Публицистик томнарны төзүчеләр бу мәҗмуга белән эш иткәндә, бүтән төрле имзалар белән басылган мәкаләләргә игътибар бирмәгән. Хәлбуки «Милли юл»да Исхакыйның берничә яңа тәхәллүсе бар. Мәҗмугада әдипнең «Чура батыр» тәхәллүсе белән басылган мәкаләләре барлыгын үзем төзегән, 1998 елда басылып чыккан беренче томга искәрмәләрдә язган идем инде.

Исхакый тәхәллүсләр итеп күбрәк үз күңеленә якын булган исемнәрне ала. Аның әлеге «Чура батыр» тәхәллүсен карыйк. Язучы «Тәрҗемәи хәлем»ендә энисе турында язганда болай ди: «Әниемнең әтиләре, әниләре ундүрт буынга кадәр голяма (укымышлылар) зөмрәсеннән, Казанның хәле авыр вакытта Кырымнан Кырым шаһзадәләре идарәсеннән Казанга ярдәм итәргә килгән, "Чура батыр" хикәясенә тема биргән кешеләр токымыннан», – ди. Тәхәллүсләрдән «Иделбай» дигәне, аңлашыла инде, әдипнең туган ягын хәтерләтеп тора, «Илтәзәр» дигәне дә Исхакыйның бертуган энесе Әхмәтхәсәннең улының исеме. Язучының 15 томлыкта басылып чыккан әсәрләре белән таныш булган укучы югарыда аталган тәхәллүсләр белән чыккан мәкаләләрдә һичшиксез Исхакыйны «таныячак». Фикерләре, стиле белән генә түгел. Ә бәлки әле автор яратып кулланган аерым гыйбарәләрнең, сүз тезмәләренең, хәтта җөмләләренең төрле әсәрләрендә еш кабатланып килүен дә күрәчәк.

Катгыйлык, сарказм, тәкәллефсез тәнкыйть – күбрәк Исхакыйның тәхәллүсләр белән чыккан язмаларына хас кебек...

Чигенеш ясап, бераз тарихка мөрәҗәгать итик әле.

Г.Ибраһимов революциягә кадәр Исхакыйның иҗатына зур бәя биреп яза. Мәсәлән, ул «Татар матбугаты» исемле мәкаләсендә («Йолдыз» 1910, 5 май) болай ди: «Әдәбият мәйданында хәзер иң шәүкәт илә вә иң бөек урында карт реалист Гаяз әфәнде тора. Бу мөхтәрәм – татар әдәбиятына башлап реализмны кертүче иде. Әле һаман да аның мәүкыйгысы (урыны) ялгыз диярлек дәрәҗәдәдер. Без аның хикәяләре кадәр реальный бер әсәргә матбугатымызда очрый алганымыз юк әле... Татар шагыйре мәйданда Тукаев исә, нәсеремездә мәйданда иң гали ноктада Гаяз әфәндедер. Аның әсәрләре укырга да күңелле, сабак та бирә, алдыңа татар мәгыйшәтенең төрле-төрле җанлы ләүхәләрен (күренешләрен) дә китерә».

Г.Ибраһимов үзенең ибтидаи (башлангыч) һәм рөшди (урта) сыйныфлар өчен әзерләгән, өч басмада (1914, 1918, 1919) бастырып чыгарган «Яңа әдәбият» дәреслегенә Исхакыйның «Мулла бабай» романыннан өзекләр китерә. Ул өзекләргә мондый исемнәр бирә: «Хозурга чыгу», «Арыган ат», «Авыл мулласы өендә», «Урман һәм кыр», «Кыш көне мәдрәсәдән кайткач», «Язгы сабанда», «Җәйге эш вакыты», «Ачлык ел». (Г.Ибраһимов Исхакыйның башка әсәрләреннән дә мул итеп өзекләр бирә). Ягъни дәреслек авторы Исхакыйның әсәрләре мәктәпләрдә укытылырга лаек дип саный. Әмма өч елдан соң, 1922 елда (Исхакый инде чит илдә) шул ук «Мулла бабай» турында Г.Ибраһимов бүтәнчә яза: «Хәзерге буынның алдагы гөруһы (төркеме) «Кыямәт», «Мулла бабай»ларны фикерләре, мәгънәләре ягыннан үткән, артта калган дип карый. Бу яктан алардан һичнәрсә көтми. Аларның мәсьәләләре, фикерләре, кәгъбәләре, әмәлләре – һәммәсе ул карчыклар белән карт хәлфәгә җан азыгы».

Өч ел эчендә бер үк әсәр турында әдиптә капма-каршы фикерләр тууын ничек аңларга? Дөрес, Җамал Вәлиди Г.Исхакыйны яклап чыга: «Мулла бабай» кай арада модадан чыгып, мәгънәсез бернәрсә булып киткән? «Мулла бабай» кебек иске татар тормышының бөтен ягын кочаклаган, һәртөрле типларга, табигать тасвирларына гаять дәрәҗәдә бай булган, татар әдәбиятының мәңге кыйммәтле хәзинәсе булган олуг бер диңгез хакында мондый сүзләр язу, минем карашымча, татар әдәбиятын бөтенләй инкяр белән бәрабәрдер. Әдәбиятка бу төрле караш – гәзитә яки календарьга караган шикелле бер караш була түгелме соң? Теге начар, чөнки былтыр язылган, ә бу шәп, чөнки быел гына чыккан... Галимҗан иптәш кеби үзен игътибарлы бер тәнкыйтьче итеп таныткан кешенең тар фикерлекне бу дәрәҗәгә җиткерүе соң дәрәҗәдә көенечле бер хәлдер, өстләренә яшьләрне тәрбия кеби мөһим бер вазыйфа йөкләнгән икән, әдәби извращение белән шөгыльләнүдер» («Татарстан хәбәрләре», 1922, 5 март).

Бу чорда Г.Ибраһимов Г.Исхакыйны, гомумән, «күз ачтырмыйча» тәнкыйтьли. Хәтта төрлечә хурлый, шәхескә кагылып, мыскыллый: «Җилкуар», «таңчы», «шарлатан», «хулиган», «теш ыржайтып...» һ.б. Сүз сәяси вакыйгалар турында барганда да, тәнкыйтьләгәндә дә сүзләрне сайлап тормый: «...1905 елда вак буржуа социализмы юлында «таңчы» иде. Реакция вакытында буржуазия көчәйгәч, социализмнан, революционлыктан тәүбә кылды – регенат, мөртәт булды». «...Динне зур хакыйкать буларак марксизмнан өстен бернәрсә итеп йөттырырга азаплана». «...Советка каршы сугыш ачкан булып, наданлык, ахмаклык сатучы, тагы шундый каралыклар белән тулы бер адәм ул!», «Ерак Себерләр аркылы дөньяның төрле-төрле җирләрендә хур сәргәрдан (аптыраган) булып...», «Бездә әбүҗәһелләр, ишмиләр, пуришкевичлар бар әле, ләкин бу әбүҗәһелләрнең саны алты бер гарип кулның бармаклары хисабынча гынадыр. Бу өч игезәк: Садри-Фуад, Закир-Гомәр, Баттал-Гаяз».

1918 елның апрелендә большевиклар Уфада Милли идарәне туздырып, банктагы акчаларын да конфискацияләгәч, Г.Исхакый Милли идарә әгъзалары белән бергә Кызылъярга (Петропавелга) күченеп китәргә мәҗбүр була. Шул вакыйгаларга бәйле рәвештә Г.Ибраһимов болай яза: «...Безнең милли «вәзирләребез» пычрак юлларда начар арбаларга кәнсәләрияләрен төяп, үзләре яланаяк ат яныннан җәяүләп качарга мәҗбүрләр», «Фуад-Гаяз-Баттал компаниясе чех-Колчак арбасына дегет лагуны булып китеп баралар». «Качканда бер шәһәргә барып җитәләр икән, менә хөкүмәт, менә җирле мөселманнар квартир бирми, урынлашырга ярдәм итми...», «Сукырлыкның чигенә җиткән кайбер кызганыч бәндәләр әле һаман да «милләт өчен», «дин өчен» Париж банкирларының бусагаларына йөзләрен сөртеп йөриләр», «Берлин, Париж урамнарында өстерәлеп...» һ.б.

Г.Ибраһимов әсәрләренең беренче фәнни басмасы 1974-1986 елларда басылып чыкты. Ул башта унтомлык итеп планлаштырылган иде, ниндидер сәбәпләр табылып, сигез томга калдырылды. (Соңыннан әдипнең хатлары, документлары өстәмә 9 нчы том булып, 2000 елда дөнья күрде. Төзүчесе Фатыйма Ибраһимова).

Сигез томлыкның 1-6 нчы томнарында төп эшне Рашат Гайнанов башкарды. Бигрәк тә 5-6 томнарда тәнкыйть һәм публицистика томнарын төзүдә аның көче күп керде. Р.Гайнанов әзерләп, машинкада бастырып куйган, басмадан төшеп калган бер томлык публицистик материалларны мин соңгы елларда Г.Ибраһимовның күптомлыгын әзерләүче текстологлар кулына тапшырдым.

Тарихи материалларны эченә алган 7нче томны – Сәлим Алишев, ә тел гыйлеменә караган 8 нче томны Лена Гайнанова әзерләде. Соңгы томдагы әсәрләргә искәрмәләрне Фазыл Фәсиев язды. Г.Ибраһимовның архивы юкка чыккан, аның һичнинди библиографиясе дә юк иде. Шуңа күрә томнарны төзүчеләргә әдип иҗат иткән чорда гарәп язуында басылып чыккан һәммә газета-журналларның һәр санын җентекләп карап чыгарга туры килде. Бу эштә безгә Р.Гайнановның гомере буе җыйган, Миркасыйм Госманов «хикмәтле» дип атаган картотекасы бик ярдәм итте. Нәтиҗәдә 5 нче томга кергән материалларның дүрттән өч өлеше, ә 6,7,8 томдагылары исә – тоташ хәзерге язуда беренче тапкыр дөнья күрде. Бу томнарга Г.Ибраһимовның Г.Исхакый иҗатына зур бәя биреп язган мәкаләләре кермәде, ярамады, аны тәнкыйтьләгәннәре генә алынды. Бу тәнкыйть мәкаләләрен укыганда Рашат абыйга әйтә идем: «Г.Ибраһимов нинди олы шәхес, ә ничек ваклана – тәнкыйте башка бер язучыны тиргәүгә, хурлауга кайтып кала. Нигә шулкадәр усаллана соң ул?» Рашат абыйның җавабы: «Көнчелек! Көнчелек – татарның төзәлмәс ярасы».

Г.Ибраһимов үзе турында: «Мин – рәхимсез тәнкыйть тарафдары һәм шундый тәнкыйтьләрнең зур файдасына ышанган кешеләрнең берсемен», ди. (Өч җавап – «Татарстан хәбәрләре», 1922, 28 апрель).

Г.Исхакый туган илдәге хәлләрне, шулай ук үзе турында нәрсәләр язуларын да белеп торган. Мин моны аның «Милли юл» мәҗмугасы белән таныша башлагач аңладым. Польша хөкүмәте үзенең Мәскәүдәге совет илчелеге аша гайрерус мөһаҗирләре юлбашчыларының оешмасы булган «Прометей»га газеталар, журналлар алдырып барган. Г.Исхакый даими рәвештә алардан хәбәрләр бастырып чыгарган. Аеруча «Кызыл Татарстан»нан күп мәкаләләр, өзекләр бастырган, тәнкыйди мәкаләләр язган. Мөһаҗирләрне илдәге вакыйгалар белән таныштырып торган. Г.Исхакый Г.Ибраһимовның үзе турында нәрсәләр язганнарын да белеп торган. Биредә укучыларга тәкъдим ителә торган мәкалә Г.Ибраһимов язмаларына кайтаваз булып яңгырый. Исхакыйның юраганнары юш килә. Революция үз балаларын да кызганмый, берәм-берәм тәгәрмәче астында калдырып юк итә. Кызганыч ки, большевизмны ничек кенә якламасын, совет властена күпме генә тугрылыклы хезмәт итмәсен, Г.Ибраһимов та шул тәгәрмәч астына эләгә...

Шуны да әйтергә кирәк, Г.Исхакыйның төрле тәхәллүсләр белән чыккан мәкаләләр җыентыгы озак көттерми басылып чыгар дип өметләнәбез.

Лена ГАЙНАНОВА.

Патшалар заманасында иң уң канатта йөреп, «Йолдыз» газетасында язучылардан булган Галимҗан Ибраһимовның, революция булыр булмас, бердән үтә кызыл булып киткәне, әлбәттә, бик күп кешенең хәтерендәдер. Бу әфәнде 1917 ел революциясеннән соң уң с.р. була башлады. Керенский күздән төшкәч, ул сул с.р. булды. Сул с.р.ләр алман илчесе Мирбахны үтерүдә гаепләнеп кулга алынгач та, Галимҗан Ибраһимов с.р.лектән тәүбә итте. Бу – ике көн эчендә марксист булып алды, аннары коммунист булды да рус өмәчелегенә сызганып кереште. Идел-Урал буенда большевикларның милли мәдәниятче халкымызны талавында Галимҗан Ибраһимов Шаһгалидән уздырырга тотынды. Милли идарәне ябуда, халык хезмәтчеләрен тоттыру вә үтерүдә ул кылмаган яманлыкны калдырмады. Милли хәрәкәтемезне большевикларга куркынычлы итеп күрсәтер өчен милли идарәчеләрнең карагруһларга акча бирүләре хакында ялганнар вә доносслар ясады, мәкаләләр язды. Үзен аны саклап калды. Аны Кырымга сөрделәр дә шунда үзе дөмегер әле диделәр дә куйдылар. Галимҗан дәваланыр өчен Яурупага чыгарга маташты. Яурупага чыгып китсә, бездән бөтенләй ычкына, анда тәүбә кылып милләтче булыр дип курыктылар булырга кирәк, Галимҗанга рөхсәт бирмәделәр. Ләкин Галимҗан авыру булса да үлмәде дә үлмәде.

Хәзер менә тагы партиядә бик нык «тазарту» бара. Шуңа карата «Яңа авыл» гәзитәсенең 18 нче, 20 нче сентябрь номерларында Х.Наум дигән бер кеше, озын мәкаләләр белән Галимҗанга күдрәя башлады. «Уң оппортунизм»да Галимҗанны гаепләде. Аны латин әлифбасына каршы чыккан 82ләрнең җаны, башы, яшерен милләтче итеп күрсәтергә тырышты. Галимҗанның китапларыннан җөмләләр алып, аны Сталинның сүзләре берлә чагыштырып, Галимҗанны хәзерге партиянең юлыннан сабучы иттереп чыгарды. Менә бу шәп большевик ни ди: «Хикмәт Г.Ибраһимовның авыру шәхесендә түгел, бәлки аның милли бур-«уңчы»лык дәлилләрен бүген үзенә каршы куялар. Г.Ибраһимовны партиядән чыгарып, аны алып ята торган акчасыннан мәхрүм итмәкче булалар. Ник соң бу болай?.. Руска каршы иткән хезмәте өчен Г.Ибраһимовның шул мәрхәмәткә генә дә хакы юкмыни?.. Шаһгалигә бит Мәскәү ул кадәр каты кыланмаган иде. Шулай, күрәсең, кичә Солтангалиевләр, бүген Г.Ибраһимовлар, иртәгә шул ук Атнагулов, Наумнарга кизү җитәчәк. Чөнки булар бары да татарга, иске барлыгыны, иске җанлылыгыны исенә төшереп, хәтерләтеп торалар. Алар барысы да бетәргә тиеш... Алар барысы да яңа октябрь мәдәнияте, руслыкның үсүенә тирес булырга тиеш... Чөнки Мәскәүнең максаты бит төрле-төрле телдә сөйли торган, төрле мәдәниятләргә тарихы берлә баглана торган халыкларның, үзләренең тарихы вә милли юлларын саташтырып, Мәскәүгә бәйләү, Мәскәүне генә, руслыкны гына үрнәк иттереп таныту. Иске чарлар (патшалар) моңа сатлык хан балаларын рус балтасына сап итәләр иде.

Большевик мирзалары ызгышалар



«шәп инде син, мелла Галимҗан абый» димәгәннәргә күз ачырмады. Мәскәү бу кешенең хезмәтен бушка чыгармады. Аңа «молодец!» дип үзен Татарстанның белек үзәгенә баш иттерде. Галимҗан белек үзәгенең бөтен басып тарату эшенә хуҗа булды. Үз китапларын казна хисабына бастырып, үз-үзенә тулы язу хаклары бирде. Ул баеды, акча җыйды. Уйланды-уйланды да, үз тирәсенә Габдулла Сәгъди вә Шенаси кебек «каләм ялагай»ларын җыйнады. Вак-төяк малай-салайны туплап, үзен мактап, көндәшләренең кайберсен уңга тайпылучы, кайсысын сулга тайпылучы дип гаепләп, милличелектә гөнаһлы иттереп күрсәтеп, тиңсез, ишсез, бердәнбер чын коммунист булды да куйды.

Ләкин бу уңган кызыл түрә кыска күзлелек ясады. Мәскәүнең бөтен төрек-татарны руслаштыруга дигән чын теләген вакытында аңлап өлгерә алмады. Ул Мәскәүне, Идел-Урал буеның милли оешмаларыны җимереп бирү эше берлә канәгатьләнер, әле бик үк тиз чеп-чи иттереп руслаштырырга керешер дип уйлый алмады. Төрек-татар берлеген нигезеннән ватар-җимерер өчен Мәскәү төрле кабиләләргә латин әлифбасы исемендә яңа әлифбалар ясый башлаганның мәгънәсен аңлап җитә алмады. Латин әлифбасына каршы чыкты. Аның дошманнары шуннан файдаланды. Галимҗан Ибраһимов бик тиз генә: «Әйттем, кайттым, партия (ягъни Мәскәү) ни кушса шуны эшлим!» – тәүбәне итсә дә, аңар Мәскәүнең шөбһәсе уянды. Аның урынына аннан йөз мәртәбә урысчы булган Сәлях Атнагуловны куйды. Галимҗан Ибраһимов күздән төште. Ул шул чорларда бик каты авырый башламаса иде, аны инде күптән «мулла баласы икәнләса бу» дип, партиядән куып чыгарырлар иде. Ләкин каты чахутка авыруы жуазный идеология шаукымнарында вә ибраһимовчылыкта, бу вак буржуазный милли агымнарны тукландыра торган туфракның «ияле милек» нигезендә корылган хуҗалыгында» ди вә шундый бер нәтиҗә чыгара: «Без аларны күрер өчен маскаларны ачып күрсәтергә, милли оппортунизм берлә рәхимсез көрәшергә тиешмез... Ибраһимовчылык төрле вакытта төрле рәвештә качамак юллар берлә милли шаукымнар тараткалый. Безнең бурычыбыз – милләтчеләр һәм аларның төрле төстәге ачык һәм яшерен берлә рәхимсез көрәшү!» – дип сүзен бетерә. Кырымда авырып яткан вә читкә чыгарга рөхсәт бирелмәгән Галимҗан Ибраһимовка бу мәкаләләр бик каты ырым ясый. Ул шул мәкаләләрне алгач та 27 сентябрьдә телеграмм берлә «Кызыл Татарстан»га җавап күндерә. Хәзер Казанда партияне тазарту вакыты булганга,әгәр җавабын почта берлә язса, вакытында барып җитә алмас та үзен партиядән куып чыгарырлар дип курыккан булырга кирәк, 70 юллык бер мәкаләне телеграм берлә җибәрергә акчаны кызганмый. Җавап 29 сентябрьдә «К.Т.»да басылып чыга. Аның җавабы да, Наумның күдрәюе дә, берсен берсе Маркс шәригатенә сыймый торган эшләрдә гаепләү булганга, безгә боларның Маркс ноктасыннан кайсы хаклы, кайсы хаксыз булуының кыйммәте юк. Булар икесе дә милли яктан караганда хаксыз һәм зарарлы рус өмәчеләре. Берсе өмәдә кояш баеганча булган, имеш, берсе большевик кояшы бата башлагач күләгәгә качкан, имеш; безнең өчен әһәмияте юк. Булар икесе дә милли хаин.

Ләкин шуны күздән качырырга ярамый, бүген Галимҗан Ибраһимовны, үзенең милләтчеләргә каршы (Мохтаров һәм Солтангалиевләргә) кулланган «милләтче» камчысы берлә кыйныйлар. Үзенең дошманнарына каршы кулланган Шуны «мөкаддәс христианлык» исеменә эшлиләр иде. Бу көнгеләре «мөкаддәс коммунизм» исеменә Галимҗан Ибраһимовны корал итеп кулланалар. Аның кирәге беткәч сыгылган лимон кебек аны ыргыталар да ташлыйлар. Аннан соң Атнагуловны, Наумны, Мәхмүд Нәдимне, Кулаевны кулланалар. Аларның эчләре сыгылып бетеп кирәкләре калмагач, тагы бер яңа имансызны китереп чыгарачаклар. Бу большевик идарәсе дәвам иткәнчә шулай барачак.

Большевик, ахмак төрек-татар балаларын тилертеп, үзенең халкын талатып, үзенең мәдәниятен, милли барлыгын җимертеп торачак. Шуның өчен бүген Г.Ибраһимов та ролен уйнап бетергән бер большевик булганга, аның да «мулла баласы» булып партиядән чыгарылуы, яисә уңга тайпылучы хисапланып айлык акчасыннан мәхрүм ителүе бик көтелерлек бер эш. Аны моннан саклап алып калса чирлелеге генә алып калачактыр. Шуның шулай икәнен Галимҗан тирәсендә черү башланганны зирәк Наум сизеп алган да, хуҗаларына яхшы күренер өчен өрергә тотынган. Моны тигенгә түгел, Г.Ибраһимовның җавабындагы кебек интригантлыктан гына да түгел, үләксә исен сизгәнлектән, үзенең мираска иялеген күрсәтер өчен, нәкъ материалистларча, карьеристларча эшләгән.

Шулай бит, Галимҗан? Рус өмәсенә йөргәндә, синең кирәгең булганда, бәлки, бик кадерле булгансыдыр! Инде ул көннәр үтте; сине себереп ыргытырга, икенче өмәчеләр чакырыла; көннең кунаклары – алар. Дуңгыз ите дә, урыс маржасы да, аракысы да аларга биреләчәк. Син инде хуҗаларыңа дога кылып тыныч кына ята алсаң ят, юкса, малай, кара!..

ЧУРА БАТЫР.

«Милли юл», 1929 ел, № 20-21, 10-12 битләр.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

25 февраль (шимбә). ***Шәгъбән аеның 5нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 9.15 сәгатьтә калка, 1.13 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.21 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә эти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул, үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур.

Чөгендер сихәте

3 литрлы банкага шакмаклап туралган 1 кг чөгендер, ярты “Бородинский” икмәге, 2 аш кашыгы шикәр, ярты чәй кашыгы тоз салып, өстенә кайнатып суытылган су коялар, 3 көн төнәтәләр, сөзәләр, көненә 3 тапкыр яртышар стакан эчәләр. Беткән саен, яңасын өлгертеп торалар. Мондый чөгендер куасы югары кан басымын төшерә.

26 февраль (якшәмбе). ***Шәгъбән аеның 6 нчы көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 9.26 сәгатьтә калка, 2.41 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 10.25 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Токсиннарны куу

Теләсә нинди йогышлы авырудан соң организмда токсиннар кала, аларны куып чыгару мөһим. Моның өчен 1 аш кашыгы яшь каен яфрагын яки ярты аш кашыгы каен бөресен 1 стакан кайнар суга салып, 15 минут кайнаталар, сөзәләр. Көненә 3-4 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, өлкәннәр – 1 әр аш кашыгы, балалар 1 әр чәй кашыгы эчәләр. Дәва курсы – 2 атна. Яки 2 чәй кашыгы каен бөресен термоска салып, өстенә 1 стакан кайнар су коялар, төн буена төнәтәләр дә, иртән сөзеп, көненә 4 тапкыр, ашаганнан соң 1 сәгать үткәч, чирегешәр-яртышар стакан эчәләр.

27 февраль (дүшәмбе). ***Шәгъбән аеның 7 нче көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 9.44 сәгатьтә калка. 2нче фаза. Көн озынлыгы 10.30 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

28 февраль (сишәмбе). ***Шәгъбән аеның 8 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 10.09 сәгатьтә калка, 4.00 сәгатьтә бата. 2нче фаза. Көн озынлыгы 10.35 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Каз (бәбкә) үләне

Икенче исеме – урам чирәме (горец птичий, спорыш). Бу – искиткеч шифалы үсемлек. Бөерләрне чистарту өчен, 2-3 атна буе гадәти чәй урынына каз үләне төнәтмәсе эчү бик файдалы. Әмма әлеге процедураны бары тик бөерләрдә һәм бәвел куыгында таш булмаганда гына үткәрергә ярый. Бәвел куыгындагы ташларны чыгару өчен, 32 көн буе рәттән кабыгы белән бергә 1 әр лимон ашап бетерергә кушалар, тик болай табиб рөхсәт итсә генә дәваланырга ярый.

1 март (чәршәмбе). ***Шәгъбән аеның 9 нчы көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 10.47 сәгатьтә калка, 5.10 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 10.40 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Ай календаре

1-3, 24-30 март - кыяр, кәбестә, борыч, баклажан, яшел тәмләткеч үләннәр, томат, берьеллык чәчәкләр, 11-17 март – сарымсак һәм суган чәчү өчен иң уңышлы көннәр. 7, 20, 21, 22 мартта үсемлекләр чәчү, утырту, күчереп утырту тыела.

2 март (пәнҗешәмбе). ***Шәгъбән аеның 10 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 11.41 сәгатьтә калка, 6.04 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 10.44 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уяныргa мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Тырнак катламланса

2 чәй кашыгы желатинны ярты стакан җылы суда җебетәләр, ул бүрткәч, кайнатып чыгара язганчы ут өстендә җылыталар. Бераз суыткач, киң савытка бушатып, 15-20 минут буе кулны шунда тыгып утыралар. Атнасына 3 тапкыр кабатлыйлар. Дәва курсы – 7-8 процедура.

3 март (җомга). ***Шәгъбән аеның 11 нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Кысла йолдызлыгында, 12.48 сәгатьтә калка, 6.40 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 10.49 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Кабаклы солы печеньесы

240 г солы ярмасына (хлопья) яртышар чәй кашыгы тоз, камыр көпшәкләндергеч, дарчин кушалар да, миччә пешерелгән 250 г кабак, 50 г вакланган әстерхан чикләвеге өстәп болгаткач, кечкенә шарчыклар әвәлиләр, аларны җәйпәкләп, кәгазь җәелгән табага тезәләр, һәрберсенә яртышар әстерхан чикләвеге яки 2-3 кабак төше батырып бизиләр дә, 180 градуслы мичтә 10-15 минут пешерәләр. Кабак урынына банан яки пешкән алма кушарга да була.

Бар мөлкәт – Аллаһныкы

Аллаһ Тәгалә, пәйгамбәрләр арасыннан байлык иясе буларак Сөләйман галәйһис-сәламне мисал итеп китерә, чөнки Сөләйман галәйһис-сәлам үзенә насыйп кылынган дөнья байлыгына йөрәген ялупа алырга һичвакыт юл куймый. Бөтен кешеләр берләшеп көч куеп, бергә кешене Сөләйман галәйһис-сәлам хәтле баетырга тырышсалар да, бу һич чынга аша алмас, чөнки җилләр, хайваннар, богаулы азгын шайтаннар – барсы да аның кул астында була. Шулкадәр хакимлеккә ия булуына карамастан, Сөләйман галәйһис-сәлам: «Мин бер фәкыйрь! Фәкыйрьгә фәкыйрьләр янында булу килешә!» – дип, үксезләр һәм ятимнәр янында йөри.

Түбәндәге бәетендә Хәзрәти Мәүләна куддисә сирруһ фәкыйрьләр һәм кайгы-хәсрәтле бәндәләр белән бер дулкында, юлдаш булуның рухи җәерен бик күркәм аңлата: «Фәкыйрь һәм мохтаҗлыкка чумган күңелләр төтен тулы йорткa охшаган. Син аларның кайгы-борчуларын тыңлап, аларга ярдәм кулы сузу нияте белән ул төтенле йортта бер тәрәзә ачып җибәр дә төтене таралып китсен, ә синең йөрәгең пакьләнеп, рухың йомшарсың, нәфисләнсен…»

Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм юмартлыкның һәр мөселман өчен асыл холык сыйфатына әйләнүен тели. Аның мондый сүзләре тапшырыла: «Ике кешегә генә көнләшергә була. Беренчесе – Аллаһ аңа мал-мөлкәт биреп, шуны хак юлда сарыф итәргә мөмкинлек тудырган зат; икенчесе исә – Аллаһ аңа гыйлем биреп, шуның белән гамәл кылучы һәм шуларны башкаларга өйрәтүче (ягъни гыйлемне инфак кылучы) зат» (Бохари, «Гыйлем», 15; Мөслим, «Мүсафирин», 266–268).

Коръәни-Кәримдә болай диелә: «И, кешеләр! Сез (һәркайсыгыз) Аллаһка мохтаҗсыз. Аллаһ исә Бай, (Ул гына) Мактауга лаеклы!» («Фатыйр», 15).

Аяти кәримәдән дә аңлашылганча, мал-мөлкәт, чынлыкта, кешеләрнеке дә, җәмгыятьнеке дә түгел. Мөлкәт – Аллаһныкы. Бөтен җан ияләре Җәнабел-Хак милкендә яши, Ул биргән нигъмәтләр белән тормыш алып бара, җан асрый. Бәндәләргә исә шул милектән бары билгеле бер вакыт аралыгында чикле файдалану мөмкинлеге генә бирелә.

Шунлыктан мал-мөлкәт һәм дәрәҗә бу тормышта иң зур сынау булып тора. Сөләйман галәйһис-сәламнең патшалыгы бер мизгелдә тулысынча тартып алына, бары тәүбә нәтиҗәсендә генә кабат үзенә кайтарыла. Бу уңайдан бер әүлиянең у нәсыйхәте шулкадәр гыйбрәтле һәм хикмәтле: «Ризык эзләп түгел, Раззакны эзләп йөр!»

Бервакыт кырмыскалар башлыгының Сөләйман галәйһис-сәлам патшалыгы турында башка кырмыскаларга: «Сөләйманның патшалыгы шундый зур, шундый куәтле!» – дип әйткәне риваять кылына. Моны ишеткәч, Хәзрәти Сөләйман галәйһис-сәлам: «Минем патшалыгым фани; бер тәүхид кәлимәсе бирә торган патшалык исә бакый һәм мәңгелек!..» – дип җавап бирә, чөнки ул чынлыкта мал-мөлкәт һәм хакимлекнең Аллаһныкы икәнен белә.



Давыт уразасы

Көнаралаш ураза тоту буларак билгеле «сәуме Давыт» (Давыт уразасы) – Хәзрәти Давыттан Мөхәммәд өммәтенә истәлек булып калган бер гыйбадәт төре ул. Аллаһ Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәллам «Давыт уразасы»н иң фазыйләтле ураза дип атаган.

Гамр ибне әл-Гас радыйаллаһу ганһенең улы Әбү Мөхәммәд Габдуллаһ радыйаллаһу ганһенең мондый сүзләре риваять кылына: «Валлаһи, гомерем буе көндез ураза тотачакмын, төнлә намаз укыячакмын», – дип ант иткәнемне Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә җиткергәннәр.

Рәсүлүллаһ миннән: «Бу сүзләрне син әйттеңме?» – дип сорады. Мин: «Ата-анам Сиңа фида булсын, йә Рәсүлүллаһ! Әйе, мин әйттем», – дидем.

Пәйгамбәр: «Синең моңа көчең җитмәс! Кайчак ураза тот, кайчак аша; кайчак йокла, кайчак (тәһәҗҗуд) өчен йокыдан тор! Һәр ай өч көн ураза тот! Бер яхшылыкның әҗере ун тапкыр. Бу ел буе ураза тоткан кебек була», – дип әйтте.

«Моннан да күбрәкне башкарырга хәлемнән килә!» – дип белдердем. «Алайса, бер көн ураза тот; ике көн ифтар кыл!» – дип боерды.

«Моннан да күбрәкне булдыра алам!» – дидем. «Алайса, бер көн ураза тот; бер көнне тотма! Бу – Давыт галәйһис-сәлам уразасы, уразаларның иң өстене, иң чамалысы!» – диде Рәсүлүллаһ.

Мин: «Моннан да күбрәгенә көчем җитә ала!» – дигәч, Рәсүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Моннан артыгы булмас!..» – дип боерды (Бохари, «Савм»; Мөслим, «Сыям»).

ӘЛЬЯСАГ галәйһис-сәлам

Әльясаг галәйһис-сәлам – Бәни Исраил пәйгамбәрләреннән. Балачагында бик нык авырый һәм Ильяс галәйһис-сәламнең догасы бәрәкәтендә шифа таба. Шуннан соң Хәзрәти Ильястан бер адым да калмый йөреп, анардан Тәүратны өйрәнә. Әльясаг галәйһис-сәлам дә азгын Бәни Исраил кавемен төзәтү, яхшырту өчен күп көч куя. Кайчак аңа буйсыналар, вакыт-вакыт каршы чыгалар.

Әльясаг галәйһис-сәлам Коръәни-Кәримнең ике аяти кәримәсендә телгә алына: «(И, Рәсүлем!) Исмәгыйльне, Әльясагны һәм Зөлкифлне дә искә ал. Һәммәсе дә хәерле кешеләрдән» («Сад», 48).

Аяти кәримәдә «искә ал», дип әмер бирелүе бу пәйгамбәрләрнең дә Аллаһ динен җәелдерү мәсьәләсендә хәлләреннән килгәнчә көч, фидакярлек, сабырлык һәм ныклык күрсәтүенә бәйле.

Әльясаг галәйһис-сәлам искә алынган икенче аяти кәримә мондый: «Исмәгыйльне, Әльясагны, Юнысны һәм Лутны да (һидаят биреп, пәйгамбәр иттек). Барысын да галәмнәрдән өстен иттек» («әл-Әнгам», 86).

Әльясаг галәйһис-сәламнең пәйгамбәрлек чорында кавемендәге кабиләләр арасында дәүләт белән җитәкчелек итү, идарәне кулга төшерү өчен ярыш башлана. Хәзрәти Әльясаг галәйһис-сәламне тыңламыйча, кабиләләр үзара дошманлык юлына баса. Соңсыз-хисапсыз фетнәләр, гауга-ызгышлар куба. Шуннан соң Аллаһ Тәгалә аларга Ассирия дәүләте тарафыннан һөҗүм җибәрә. Нәтиҗәдә, Бәни Исраил кабиләләре үзләренең яман эшләре сәбәпле илаһи рәхмәттән ерагая һәм, ассириялеләргә җиңелеп, хурлыкка кала һәм пыран-заран китерелә.

Нишанҗызадә Мухйиддин Мәхмәд «Мирьат әл-Кайнат» исемле китабында Әльясаг галәйһис-сәламнең могҗизалары турында сөйли:

Әриха шәһәрендәге халыкның эчәр суы әчеләнә. Кешеләр шундук Хәзрәти Әльясагка килеп, аннан ярдәм сорый. Ул исә, әчеләнгән суга бераз тоз кисәге ыргытып: «Тәмле бул!» – дип әйтә. Аллаһның рөхсәте белән су әүвәлгедән дә тәмлеләккә әйләнә.

Бурычлы бер тол хатынның Әльясаг галәйһис-сәлам янына барганлыгы риваять кылына. Ул пәйгамбәргә үзенең бик фәкыйрьлеге турындап сөйли. Хәзрәти Әльясаг: «Өеңдә нәрсә бар?» – дип сорый Теге хатын: «Бер уч чамасы маем бар!» – ди. Әльясаг галәйһис-сәлам: «Бар, шул майны бергә савыт эченә куй!» – дип боера. Тол хатын, өенә кайтып кушылганны эшләгәч, бөтен савытларның да май белән тулганлыгын күрә. Әлеге могҗиза ярдәмендә ул барлык бурычларын түли, шуннан соң да аның майлары бетми.

Үлеме якынлашкач, Әльясаг галәйһис-сәлам Зөлкифл галәйһис-сәламне чакырып ала һәм, Аллаһның әмере белән, аны үзеннән соң эшен дәвам итүче итеп билгеләп куя.

Ярамир НИЗАМЕТДИНОВ:

«Сәнгать советларын кире кайтарыр идем»

Курган өлкәсендәге татар авылында туып үскән талантлы егет үз тырышлыгы белән опера сәхнәләрен яулады.

– Ярамир, опера җырчысы буларак иҗат юлың ничек башланды? Студент чакта ук М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында эшләдең, дип беләбез.

– Консерваториягә кергәнче, мин академик музыка белән таныш түгел идем диярлек, без бит радио һәм телевидениедә нәрсә яңгыратсалар, шуны тыңлыйбыз... Консерваториядә укыганда опера һәм балет театры эшчәнлеге белән якыннан танышкач, анда эш белешә башладым, 3 нче курста укыганда солист-стажер итеп алдылар. Опера спектакльләрендә кечкенә генә партияләр бирәләр иде, шулай да алар зур тәҗрибә булды. Мин 4нче курста укыганда, «Сөембикә» операсының (либретто авторы – шагыйрь Ренат Харис, композиторы – Резеда Әхиярова) премьерасы булды. Мине дә Иван Грозный партиясенә тәкъдим иттеләр. Дирижер Владимир Рылов бу партиягә тәкъдим ителгән 5 артистны да тыңлады, минем тавыш тембрын ошатты. Аннары режиссер, «Санктъ-Петербургъ Опера» театры җитәкчесе, Россиянең халык артисты Юрий Александров Казанга килеп тыңлагач, тавышым аңа да хуш килде. Шул рәвешле, комиссия премьерада чыгыш ясау хокукын Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, танылган җырчы Әхмәт Әхәди белән миңа бирде.

– Нишләп Казанда калмадың? Ни өчен Санкт-Петербургка китеп бардың?

– Бу – тавышымның табигате белән бәйле. Аллаһ миңа көчле академик тавыш биргән, мин опера сәхнәсе өчен туган. Үземне опера сәнгатенә хезмәт итәргә тиеш дип санадым. Ә монда мин тамашачыларым белән очрашырга кайта алам. Опера җырчысы өчен Санкт-Петербургта мөмкинлекләр күбрәк.

– Санкт-Петербургта кайсы театрда эшлисең, нинди партияләр башкарасың?

– «Санктъ-Петербургъ Опера» музыкаль театрында эшлим, бүгенге көндә уннан артык партия башкарам, алар арасында төп партияләр дә, икенче пландагылары да бар. Баш рольләрдән – Джузеппе Вердиның «Риголетто» операсындагы Герцог, Гаэтано Доницеттиның «Любовный напиток» операсындагы Неморино, Петр Чайковскийның «Черевички» операсындагы Вакула, «Евгений Онегин» операсындагы Ленский, Александр Даргомыжскийның «Эсмеральда» операсындагы Феб де Шатопер партияләрен (һ.б.) телгә алырга була.

– Бүгенге татар эстрадасын күзәтеп барасыңмы?

– Күбесенчә татар композиторларының классик әсәрләре белән кызыксынам. Эстраданың да яшәргә хокукы бардыр. Аның үз роле, үз тамашачысы. Әлбәттә, профессиональ дәрәҗәсе югарырак булуын теләр идем. Яхшы артистлар күп. Төп проблема – яхшы композиторлар һәм шагыйрьләр җитмәүдә. Хәтта үзем дә Салих Сәйдәшев, Рөстәм Яхин һ.б. композиторларныкы кебек, халык хәтерендә мәңге сакланачак җыр язып бирсеннәр өчен, кемгә мөрәҗәгать итәргә белмим. Андый композиторлар бүген бик аз.

Мин радио һәм телевидениегә сәнгать советларын кире кайтарыр идем. Рәттән бөтен җырларны да экраннарга чыгару дөрес түгел. Мәдәният – ул тәрбия. Балаларның зәвыгын теләсә нәрсә белән бозарга ярамый. Чын мәдәният һәм сәнгать беркайчан да зыян китерми, ә зәвыкны тәрбияли.

– Татар музыкасы башка халыкларның музыкасыннан нәрсәсе белән аерыла?

– Һәр халыкның да музыкасында үз «моңы» була. Татар көйләренең генә моңы бар, диләр. Минем аңлавымча, моң генетик һәм тарихи яктан барлыкка килә. Үзебезнең татар музыкасын алыйк. Аның өчен драматик мотивлар хас – газап, җирсү, эти-әни темасы. Татар халкы бик күп фаҗигаләр кичергән, һәм бу – музыкада да чагылыш таба. Музыкантлар үзләрен борчыган әйбер турында яза.

Ә кайберәүләр, татар музыкасын баяннан башка күз алдына китереп булмый, ди. Ләкин бит баян – италья уен коралы. Димәк, эш уен коралында түгел, ә җанда.

Гөләндәм ФӘТХУЛЛИНА.
intertat.tatar

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

24 февраль – 15.00 Шәрык клубында – Балалар өчен рәсем дәресе. 18.00 – «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» (М.Галәү).
25 февраль – «Рәшә» (Ә.Еники).
26 февраль – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
28 февраль – «Санаулы кичләр» (А.Володин).
1 март – «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев). С.Сәйдәшев исемендәге дәүләт зур концерт залында – «Театр һәм музыка» шәлкеменнән композитор Р.Яхинның иҗатына багышланган концерт.
2 март – «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт).
3 март – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

24 февраль – «Хованщина» (М.Мусоргский).
27, 28 февраль – Ф.Шаляпин исемендәге халыкара опера фестиваленең гала-концертлары.
2 март – «Жизель» (А.Адан).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

24 февраль – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).
25 февраль – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
26 февраль – «Чулпан» (Ш.Хөсәенов).
28 февраль – «Ядәч! Исемдә! Бер гаилә трагикомедиясе» (А.Бикбулатов, Й.Миңнуллина, Э.Дусаева, М.Гафурова).
1 март – «Беренче театр» (Г.Камал).
2 март – «Назлы кияү» (К.Тинчурин).
3 март – «Кияү урлау» (С.Юзеев, Х.Ибраһим тәрҗемәсе).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

25 февраль – «Артист» (Р.Зәйдулла).
26 февраль – «Шәй-бу! Шай-бу!» (К.Кәримов).
28 февраль – «Озын-озак балачак» (М.Кәрим).
1 март – «Сәлам, Актәпи!» (А.Сальникова).
2 март – «Мио, Минем Мио!» (А.Линдгрен).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

24 февраль – Зур залда – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин). Кече залда – «Кәтүкнең сихри төшләре» (Х.Ибраһим, И.Нәфиев).
25 февраль – Зур залда – «Муха-цокотуха» (К.Чуковский). Кече залда – «Серая шейка» (Д.Мамин-Сибиряк әкияте буенча).
26 февраль – «Снежная королева» (Г.-Х.Андерсен).
28 февраль – «Бобровый пруд».
2 март – «Золушка» (Е.Шварц).
3 март – 13.00 – «Золушка» (Е.Шварц). 19.00 – «Ханума» (А.Цагарели).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

24 февраль – 15.00 – Җырчы Оксана Шәйдуллина концерты. 18.30 – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский).
25 февраль – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский).
26 февраль – 11.00 – «Золушка» спектакле. 17.00 – «Труффальдино из Бергамо» мюзиклы.
27 февраль – «Песняры» төркеме концерты.
28 февраль – «Нотр дам де пари», «Ромео һәм Джульетта» мюзикллары.
1 март – Алексей Архиповский концерты.
2 март – «Евгений Онегин» спектакле.
3 март – Композитор П.И.Чайковскийның ария һәм романсларына багышланган кичә.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

24 февраль – La Primavera оркестрына саксофончылар Бөтенроссия һәм халыкара бәйгеләр лауреатлары Мәскәүдән Гнесиннар исемендәге музыка көллияте мөгаллиме Л.Друтин һәм Казан консерваториясе доценты М.Беготова кушылып уйный. Программада – Пьяццолла, Вивальди, Глазунов, Марчелло, Молинелли, Ван Хьюзен музыкалары. Дирижерлар – Р.Абзов һәм И.Камал.
25 февраль – «Неоклассика» оркестрының Людовико Эйнауди иҗатына багышланган концерты.
26 февраль – Балалар өчен «Робин Гуд» әдәби-музыкаль тамашасы һәм ком анимациясе.
28 февраль – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Сергей Работкин башкаруында композиторлар А.Скрябин һәм П.Чайковскийның фортепиано музыкалары яңгырый.
1 март – Г.Камал театры оркестры һәм артистлары башкаруында композитор Р.Яхинның иҗатына багышланган концерт. Дирижер – Д.Соколов.
3 март – М.Таминдарова җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт камера хоры концерты.

Иң камил

Кеше йөрәге бер генә секунд та ял итми! 50 елда йөрәк аша үткән кан микъдары кадәр су агызу өчен, кранны тулы куәтенә ачып, аны 45 ел буе япмаска кирәк. Тәндәге барлык кан тамырлары озынлыгын кушсаң (иң вак капиллярларны да кертеп), 105 мең чакрымлы тамыр барлыкка килер иде. Бавыр 500 ләп вазыйфа башкара. Ул организмга кергән бөтен нәрсәне фильтрлап кына калмый, үт тә эшләп чыгара, туклыклы матдәләрне дә саклый. Кандагы кислородның 20 процентын баш мие куллана. Кеше үпкәләренең сулау мәйданы өслеге 100 квадрат метрга якын, бу – футбол кыры үлчәме. Өлкән кеше көненә 23 мең тапкыр сулыш ала һәм үпкәсе аша 10 мең литр һава үткәрә. Бөер күчереп утыртканда, кешенең үз бөерләре дә урынында кала, өченчесен өскәрәк урнаштыралар. Кеше тәнендәге иң зур күзәнәк – күкәй күзәнәк, аның диаметры 1 миллиметрга тәңгәл. Чәч табигатьтә юкка чыгарылмый һәм череми, аны бары яндырып яки кислотада гына эретеп була. Нечкә эчәклекне тигезләп сузып салсаң, аның мәйданы 250 квадрат метр булачак. Анда яшәүче микроорганизмнарның авырлыгы 2,5 килограммга якын.

(“The Times”).

Химия ашыйбыз

Хәзер ясалма алмаштыргычлар файдаланып җитештерелгән продукция барлык азык-төлекнең 50 процентын тәшкил итә. Кибеттә сатыла торган ризык көннән-көн катлаулырак химик субстанциягә охшый бара. Әйтик, ит ризыкларында файдалы аксым һәм витаминнар юк диярлек, ә менә тоз, шикәр һәм май хәттин күп. Британия диетологлары, азык-төлек базарын өйрәнеп, иң популяр ун ашамлыкта уртача утызар, берсендә исә илле химик ингредиент булуын ачыклаган. Майлар арзанлы пальма мае белән алмаштырыла, азык массасына дым саклагыч, тәм көчәйткеч, балландыргыч, буяу, хуш исләндергеч, консервантлар һәм тагын әллә нәрсәләр өстәлә. Кайбер ашамлыкларда берьюлы берничә хуш исләндергеч кулланыла. Мәсәлән, E455 азык өстәмәсе агач эшкәртү калдыкларыннан алына һәм ул “Цитруслы” лимонадка яңа сыгылган сок төсен һәм куелыгын бирә, әлеге эчемлек 17 ингредиенттан, шул исәптән шикәрдән 200 тапкыр татлырак ике ясалма балландыргычтан тора. Кондитер эшләнмәләренең күбесендә какао мае үсемлек мае белән алыштырыла, бәяләре исә арзанайтылмый. Туңдырмага күбрәк һава тутырыр өчен, сөт өсте урынына төрле тотрыкландыргычлар, эмульсификаторлар, кэроб агачы кузагы сагызы һәм хәтта пальма яфракларыннан алына торган карнауб балавызы кушыла, нәтиҗәдә аның авырлыгы икеләтә арта. Британия супермаркетларының берсендә 49 ингредиентлы пицца табылган, анда бер генә табигый матдә дә юк. Төп проблема шунда ки – кулланучы, кыйммәтле булса да, сыйфатлы ризык сатып алырга әзер, әмма андый ашамлыклар көннән-көн азая бара.

(“Daily Mail”).

Сәяхәтче Сара

Швейцариянең төньягындагы кечкенә авылда туган Сара Маркиз 17 яшендә атка атланып Төркияне аркылыга-буйга йөреп чыга һәм шул вакыттан гомерен җәяүле сәяхәтләргә багышларга була. 2000 елда ул 126 көн эчендә Америка-Канада чигеннән Мексика чигенә кадәр 4260 чакрымны җәяүләп үтә. Аннары берничә ел өендә утыра. 2006 елда 8 ай дәвамында Чилидагы Анд тауларына менә. Тагын тынычлана, дүрт ел ял итә. 2010 елда мажараларга сусавы барыбер үзенекен итә – Сара Себер һәм Монголия далаларын, Гоби чүлен, Кытайны кичә, Лаос һәм Таиландка кадәр җитә. Аннары, йөк судносына утырып, Австралиягә кадәр йөзә һәм кеше яшәми торган җирләрдән меңләгән чакрым уза. Ни гаҗәп тоелса да, Сара әлеге сәяхәтен берүзе (дөрес, янында тугры эте була) ерып чыга, өч елда 16 мең чакрымнан артыграк юл үтә. Моның өчен National Geographic каналы Маркизны “Ел сәяхәтчесе” дип игълан итә.

(“The Mirror”).

Белем – бәхет ачкычы

Ричард Дженкинс башлангыч сыйныфларда укыганда ук, җавап бирергә кулын бик еш күтәрә торган булган, шуңа аңа классташлары “Гарвард” кушаматын таккан һәм гел мәсхәрәләргә маташкан. Ә бит ул чыннан да сыйныфта иң акыллысы булып чыккан! Аңа бик күп авырлык күрергә туры килгән. Ялгызы өч малай тәрбияләүче әниләре йорт өчен түли алмый башлагач, аларны урамга куып чыгарганнар. Гаилә башта Теннесига, аннары Флорида штатына, аннары кабат Филадельфиягә күченгән. Ричард алтынчы сыйныфта укыганда, сукбайлар приютында яшәгәннәр. Шунда үсмер нык карарга килгән: әнисе һәм энекәшләрен мондый хәерчелектән аралау өчен, тырышып укырга кирәк. Көн саен диярлек баш өянәгеннән интексә дә, үсмер бик яхшы укый, яңа технологияләр белән кызыксына башлаган. 11 сыйныфта ул инде сәләтле балалар өчен Girard College интернат-мәктәбенә кабул ителгән. Анда, бик яхшы укудан тыш, баскетбол да уйнаган, колледж советына да кергән, космос яратучылар клубына да йөргән. Берьюлы өч – Пенсильвания, Йель һәм Гарвард университетларына гариза биргән. Тырышлыгы һәм үҗәтлеге бушка китмәгән – Ричард Дженкинсны Гарвард университетына алып кына калмаганнар, тулы стипендия дә билгеләгәннәр, ягъни ул анда бушлай укый, яши һәм туклана алачак. Туганнарына әлеге сөенечле хәбәрне җиткергәч, абзасы Дональд Кинси, егеткә планшет һәм кирәк-ярак алыр өчен, краундфандинг платформасында акча җыюны оештырган – моңа кадәр беркемнән дә ярдәм сорамыйча үз теләгенә ирешкән энекәшенә бераз булышырга ниятләгән.

(“The Washington Times”).

Кытайның Хайнань провинциясендәге “агач-йортлар” буларак мәгълүм Beauty Crown Hotel кунакханәләр комплексы моннан берничә ел төзелгән һәм дөньядагы иң зур отельләрдән берсе санала.

(“Nation Geographic”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

27 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 16.00 «СИҢА КАЙТАМ». 16+
10.00, 23.00 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
13.00 «Семь дней». 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
17.00 «Татарлар». 12+
17.30 «Трибуна «Нового Века». 16+
19.00, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
23.50 «Здоровая семья: мама, папа, я». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Туган җир». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА». 16+
15.30, 20.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.05, 22.10 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «Рейс в один конец. Прокуроры 6». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ПРИКАЗАНО УНИЧТОЖИТЬ! ОПЕРАЦИЯ: «КИТАЙСКАЯ ШКАТУЛКА». 16+
11.30 «НА ПОРОГЕ ЛЮБВИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «БРАТСКИЕ УЗЫ». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Законоблюстители. Правое дело». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+
20.00 «ПРИНЦ СИБИРИ». 12+
23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
22.40 «Большая игра». 16+
23.40 «Век СССР». «Восток». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИМИТЧИЦЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Александр Володин.
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Русский бал».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «ТРЕСТ, КОТОРЫЙ ЛОПНУЛ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Человек придумал песню. Авторский вечер поэта Леонида Дербенева».
12.25 «Исцеление храма».
13.10 Линия жизни. Игорь Петренко.
14.05 «Забытое ремесло».
14.20 К 130-летию со дня рождения Всеволода Пудовкина. Острова.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 Мастера исполнительского искусства. Даниил Шафран.
16.40 Спектакль «Фома Опискин».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Магическое стекло академика Дианова».
21.25 «Сати. Нескучная классика...»
22.10 «СЁГУН».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АУТСАЙДЕР». 16+
22.00, 0.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+

Сишәмбе

28 февраль «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 16+
10.00, 23.30 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
11.00 «Азбука долголетия». 16+
11.15 «Память сердца». 16+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.40 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
13.00 «Родная земля». 12+
13.30 «Юлчы». 16+
14.00 «Путь». 16+
14.15 «Не от мира сего...» 16+
15.15 «Теймә».
16.00, 0.45 «Соотечественники». 16+
18.00 «Казаннан - казанга». 16+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00, 22.10 «Трибуна «Нового Века». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 12+
9.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА». 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРИНЦ СИБИРИ». 12+
11.30 «НА ПОРОГЕ ЛЮБВИ». 12+
12.30, 18.30 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «БРАТСКИЕ УЗЫ». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Законоблюстители. Правое дело». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.50 «Короче говоря». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Век СССР». «Север». 18+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИМИТЧИЦЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 Императорский дом Романовых.
7.05 Легенды мирового кино. Ростислав Плятт.
7.35 «Великие строения древности».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «ТРЕСТ, КОТОРЫЙ ЛОПНУЛ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Тропой Арсеньева».
12.30, 22.10 «СЁГУН».
14.10 80 лет со дня рождения Юрия Волчка. Academia. Юрий Волчок. «Архитектоника В.Г. Шухова».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 Мастера исполнительского искусства. Евгений Светланов.
16.50 Спектакль «Эдит Пиаф».
18.35 «Очарованный жизнью. Борис Иванов».
19.20 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Искусственный отбор.
21.25 «Белая студия».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АУТСАЙДЕР». 16+
22.00, 0.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+

Чәршәмбе

1 март «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 16+
10.00, 23.00 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
13.00 «Җырлыйк әле!» 12+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15, 0.30 «Если хочешь быть здоровым». 16+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00, 0.40 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Спортивная среда». 6+
23.50 «Соотечественники». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00 «Палитра». Бакый Урманче. 16+
8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
9.40 «Йөрәктән-йөрәккә». Абрек Абзгильдин турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА». 16+
15.30, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.30 «Гаилә учагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРИНЦ СИБИРИ». 12+
11.30 «РЕДКАЯ ГРУППА КРОВИ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЕГО ЛЮБОВЬ». 12+
14.35 «Великие женщины России». 12+
14.50 «Не женское дело». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Восход Победы. Курская буря». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 «Век СССР». «Юг». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИМИТЧИЦЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 Императорский дом Романовых.
7.05 «Театральная летопись». Павел Хомский.
7.35 «Великие строения древности».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «ТРЕСТ, КОТОРЫЙ ЛОПНУЛ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Мастера русской оперы. Жизнь и роли Ивана Петрова».
12.20 Цвет времени. Василий Поленов. «Московский дворик».
12.30, 22.10 «СЁГУН».
14.00, 19.10 «Первые в мире».
14.15 Искусственный отбор.
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 Мастера исполнительского искусства. Марис Янсонс.
16.40 Спектакль «Вечерний свет».
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 Абсолютный слух.
21.25 Власть факта. «Северная Корея: опыт изоляции».

«НТВ»

4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АУТСАЙДЕР». 16+
22.00, 0.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+

Пәнҗешәмбе

2 март «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 16+
10.00, 23.00 «НОЧНЫЕ ЛАСТОЧКИ». 12+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ДЕТЕКТИВ ӘНИ». 12+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 12+
14.15 «Рыцари вечности». 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә.
16.00, 21.10 «Ватандашлар». 16+
18.00 «Юлчы». 16+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Погружение на 100». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Бар фасылга - бер асыл». Рузия Мотыйгуллина турында телеочерк. 16+
10.40 «Туган авылым». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА». 16+
15.30 «Таяну ноктасы». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРИНЦ СИБИРИ». 12+
11.30 «РЕДКАЯ ГРУППА КРОВИ». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ЕГО ЛЮБОВЬ». 12+
14.35 «Великие женщины России». 12+
14.50 «Не женское дело». 12+
15.00 «Рассекреченная история». 12+
15.30 «Восход Победы. Днепр: крах «Восточного вала». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50, 18.20 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТЕСТ НА БЕРЕМЕННОСТЬ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+
23.45 Подкаст.лаб. 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.

11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЛИМИТЧИЦЫ». 12+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.45 Новости культуры.
6.35 Императорский дом Романовых.
7.05 «Театральная летопись». Павел Хомский.
7.35 «Великие строения древности».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «НЕЗАКОНЧЕННЫЙ УЖИН».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Встреча в концертной студии «Останкино» с писателем Валентином Катаевым».
12.20 Дороги старых мастеров. «Гончарный круг».
12.30, 22.10 «СЁГУН».
14.05 60 лет Евгению Дятлову. Линия жизни.
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Русская усадьба».
15.50 Мастера исполнительского искусства. Эмиль Гилельс.
16.25 Цвет времени. Микеланджело Буонарроти. «Страшный суд».
16.40 Спектакль «Странная миссис Сэвидж».
19.10 Голливуд Страны Советов. «Звезда Веры Марецкой». Рассказывает Олеся Судзиловская.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Владислав Отрошенко. «Околицы Вавилона».
20.30 «Спокойной ночи, малыши!»
20.45 «Белое солнце пустыни». Для кого ты добрая, госпожа удача?»
21.30 «Энигма. Анна Цыбулёва».

«НТВ»
4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «АУТСАЙДЕР». 16+
22.00, 0.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+

Җомга

3 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Оныта алмыйм...» 12+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 16+
6.00, 7.10 «Манзара». 16+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 16+
8.10 «Здравствуйте!» 16+
9.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ». 16+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
11.00 «Нәсыйхәт». 16+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00 «Ком сәгате». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 16+
14.15 «Здоровая семья: мама, папа и я». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә.
16.00 «Аулак өй». 12+
16.30 «Әдәби хәзинә». 16+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00 «Гаилә учагы». 16+
22.10 «ВЕРЮ В ЛЮБОВЬ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00, 13.05 «Манзара». 16+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 16+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 16+
10.30 «Казаннан казанга». 16+
11.00, 15.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 16+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА». 16+
16.00 «Әдәби хәзинә». 6+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.00 «Яңалыклар». 12+
19.20 «Туган җир». 12+
19.50, 22.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 12+
20.30 «Заман көзгесе». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «АКВАТОРИЯ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПРИНЦ СИБИРИ». 12+
11.30 «РЕДКАЯ ГРУППА КРОВИ». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «СПИТАК». 16+
14.45 «Великие женщины России». 12+
15.00 «Коллекция». 12+
15.30 «Восход Победы. Падение блокады и крымская ловушка». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 16.50 Информационный канал. 16+
16.00 «Мужское/Женское». 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 «ГОЛОС». 12+
23.35 Подкаст.лаб. 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
0.15 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 Императорский дом Романовых.
7.05 «Театральная летопись». Павел Хомский.
7.35 «Великие строения древности».
8.30 «Жизнь и судьба».
8.50 «НЕЗАКОНЧЕННЫЙ УЖИН».
10.15 Гении и злодеи.
10.45 Открытая книга. Владислав Отрошенко. «Околицы Вавилона».
11.10 «Юрий Завадский».
12.20 Цвет времени. Клод Моне.
12.30 «СЁГУН».
14.00 «Забытое ремесло».
14.15 Власть факта. «Северная Корея: опыт изоляции».
15.05 Письма из провинции. Ярославль.
15.30 80 лет со дня освобождения Ржева от немецко-фашистских захватчиков. «Героям Ржева посвящается...» Благотворительный концерт.
16.15 Спектакль «Дальше - тишина».
18.45 «Царская ложа».
19.45 К 85-летию Вячеслава Зайцева. Линия жизни.
20.40 «УЧИЛКА».
22.50 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.55 «МОСКВА. ТРИ ВОКЗАЛА». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ДЕЛЬТА. ПРОДОЛЖЕНИЕ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «АУТСАЙДЕР». 16+
22.00 «НЕВСКИЙ. ТЕНЬ АРХИТЕКТОРА». 16+

Шимбә

4 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 16+
7.00 «Синә Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Казаннан - казанга». 16+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 16+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
13.30 «Гаилә учагы». 16+
14.00 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». 16+
17.20 «Килеп китсәм ни була?» Винарис Ильегет концерты. 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 16+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 16+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Җырлыйк әле!» 12+
22.00 «КунакБит шоу». 16+
23.00 «ПРИТВОРЩИКИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
6.00 «Җиде энҗе». Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле концерты. 12+
7.00, 15.00 «Синә Миннән Сәлам». 16+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 16+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 12+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Үксезләр». 16+
17.15 «Казаннан казанга». 16+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 16+
20.30 «Мәхәббәт җыры». Резеда Шәрәфиева һәм Равил Галиев концерты. 16+
22.40 «МӘХӘББӘТ ХАКЫНА». 16+

«ЭФИР»
3.00, 19.00 «Город». 16+
5.00, 8.00 «Великие женщины России». 12+
5.15 «Не женское дело». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайные механизмы природы». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.15 «МОЙ КАПИТАН». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «БЕЛЫЕ РОСЫ. ВОЗВРАЩЕНИЕ». 12+
14.50 «Крик души. Депрессия». 12+
15.45 «ДВЕ ЖЕНЫ». 16+
21.00 «ХРАБРОЕ СЕРДЦЕ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Проуют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «ПО ЗАКОНАМ ВОЕННОГО ВРЕМЕНИ». 12+
16.25 «Горячий лед». Финал Гран-при России по фигурному катанию.
18.20 «Кто взорвал «Северные потоки»?» 16+
19.20 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.45 «ПОМЕНЯТЬСЯ МЕСТАМИ». 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «Доктор Мясников». 12+
12.55 «АКУШЕРКА. НОВАЯ ЖИЗНЬ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «РАЗВОД С ПРЕПЯТСТВИЯМИ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05, 12.25 Мультфильмы.
7.55 «КОГДА МНЕ БУДЕТ 54 ГОДА».
9.25 «Мы - грамотеи!»
10.05 «ЗЕЛЕНЫЙ ФУРГОН».
13.15 Черные дыры. Белые пятна.
13.55 «Опасные связи. Друзья и враги в дикой природе».
14.50 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
15.55 «НА СЕМИ ВЕТРАХ».
17.40 Линия жизни. Лариса Лужина.
18.35 Искатели. «Янтарная комната. Поиски продолжаются».
19.20 «ОДНАЖДЫ НА ДИКОМ ЗАПАДЕ».
22.00 «Агора».
23.00 «ДЕЛОВЫЕ ЛЮДИ».

«НТВ»
5.00 «Жди меня». 12+
5.50 «ВИЖУ-ЗНАЮ». 16+
7.25 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Основано на реальных событиях». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «Секрет на миллион». 16+
23.25 «Международная пилорама». 18+

Якшәмбе

5 март
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Оныта алмыйм...» 12+
6.00 «Син минем тиң ярым». Зинира һәм Ризат Рамазановлар концерты. 12+
8.00, 13.00 «Адымнар». 16+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы».
10.15 «Ачыктан - ачык». 16+
11.00 «Туган авылым». 12+
11.30 «Тархан». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 16+
13.30 «Погружение на 100». 12+
13.40 «ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮК ИКӘН». 16+
14.35 «Татар халык җырлары».
15.00 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
16.00 «Ком сәгате». 16+
17.00 «Видеоспорт». 16+
17.30 «Соотечественники». 16+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 16+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 12+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
23.00 «ЗА ГРАНЬЮ РЕАЛЬНОСТИ». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35, 0.15 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 16+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 16+
7.00 «Адымнар». 16+
7.30 «Җырлыйм туган якта». Илгиз Закировның иҗат кичәсе. 16+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Рөстәм Вәлиев турында телеочерк. 16+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.40 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 6+
13.00 «Туган авылым». 12+
13.20 «Гаилә учагы». 16+
13.50 «Олы юл әйтте...» циклыннан «Ышаныч». 16+
15.30 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Габәши язмышы». 16+
16.20, 21.10 «Әниемнең җылы кочагы». 16+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 16+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 16+
20.00 «Семь дней». 16+
22.00 «Яшик сеенеп кенә». Рифат Зарипов концерты. 16+

«ЭФИР»
5.00, 15.00 «Великие женщины России». 12+
5.15 «Не женское дело». 12+
5.30 «Дело №». 12+
6.30 «Тайные механизмы природы». 12+
7.00 «Смешарики. Новые приключения».
7.30 «Фиксики».
8.00 «Крик души. Депрессия». 12+
8.45 «ДВЕ ЖЕНЫ». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «СПАСТИ НЕЛЬЗЯ ОСТАВИТЬ». 6+
14.15 «Золотое дно Охотского моря». 12+
15.15 «МОЙ КАПИТАН». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ВСЁ ИЛИ НИЧЕГО». 16+
23.00 «НОЧНАЯ ФИАЛКА». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
6.10, 0.00 Подкаст.лаб. 16+
6.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.10 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Диагноз для Сталина». 12+
13.10 «Прокофьев наш». 16+
14.10 «Бомба. Наши в Лос-Аламосе». 16+
15.15 «Горячий лед». Финал Гран-при России по фигурному катанию.
16.30 «Закат американской империи». «Украина». 16+
19.00 «Три аккорда». 16+
21.00 «Время».
22.35 «КОНТЕЙНЕР». 16+
23.30 «На футболе с Денисом Казанским». 12+

«РОССИЯ»
6.10 «СЧАСТЛИВАЯ СЕРАЯ МЫШЬ». 12+
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.50 «Большие перемены».
12.55 «АКУШЕРКА. НОВАЯ ЖИЗНЬ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 12.20 Мультфильмы.
7.50 «ЖУКОВСКИЙ».
9.15 Тайны старого чердака. «Странные художники».
9.45 Диалоги о животных.
10.25 «ДЕЛОВЫЕ ЛЮДИ».
11.50 Невский ковчег. Теория невозможного. Александр Шарымов.
13.25 «Игра в бисер» "Эдуард Успенский. «Крокодил Гена и его друзья».
14.10 К 250-летию Большого театра России. Марис Лиепа, Владимир Васильев, Екатерина Максимова в балете «Спартак».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.40 Юбилей Лики Нифонтовой. Линия жизни.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «ЗЕЛЕНЫЙ ФУРГОН».
22.30 Великие имена. Мария Каллас.
23.25 «ДЭЙЗИ МИЛЛЕР».

«НТВ»
5.00 «ВИЖУ-ЗНАЮ». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Человек в праве с Андреем Куницыным». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Маска». Новый сезон. 12+
23.30 «Звезды сошлись». 16+

Рәфкать Вәлиев хәзерге Башкортстанның Кыйгы районы, Еланлы авылында Әхтәмҗан ага гаиләсендә 1911 елда дөньяга килгән. Гаилә башлыгына гражданнар сугышында шактый озак катнашырга туры килү сәбәпле барлык авырлыклар баш балага — 8 яшьлек Рәфкатькә төшкән.

Бервакыт мәктәп мөдире Низаметдин Терегулов (Уфа ягыннан килгән педагог) Рәфкатьнең әнисен мәктәпкә чакыртып ала һәм аңа: «Мәстүрә, улың бик башлы күренә, әйдә, ул укырга килсен, дәреслек, каләм-кәгазь белән үзебез ярдәм итәрбез», – ди. Шулай итеп малай дәресләргә йөри башлый, укуда сабакташларын бик тиз куып җитә. Җәен ул, гадәттәгечә, көтүче булып ялланa. Башлангыч мәктәпне мактау кәгазе белән тәмамлагач, Низаметдин мөгаллим тагын Мәстүрә белән сөйләшә: «Улың бик сәләтле, аны бу белем белән калдырсак, гөнаһ булыр, әйдә, аны күрше Еландино (урыс авылы) җидееллык мәктәбенә бирик. Директоры белән сөйләштем. Рәфкать өчен туклану, тору урыны тулай торакта булыр», – ди. Рәфкать әлеге мәктәпне дә бик яхшы билгеләренә тәмамлый, бигрәк тә математика, физика кебек фәннәрдән көчле була. Шуны истә тотып Еландино мәктәбе дирекциясе аны Пермьдәге механика техникумына укырга җибәрә. Бирердә дә егет күпләрне шаккатыра: югары курс студентларына иң авыр мәсьәләләрне чишеп бирә...

Техникумны тәмамлагач, җитәкчелек яшь талантны Мәскәү университетына юллый, аны математика факультетына имтиханнарсыз кабул итәләр. Нәтиҗә шул ук: университетны кызыл диплом белән тәмамлый һәм аспирантурага калдырыла. Әмма Мәгариф министрлыгы яшьләр белән эшләү өчен Рәфкатьне Монголия халык республикасына җибәрә. Аннан кайткач, аны Бронетанк гаскәрләре академиясенә математика укытучысы итеп билгелиләр, диссертацияне эш арасында язарсың, дип тынычландыралар. Әмма Бөек Ватан сугышы башлана. Р.Вәлиев берничә мәртәбә рапорт язып, Мәскәүне саклаучылар сафына басарга тели. Ул теләгенә ирешә: мәскәүлеләрдән төзелгән бер ополчениедә артиллерия дивизионы командиры итеп билгеләнә. Кенигсберг өчен барган сугышта ул өченче мәртәбә каты яралана (күрсәткән батырлыклары

Генерал Рәфкать Вәлиев

өчен Р.Вәлиев Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителсә дә, гамәлгә ашырылмый калдырыла).

Сугыштан соң якташыбыз М.Фрунзе исемендәге Хәрби академияне тәмамлый. Аны Совет Армиясенең Генштабына, ракеталар белән шөгыльләнә торган бүлегенә эшкә чакыралар, генерал дәрәҗәсе бирелә. Ул анда СУ-25, СУ-75, СУ-125 зенит ракеталар белән шөгыльләнүче атаклы конструктор академиклар А.Расплетин, С.Лавочкин, П.Грушин, Б.Бункин, Ю. Фигуровскийлар белән хезмәттәшлек итә. Яңа хәрби коралларны сынауда катнаша. Әлеге өлкәдәге уңышлары өчен Р.Вәлиев Ленин премиясе белән бүләкләнә.

Рәфкать ага моннан берничә ел элек йөрәк авыруыннан дөнья куйды. Докторлык диссертациясен дә (ул язылып беткән иде) яклап өлгерә алмады... Әмма ул әле дә тере кеше булып күз алдында тора: уртача буйлы, тыгыз тәнле, җиргә нык басып йөрер иде. Гомере буе руслар арасында яшәсә дә, туган телне әйбәт белде, хөрмәт итте.

Рәфкать ага заманасының күренекле галимнәре, хәрби начальниклары белән еш аралашкан, бигрәк тә, маршал Иван Христофорович Баграмян белән якын дус булган... Баграмян да, Сталин да Грузиядә туып үскән, шуңа күрә бу ике күренекле шәхес еш кына очрашкан да. Бервакыт Рәфкать ага Иван Христофоровичка: «Сталин спорт белән кызыксына идеме?» — дигән сорау белән мөрәҗәгать иткән. Баграмян болай дигән: «Иосиф Виссарионович спорт белән кызыксынмый иде кебек. Әмма, ниндидер команда читкә чыгып оттырып кайтса, аларны тренеры белән бергә төрмәгә яптырып ала иде...»

Югарыда әйттек, Рәфкать ага Башкортстанда туган. Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, ул республика җитәкчеләре өчен Рәфкать Вәлиев дигән күренекле генерал-галим юк... Шулай да, Еланлы урта мәктәбенең Туган як музеенда аңа багышланган стендлар булдырылган, эшчәнлеге турында материаллар тупланган. Минемчә, татарның мондый күркәм егетләренә Татарстанда да әһәмият бирергә вакыт. Онытмыйк: Татарстанда татар халкының нибары 25 проценты гына яши. Димәк, бик күп атаклы затларыбыз чит регионнардан чыккан. Башка халыклардан үрнәк алып, безгә дә мәшһүр шәхесләребезне мәңгеләштерү чараларын күрү мәслихәттер...

Мәхмүт ӘХМӘТҖАНОВ,
педагогика фәннәре докторы.
«Гасырлар авазы» журналыннан.

Аксакал әдип бәйрәме

Түбән Кама шәһәренең Г.Тукай исемендәге китапханәсендә Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, язучы Фәтхулла Абдуллинның 85 яшьлек юбилеена багышланган «Бу дөньяга без килгәнбез икән» исемле кичә гөрләп үтте.

Хезмәт биографиясенә күз салсак, тумышы белән Мөслим районы Яңа Сәет авылыннан булган Фәтхулла абый күрше Мари Бүләр авылында җидееллык мәктәпне тәмамлап, берничә ел колхозда эшләгәннән соң, Үзбәкстанга китә, анда тимер юлда эшли, шунда Ташкент тимер юл техникумын тәмамлый. Төзүче мастер буларак, Памир таулары аша автотрасса, Кыргызстан һәм Үзбәкстанда ГЭСлар төзүдә, 1966 елдагы җир тетрәвеннән соң җимерелгән Ташкентны торгызуда катнаша. Гыйлемгә омтылу юлында вагоннар бушатып, карбыз тәяп йөргән чакларын тормышының иң авыр чаклары дип искә алмый ул. Аның өчен тормышының иң авыр мизгеле булып, алтынчы сыйныфта укыганда, әтисенең бакыйлыкка күчүе, аннары әнкәсе Гыйльмекамалның вафаты санала.

– Әткәй кырысрак холыклы булса да, гадел кеше иде, ул атларны бик яратты, мин белгәндә, 1945-1946 елларда ике атыбыз бар иде безнең. Әткәй үзе ашамаса ашамады, әмма атларын нык тәрбияләде. «Синең пәкең кылыч кебек үткен, малайның чәчен алып җибәр әле, Габдулла, дип, әткәй янына балаларын җитәкләп авылдашлар да еш килде. Ә әнкәй турында мин таң атканчы сөйли алам, тик анда булган күркәм сыйфатларны мин барыбер тезеп чыга алмам. Әнкәй ризыкларны да бик тәмле пешерә иде, мөнәҗәтләрне, экиятләрне, кич йокларга ятканда өйрәткән догаларны мин китаптан укып түгел, ә әнкәй сөйләгәннәрдән хәтерлим. Кемдер йомшы белән кергәндә, үз авызыннан өзеп булса да, ярдәм итәргә тырышты», – дип хәтер яңарта Фәтхулла абый.

Беренче сыйныфны бишлегә тәмамлаган өчен унике биттән торган юка гына дәфтәргә иә булу шатлыгын бүгенгәчә йөрәк түрендә саклый. Моңа өстәп, укып чыгып, һөнәрле булуын, гаилә коруын да гомеренең иң якты, матур вакытлары буларак тасвирлый ул, тормыш дәверендә ирешелгән уңышларын, 55 ел иңгә-иң куеп яшәгән хатыны Альмира апа кебек ныклы терәге булуы белән аңлата, үз чиратында, бергәләп ике кыз, ике ул үстергән тормыш иптәшенә ихлас рәхмәтләрен җиткерә. Ә тырыш хезмәт белән сугарылган уңышлары шактый. Ул Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, дистәдән артык китап авторы, С.Сөләйманова исемендәге бүләк иясе буларак мәгълүм. Күркәм юбилеенда Татарстан Дәүләт советы депутаты, язучы Ркаил Зәйдулла Ф.Абдуллинга Дәүләт советының Рәхмәт хатын һәм Мәдәният министрлыгының «Әдәбияттагы казанышлары өчен» медален дә тапшырды.

– Фәтхулла абый Түбән Кама өчен генә түгел, туган ягы Мөслим өчен дә җан атып яши. Мине Мөслим җәмгыятенең җитәкчесе итеп куйган кеше дә әле ул! – дип белдерде шәһәр башлыгы Рамил Муллин үз котлавында. – Ул миңа бер яктан Мөслимне онытмаска, икенче яктан Түбән Камада хезмәт куярга ярдәм итә... Язучы буларак кына түгел, яшь буынны тәрбияләүдә остаз булуы өчен дә хөрмәт итәбез аны. Менә бу чараны зәвыклы, аңа милли рух бөркеп торучы китапханәчеләрдән Айгөл Гәрәева белән Фирая Фәләхиева да аның укучылары.

Күркәм чарада Казаннан Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, язучы Хәбир Ибраһим, Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе, Г.Тукай бүләге иясе Факил Сафин, шагыйрә Лилия Садриева, Бөтендөнья Татар Конгрессының Түбән Кама бүлеге җитәкчесе Рөстәм Ганиев, бүлекнең башкарма директоры Фирдәвес Ханов, Түбән Кама шәһәренең «Урал» башкорт оешмасы җитәкчесе Гали Хәсәнов, «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе җитәкчесе Рәсимә Нәбиуллина, җырчылар Рөстәм Мортазин, Илһам Хисмәтуллин, мәгариф ветераны Саимә Сабитова, язучының туганнары, якыннары, каләмдәшләре, якташлары һ.б чыгыш ясады. Якташ мөслимлеләр юбилярга район башлыгының рәхмәт хатын һәм истәлек бүләкләр тапшырды. Чара барышында халык шагыйре Разил Вәлиевнең Фәтхулла абыйга юлланган котлау телеграммасы да килеп иреште.

Күптән түгел Арчаның »Җидегән чишмә» исемле халык театры Фәтхулла абыйның «Яшьлек кабат чәчәк атканда» комедиясен сәхнәләштергән булган. Бу көнне зур экраннан әлеге тамашадан өзек күрсәтелде. Моннан тыш, язучының «Без кешедән киммәни» әсәре Минзәлә, Түбән Кама, Зәй, Азнакай һ.б халык театрлары коллективлары тарафыннан сәхнәгә куелган, ә «Сау бул дип әйтә алмыйм» дигән пьесасы Түбән Кама татар драма театрында барган.

Фәтхулла абый дистә елдан артык «Кама таңнары» әдәби берләшмәсен җитәкләгән чорда ул шушы төбәктә яшәп иҗат итүче шагыйрь вә язучыларның әсәрләре тупланган 4 әдәби альманах дөнья күрде, берләшмәгә йөрүче Х.Ягъфәр, И.Хәйруллин, Р.Имаев, М.Хафизов, И.Вәлиуллина, Ф.Имамов, Н.Мирхазовалар Язучылар берлегенә кабул ителде. Фәтхулла абый әле 5 ел буе татар төрек лицеенда әдәби түгәрәк тә алып барды.

Түбән Кама аксакалы бүген дә иҗатчылар сафында.

Илзирә ВӘЛИУЛЛИНА.

«Татар кызы»ның «атасы»



Казаныбызда кем иң күп монументаль эшләр башкарган? Беренчеләрдән булып кайсы рәссам тарих темасына керешкән һәм дивар зурлыгында картиналар иҗат иткән? Рәссамнардан кайсысы иң күп портрет ясаган? Бу сорауларга, әлбәттә, Виктор Федоров, дип җавап бирәбез. Кылкаләм остасының гомере нибары 61 яшендә өзелә. Әмма ул үзеннән соң республикабызның гына түгел, бөтен Россиянең күрке булган мирас калдыра. Былтыр 80 еллыгы уңаеннан Татарстан Мәдәният министрлыгы, Сынлы сәнгать музее, рәссамның гаиләсе һәм «Заман» нәшрияты альбом-каталог чыгарырга тиеш иде. Әмма эш озаккарак сузылып, затлы басма әле яңа гына табадан төште. Милли китапханәдә аны сәнгать сөючеләргә тәкъдим иттеләр.

Басманы сәнгать белгечләре Фәридә Миңнегулова, Ольга Улемнова һәм рәссамның хатыны Антонина Федорова төзегән. Мәкаләләр авторлары арасында сәнгать белгечләре Динә Вәлиева һәм Динә Әхмәтова да бар. 288 битлек альбомда Казан музейларында сакла용 иҗат әсәрләре генә түгел, Чабаксар, Владимирда, шәхси тупламаларда һәм кылкаләм остасының гаиләсендәге картина-рәсемнәр дә бастырылган.

Бирегә 1967 елда С.Бубеннов белән бергәлектә иҗат ителгән һәм алтмыш елга якын тимер юл вокзалында башкалабыз кунакларын каршы алган «Казан – Татарстанның башкаласы» панносындагы татар кызы лаеклы рәвештә түр урынны алып тора. Ни кызганыч, рәссамның байтак монументаль эшләре юкка чыккан. Адәм баласының гасырлардан килгән бер яман чире бар – яңаны төзү өчен ул элек бар ителгәнне юкка чыгара. Мәсәлән, сәламәтлек комбинаты белән бергә Федоровның монументаль эше дә юкка чыкты. Шулай да Яшел Үзән вокзалындагы мозаика панносы, Казаныбызның Горький һәм Шаляпин музеендагы витражлары, «Оргсинтез» бассейнында, янгынга каршы хезмәт музеенда, Киров районындагы бер йорт фасадында монументаль әсәрләре сакланган. Элек Төзүчеләр, хәзер исә Сәйдәш мәдәният үзәгендәге витражларны да хатыны Антонина Ивановна һәм җәмәгатьчелек тавыш куптарып кына саклап калды. Альбомда аларны гына түгел, вәхшиләрчә юкка чыгарылган эшләрне дә күрергә мөмкин.

Татар халкы Федоровны барыннан да бигрәк үткән гасырның сиксәненче еллары башында ук иҗат ителгән «Пугачев һәм Бәхтияр Канкаев» картинасы, Җәлилчеләрнең батырлыгын тасвирлаган «Кызыл карлыгачлар» сурәте, «Габдулла Тукай һәм «Сәйяр» труппасы» киндере, драматург, режиссер К.Тинчурин, танылган артистка Рәшидә Җиһаншина портретлары, Ә.Фәйзинең «Тукай» романына иҗат ителгән иллюстрацияләре аша белә. Виктор дәдәйнең Европа артистлары рәвешендә зурлап, яратып сурәтләнгән җырчыбыз Ринат Ибраһимов портретын ничек онытасың?!

В.Федоров майлы буяулы картиналарны да, акварельләр сыман, бик җиңел, виртуозларча иҗат иткән. Бу аның житди мәктәп үтүен күрсәтә. Альбомда беренче тапкыр рәссамның графикасына зур урын бирелгән. Бу бүлектә В.Федоровның 1960-1980 елларда «Татарстан» китап нәшрияты өчен иҗат ителгән китап иллюстрацияләре дә тупланган. Арада рәссамның үзе язган «Мишин колосок» китабы да бар. Шуның өстенә, рәссам 400 дән артык шигырь иҗат иткән һәм 1997 елда алардан «Миг» дип исемләнгән китап та нәшер ителгән иде. Барысына да ничек житешкән ул?!

Альбом-каталогны тәкъдим итү тантанасына килгән рәссамнар, туганнары барысы да В.Федоровның зыялылыгы, киң күңеле булуы, портретларындагы галим, язучыларны, күргәзмәсенә килгән министр, директорларны гына түгел, гап-гади кешеләрне дә ярата белүе турында искә алды. Бервакытта да тавышын күтәрмәс, урамнан барганда юлында очраган әби-бабайның хәл-әхвәлен сорашмыйча, балачагага сәлам бирмичә узмас иде, диештеләр.

Иренең мирасына сакчыл булганы өчен хатыны Антонина Ивановнага рәхмәт. Шәһәр буенча монументаль эшләрне барлап йөрүче дә, җимермәгез, дип чаң кагучы да, альбом-каталогка шул хакта зур мәкалә әзерләүче дә ул! Газетабызда В.Федоров турында мәкалә чыккач редакциягә килүен һич онытырлык түгел. Аның, балам, русчага тәрҗемә итче, ирем турында һәр мәкаләне җыеп барам, һәр сүзне мәгънәсенә төшенеп укыйсы килә, дип ялваруында иренә, аннан калган мираска чиксез ихтирамы, табынуы сизелә иде...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль кәнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 22.02.2023

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2606

16+